ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN
ISSN 0130-2418
№08 (391)
АВГУСТ 2024
1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ГҮЗӘЛ ХАНЫМНАР ИРТӘН КЕМГӘ КОЙМАК ПЕШЕРӘ

4 612750 670011

№08 (391)
АВГУСТ 2024

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Венера Вольская, Илдус Заһидуллин, Яна Шевцова
Фотограф: Александр Ефремов
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Раджана Солтанова, «Мисс һәм Миссис Бизнес Татарстан 2024» конкурсы җиңүчесе, тәрҗемәләр компаниясен оештыручы һәм аның директоры.
Влада Мартина фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: А-1615
Басарга кул куелды: 14.08.2024
Чыгу көне: 20.08.2024

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

МИНЕ ЮЛЛАР, ЮЛЛАР ЧАКЫРА...

Традиция буенча ел саен берәр санны туризмга багышлап, «Татарстан» журналында үзенчәлекле юл күрсәткече ясарга тырышабыз.

Бу ел да искәрмә булмады. Август аенда редакциябез яңа ачылган М-12 трассасы буенча сәяхәткә чыкты. Максатыбыз – яңа юлның туристлык потенциалын ачыклау.

...М-12 юлыннан беренче борылыш – без Татарстанның Кайбыч районында. Зур Подберезье авылының ачык һавадагы музеена тукталдык. Анда безне тегермәннәр каршы алды: су тегермәне, җилнеке, узган гасырда, аннан алдагысында төзелгәннәре. Районда бик шәп балык тоту урыны да бар икән. Колаңгыда туктап, карп балыклары тоттык. Пешереп ашап та карадык. Тәме – телеңне йотарлык!

...М-12 юлыннан икенче борылыш Түбән Новгород өлкәсенең Сергач шәһәренә китерде. Узган гасырның 80 нче елларына кайткандай булдык. Шәһәр безне кәмитләрдә биегән аюлары турындагы истәлекләре белән шаккатырды. Аюлар хәтта Наполеон белән сугышта да катнашкан, диләр!

...М12 юлыннан тагын бер борылыш Арзамас шәһәренә илтә. Бу калай әтәчләр, юк, калай казлар шәһәре икән. Чын казларга куелган сыннар шактый күп монда. Каз сугышларында катнаштыру өчен, аларны хәтта җәяүләп Мәскәүгә алып барганнар, диләр.

...Тагын бер борылыш – Муромда тукталабыз. Владимир өлкәсе храмнары һәм монастырьларының матурлыгы белән таң калдырды. Ока елгасы аша сузылган күперне күреп тә хозурландык. Биредә әкиятләр каһарманы Илья Муромец туган, диләр.

Сәяхәтләрнең дәвам итүен телисезме? Юлга чыгыгыз, борылыш саен – истәлекле урыннар, матур кала-салалар. Рәхәтләнеп үз маршрутыгызны төзеп, илебезнең матурлыгына, байлыгына сокланып кайтыгыз. Әле вакыт бар...

Сезнең сәяхәтче редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2024 елның ртыеллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1212 сум 00 тиен китереп бирешле,
1175 сум 40 тиен соратып алганда.
2024 елга ТР буенча язылу бәясе:
2423 сум 92 тиен китереп бирешле,
2350 сум 66 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» журналына 103 яшь

\# ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

\# бары тик ТАТАРСТАНДА

ШАЛЯПИННЫҢ КИРЕ КАЙТУЫ

Казанның Бауман урамындагы бронза Федор Шаляпин – бөек рус басына безнең илдә куелган беренче һәйкәл. Аны моннан егерме биш ел элек, 1999 елның 29 августында, Федя Шаляпин чукындырылган Богоявленский соборы янына урнаштыралар. Һәйкәлне каплаган ак җәймәне ачуга, букукка ап-ак күгәрченнәр күтәрелә. Элеккеге Проломная, ә бүгенге Бауман урамында җырчының көчле тавышы яңгырый. Скульптор Андрей Балашов Шаляпинның туган иленнән аерылыр алдындагы халәтен сурәтләгән. Җырчының уң кулында – эшләпәсе белән плащы, сул кулы – йөрәге турысында. Саубуллашыр өчен бер генә минутка тоткарлангандай тоела... Һәйкәлне ачу тантанасында Федор Ивановичның оныгы Ирина Борисовна катнаша. Бөек җырчыга һәйкәлләр хәзер Мәскәүнең Новинский бульварында, Уфада һәм Плёста бар. Әмма Казанныкы – беренче һәм, күпләр фикеренчә, иң уңышлысы.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Триллионнар кайтырмы?
М-12 икътисад файдасына ничек эшли

8. Зур Подберезье хәзинәләре
Җил тегермәннәре кайда «яши»

14. Балык чирткән урын
Ни өчен Колаңгы карплары тәмле

24. Кичәгедән калган бүгенге
Арзамас туристларны кай ягы белән гаҗәпләндерә

32. Муромга, Илья Муромец янына
Баһадир көчен кайда җыйган

38. Аграр феномен
Ни өчен Чүпрәле районында уңыш чүпрә белән кабарткандай үсә

52. Бердәм дәүләт имтиханнары
Татар теленнән БДИ бирүчеләр нинди вузларны сайлаган

игелекле эшләр

56. Гамьле әңгәмә
Бөтен дөньяны гизәр өчен нәрсә кирәк

60. Раджана Солтанованың тәрҗемәләр дөньясы
Бизнесның киләчәге нәрсәдә

65. Җиләкле урын
Салкынга чыдам җиләкне ничек үстерергә

67. Алты мең баш – эш башлана гына
Әгерҗе районында мегаферманы кем төзер

68. Мәктәп яңалыклары
Кадыбаш мәктәбе кай ягы белән көчле

70. Тарихи мәдрәсәләр
Иж-Бубый мәдрәсәсенә укырга дип кайлардан килгәннәр

76. Гаилә бәхетенең сере
95 яшьлек Мәснәвия Сәгыйтовна киңәшләре

мәңгелек кыйммәтләр

80. Тарихи сәхифә
Шаһбазгәрәй Әхмәрев калдырган мирас

84. Фәрваз Миңнуллин истәлегенә
«Тәнкыйть күгендәге якты йолдыз»

90. Татарстан авыллары
Сарсак-Омга – удмурт дөньясына капка

96. Ай кәефе
Блогерлар Сабан туе

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

Фото: ru.wikipedia.org/Flanker

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

18.07

Илья Вольфсон, Татарстаннан РФ Дәүләт Советы депутаты, – «Молодая гвардия» балалар лагерена баргач:

– Шәһәр яны лагерьлары территорияләрен шәхси йортлар, ял базалары һәм башкалар өчен сатып алырга тырышу очраклары күп булды. Шәһәр бу җирләрне саклап калды, билгеләнешен үзгәртергә юл куймады – бу Казан мэры Илсур Метшинның принципиаль позициясе. Ә соңгы берничә елда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән лагерьларны реконструкцияләү буенча киң колачлы программа гамәлгә ашырыла.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

17.07

Дмитрий Сотников, «КАМАЗ-мастер» командасы пилоты, – «Ефәк юл» ралли-марафонында җиңгәннән соң:

– Ярыш уңышлы узды, ул тәэсирләргә бик бай булды, барысы да канәгать калды. Оештыручылар тырышкан: ландшафт һәм рельеф бик төрле иде. Бу без күптән көткән, бик сагынган узыш трассалары булды. Син кайдадыр вакытны ота, тизрәк бара аласың, барысы да синнән генә тора. Иң мөһим этапларның берсе Алтай Республикасындагы Иогач җирләре булды: без анда инициативаны үз кулыбызга алдык, этапта җиңеп, өстенлеккә ирештек.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

17.07

Саша Сулим, журналистка, блогер, – Казанда, «Черек күл» паркында true-crime* темасына лекция укыганда:

– Миңа гомумән явызлыкның табигатен өйрәнү кызык. Шул кызыксыну мине аның төрле чагылышларын эзләргә этәрде. Мин явызлык төрләрен өйрәнә башладым. Бәхеткәме икән, әллә кызганычкамы: җинаять кылган кешеләр белән сөйләшкәндә, мин үзебезнең алардан әллә ни аерылмавыбызны аңладым.

* True crime – криминал турында хакыйкать (инглизчәдән)

Фото: duma.gov.ru, kamazmaster.ru, wilsoncenter.org

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

төп тема

Бу санда тәкъдим итәбез:

М-12 юлының туристлык потенциалын **ничек** тикшерергә

Җил тегермәннәре **кайда** «яши»

Кайсы аюлар Наполен белән сугышта катнашкан

Арзамас казлары Мәскәүгә **нәрсәгә** барган

Илья Муромецның туган йорты **кайда** урнашкан

Татар теленнән имтиханны **ничек** 100 баллга бирергә

М–12 МӘСКӘҮДӘН

Ике башкала арасындагы юл вакыты

2 тапкырга

диярлек кыскара

3 млн
пассажир һәм машина йөртүче

быел яңа магистральдән файдаланачак

Аларның һәркайсы уртача

1 сәг 40 минут

вакыт ота

33 500 -

2030 елга магистраль буенча тәүлегенә шуның кадәр автомобиль узачак. Пассажирлар ташу күләменең бик тиз үсүе һәм вакытның сизелерлек кыскаруы Мәскәү белән Казан агломерацияләре чикләренең кискен киңәюенә китерәчәк.

2030 елга кадәр
160 млн кв. метрдан
артык торак -

М-12 юлының шәһәр төзелеше потенциалы

Агломерация үзәгенә 2,5 сәгатьтән дә кимрәк вакыт эчендә барып җитәргә мөмкин булган торак пунктлар агломерациянең чиге санала.

М-12 трассасы мондый торак пунктларның кискен артуына китерә, һәм икътисади яктан алар мегаполислар кебек үк җитештерүчән эшли башлый.

Башкача әйткәндә, юл үз тирә-ягында икътисади активлыкны җанландыра, чөнки трассадагы теләсә кайсы торак пункттан иң якын зур шәһәргә 2,5 сәгатьтән дә кимрәк вакыт эчендә барып җитәргә мөмкин булачак.

М-12 төзелешенә тотылган бер сум икътисадка

1,3 сум

булып кайтачак

КАЗАНГА КАДӘР

ЮЛНЫҢ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ

20 ЕЛ ЭЧЕНДӘ М-12 ЮЛЫННАН (МӘСКӘҮ–КАЗАН) КЕРГӘН ҖЫЕЛМА ИКЪТИСАДИ ФАЙДА

2 трлн сум*

1,2 трлн сумнан артыгы

юлны турыдан-туры эксплуатацияләүдән килгән файда

711 млрд сум -

төзелеш тармагы продукциясенә өстәмә заказ, ул инде төзелеш процессында ук Россиянең тулай эчке продукты үсешенә үз өлешен кертте

420 млрд сумнан артык

өстәлгән тулаем бәя үсешен торак пунктларны зур шәһәрләргә тоташтыру нәтиҗәсендә **ИКЪТИСАД ТАРМАКЛАРЫНЫҢ ҖИТЕШТЕРҮЧӘНЛЕГЕН ҮСТЕРҮ ХИСАБЫНА** алырга мөмкин булачак

360 млрд сумга якын

өстәлгән тулаем бәя үсешен **ЮЛ ОПЕРАТОРЫ** – «Автодор» компанияләр төркеме үзенең икътисади эшчәнлеге хисабына **ТӘЭМИН ИТӘЧӘК**

250 млрд сум -

пассажирлар, йөк җибәрүчеләрнең вакытын экономияләү нәтиҗәсендә алынган файда

20 ел эчендә туристлык тармагында өстәлгән тулаем бәя үсеше

44 млрд сум

тәшкил итәчәк

* *Стратегик эшләнмәләр үзәге мәгълүматлары буенча, 2022 елга булган бәяләрдә*

Сәяхәтләр өчен яңа М-12 юлы уңайлымы? Әлеге сорауга җавап табу, магистральнең туристлык потенциалын үз күзләре белән күреп бәяләр өчен, «Татарстан» журналы хәбәрчеләре тиз генә юлга җыенды. РФ Президенты Владимир Путинның «Нева» М-11 һәм «Көнчыгыш» М-12 трассалары тирәсендә автотуризмны үстерү буенча «юл картасын» эшләү бурычын редакциябез башкарып чыкты.

Фото: РФ Президентының рәсми сайты

ВЛАДИМИР ПУТИН, РФ ПРЕЗИДЕНТЫ:

– БЕЗ БӨТЕН ИЛ АША УЗА ТОРГАН ЮЛЛАРНЫ ТӨЗЕДЕК ҺӘМ ТӨЗҮНЕ ДӘВАМ ИТӘБЕЗ: ПЕТЕРБУРГТАН МӘСКӘҮГӘ КАДӘР ҺӘМ АЛГА ТАБА – КӨНЧЫГЫШКА. ӘЛБӘТТӘ, БУ ТРАССАНЫ МӨМКИН КАДӘР КҮБРӘК КЕШЕ ФАЙДАЛАНА АЛЫРЛЫК ИТЕП ҮСТЕРЕРГӘ КИРӘК: КЫЗЫКЛЫ УРЫННАРГА, КҮРЕРГӘ ТЕЛӘГӘН ҖИРЛӘРГӘ ТИЗ АРАДА БАРЫП ҖИТӘРЛЕК БУЛСЫН.

ҺӘМ САЛАЛАР БУЕНЧА

«ТАТАРСТАН» ЮЛ КҮРСӘТКЕЧЕ

М12

КАЗАН

Маршрутыбызны билгелибез. Юл башы – Казан. Аннары М-12 юлы белән – Муромга. Бу 500 километрдан бераз гына күбрәк. Планда – Олы Кайбыч (Татарстан), Сергач, Арзамаска (Түбән Новгород өлкәсе) кагылып чыгу, Муромда (Владимир өлкәсе) Ока яры буйлап йөреп кайту. Туристлар игътибарын җәлеп итәрлек башка урыннарны юл күрсәткечләре әйтеп җибәрер, дип өметләнәбез.

Димәк, юлга!

Юл күрсәткечләре сәфәр башында ук ышанычны акламады. Шәһәрдән чыккан җирдә түләүсез трассаларга юнәлеш күрсәткәннәре генә күзгә чалына. Мәскәү ягына юл тотканда, аларга ышанып барсаң, үзең дә теләмәстән, борын-борыннан билгеле М-7 трассасына эләгәсең. Ни гаҗәп, телефондагы навигатор безне шул юлга гына җибәрә. Нишләргә? «Автодор» сайтында М-12 картасының сыйфаты начаррак вариантын гына таптык, анда трассага керү-чыгу урыннары схематик рәвештә генә күрсәтелгән. Түләүле трассага Югары Ослан районында – Вахит авылы янында чыгарга карар кылдык.

Казан–Ульяновск юлыннан, Кама Тамагы ягына борылып, берничә минут баруга каршыбызда үзебез көткән «М-12» Восток» язуын күрәбез. Ә трассага нәкъ менә Мәскәү юнәлешендә керү

Фото: Александр Ефремов

ЗУР ПОДБЕРЕЗЬЕ

урыны кайда? Мондый юл тактасын таба алмыйбыз. Бер мизгелгә аптырашта калган кебек булабыз. Ул арада түләүле автобанга килеп тә керәбез, ләкин бөтенләй башка якка... Казанга таба.

Кирегә борылыш мөмкин булган иң якын урын – Казан аэропорты тирәсендәрәк. Навигатор хатасын төзәтер өчен планлаштырылмаган кырык километрны (борылышка кадәр һәм кирегә) узарга мәҗбүрбез. Ләкин кәефсезләнергә өлгерми дә калабыз. Идел аша мәһабәт күпер, идеаль бетон юл, өстәвенә йөк машиналары агымының әсәре дә юк! М-12 – шәп юл!

Сәяхәтебез башланып, бер сәгать үтүгә, каршыбызга «Күпфункцияле зона» күрсәткече очрый. Автомобилеңә ягулык салган арада юл буендагы кафеда каһвә тәмләп алу «уңайлы туризм» төшенчәсен искә төшерә. Юлыбызда очраган беренче ял зонасында барысы да шәп булуын шәхсән раслыйбыз: каһвәсе дә, снеклары да, ягулык салу станциясе дә, уңайлы бәдрәфләре дә, хәтта душы да бар. Ял итеп, тамак ялгап алгач, Олы Кайбыч тарафына борылабыз.

Юл буендагы «Олы Кайбыч» күрсәткече маршрутыбызның беренче ноктасына килеп җиткәнебезне искәртә. Башка бернинди мәгълүмат юк, димәк, потенциаль турист аны узып китәчәк. Ләкин Кайбыч районында сәяхәтче карарлык һәм ял итеп алырлык нәрсәләр дә бар икән.

Фото: Аскар Сабиров, Александр Ефремов

ТЕГЕРМӘН КАНАТЛАРЫ АСТЫНДА

Евгения Чеснокова

Яшел үләнле иркен ишегалдында горур басып, агач йортлар өстенә киң канатларын җәйгән тегермән Дон Кихотны искә төшерде. Ләкин М-12 Испаниягә алып бармый (әлегә!), аның каравы ул Татарстанның Кайбыч районы аша уза. Ә мондагы Зур Подберезье авылында без ачык һавадагы гадәти булмаган музейга юлыктык...

Үткән гасырлардагы игенчелек һәм авыл көнкүреше музей-туристлык комплексына (дивардагы элмә тактада шулай диелгән) җиңел генә эләгеп булмады: монда экскурсияләргә алдан язылырга кирәк икән. Ләкин безгә бәхет елмайды. Кемдер капка ярыклары аша эчке якны карарга маташкан чит кешеләр төркемен күргән һәм, уяулык күрсәтеп, хәбәр иткән. Шуңа күрә 10 минуттан яныбызга мотоциклында Сергей Шапкин килеп туктады.

Сергей Михалыч – музейны карап торучыларның берсе икән. Үзенә күрә уникаль кеше булып чыкты ул. Мәсәлән, арбалар ясый белә. Гомумән, бөтен нәрсәгә кулы ятып тора. Безгә музей турында да бик күп кызыклы нәрсәләр сөйләде.

Бу музейны 2019 елда ачалар, аны оештыру эшләре белән биредә туып үскән, ә хәзер Россия Фәннәр академиясе президенты урынбасары булган Пётр Чекмарёв шөгыльләнгән. Пётр Александрович заманында Подберезье колхозын җитәкләгән булган, димәк, авыл тормышына кагылышлы бөтен нәрсәне белә.

Кунаклар XVIII–XX гасыр традицион крестьян көнкүреше детальләрен күрә

МУЗЕЙНО-ТУРИСТИЧЕСКИЙ КОМПЛЕКС
ЗЕМЛЕПАШЕСТВА И СЕЛЬСКОГО БЫТА ПРОШЛЫХ ВЕКОВ
ҮЗГАН ГАСЫРЛАРДАГЫ АВЫЛ ТОРМЫШЫ
ҺӘМ ИГЕНЧЕЛЕК БУЕНЧА МУЗЕЙ-КОМПЛЕКС

алсын өчен, бирегә экспонатларны бөтен ил буйлап җыйганнар. Сабан, чәчкеч, төрән, арба, чаналар... Амбар стенасында – агач камыт, ишегалды уртасында – чып-чын кое.

Әмма туристларны, әлбәттә, беренче чиратта тегермәннәр кызыксындыра. Биредә ике зур җил тегермәне һәм бер су тегермәне бар. Эчкә үтеп, зур тегермән ташларын якыннан күрергә, механизмнарны аңларга тырышып карарга була...

Музей янында агымсу юк, димәк, су тегермәне күргәзмә экспонат кына булып тора, ә менә җил тегермәннәре – эшкә яраклы хәлдә. «Канатлары әйләнә», – дип ышандырды безне Сергей Михалыч. Дөрес, хәзер тегермәннәр тормозга куелган, аларны бик зур бәйрәмнәрдә генә эшләтеп алалар – мәсәлән, 2021 елда Зур Подберезье музеена Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов килгәч, аңа он тартуның бөтен процессын күрсәткәннәр, дип сөйлиләр.

Музейның барлык экспонатлары да ачык һавада түгел. Монда, мәсәлән, элекке заманнардагы крестьян көнкүрешен чагылдырган авыл өенә кереп карарга мөмкин. Анда исә 1825 елгы самовар да, шулай ук эшкә яраклы туку станогы да бар. Борынгы сандыкка да урын табылган – сандыксыз ызба була димени?!

Хуҗалыкның икенче башындагы ике катлы агач йортта ядкәрләр тагын да күбрәк. Монда совет чоры көнкүреше тарихын да күзәтергә мөмкин. Болдырда 1960 нчы еллар «кунагы» – бензоколонка (аны, Сергей Михалыч әйтүенчә, Ульяновскидан алып килгәннәр). Телевизор, үтүк, төрле елларда чыгарылган фотоаппарат коллекцияләре бар. Арада авыл хуҗалыгы уңышлары турында хисап тоткан совет газеталарының баш мәкаләләре күзгә чалына, ә бер өстәлдә самогон аппараты кукраеп утыра – кем өчендер ул көнкүрешнең мөһим элементы булган, хәтта авылда гына да түгел...

КОЛАҢГЫГА – БАЛЫККА!

Бирегә балык тотарга Саратовтан, Мәскәүдән, Краснодардан киләләр. Хәтта Мурманскидан да... Юк, бу Сахалин да, Камчатка да түгел. Адресын истә калдырыгыз: Татарстан, Кайбыч районы, Колаңгы станциясе, Озерная урамы.

Монда балык тотарга килүчеләрнең адреслары билгеләнгән Россия картасы ниндидер визит карточкаларыннан яхшырактыр, мөгаен. Кайдан гына килмәгәннәр икән! Иң ерак нокта – Салехардтан да көнчыгыштарак.

Шулкадәр ерактан килүнең ни мәгънәсе бар? Балыгын тоттырып, мондагы сәхнәгә бастырып фотога төшергән балыкчы малай да безнең сорауга аптырабрак калды: җавап бирмәсәң дә аңлашыла кебек бит! Ул үзе бирегә Идел буенда урнашкан Карамалы Таудан килгән. Әти-әнисе белән. Үзләрендә – зур елга, ә монда – зур балык.

Колаңгыга балык тотарга йөрүчеләр иң зур табыш турында сөйләшүгә караганда конкретлыкны өстен күрәләр: социаль челтәрләрдә балык күтәреп фотога төшкән бәхетлеләргә көнләшеп карыйсың. Алынган тәэсирләр турында сокланып укыйсың! «Ике тәүлеккә 30 кг лимит куелган иде, ә без 29 кг гына тоттык», «Рәхәтләнеп балык тоттык! Ике килолы сазан тартып чыгардык!» Бөтен нәрсәне ташлап, бер сәгатькә генә булса да монда киләсе килә!

– Балык тотуның беренче сәгате бездә бушлай, – дип кызыктыра балык хуҗалыгы хезмәткәре дә. – Әгәр тотсагыз, балык өчен генә түлисе.

Барысы да дөрес. Тик сез миңа бер килолы карп эләккәч, сәгатем тулды дип, тиз генә җыенып киткән балыкчыны күрсәтегез әле... Юк андыйлар. Без дә булдыра алмадык...

– Балыкны үзебез үрчетәбез, буада балык кимемәсен дип, гел тикшереп торабыз, – дип аңлата Кайбыч балык хуҗалыгы генераль директоры Радик Җамалетдинов. – Тотылган балык һичшиксез үлчәнә. Бер тонна тотыла икән, шуның кадәр үк балык буага җибәрелә... Ләкин осталыктан башка монда да балык эләктереп булмый. Балык тоту шул ягы белән кызык та бит.

Балыклы елга-күлләр, буалар әз түгел, тик барыбер Колаңгыга киләләр. Монда яхшы чиркән өчен генәме?

– Чөнки монда шәп! – дип аңлата балыкчыларның берсе. – Миңа гына түгел. Гаиләсе белән, дуслары белән



килүчеләргә дә рәхәт монда. Сез биредәге кояш баешын күрсәгез иде! Ә күрше буалардагы аккошларны? Алар монда зоопарктагы шикелле бер-ике пар гына түгел, йөзәрләгән! Ә мунчасы ни тора! Шәһәр ыгы-зыгысыннан җаның-тәнең белән ял итәсең.

Арендага алырга мөмкин булган барлык апартаментлар – су янында гына, беренче линиядә. Гаилә ялы өчен барлык уңайлыклары һәм кондиционерлары булган матур гына коттеджлар. Кечерәк йортлар да бар, шулай ук бөтен уңайлыклары белән. Ә инде спартан шартларына да риза булучылар өчен тагын да тыйнаграк йортлар төзелгән. Хуҗалар әйтүенчә, икенче катта террасасы булган йортларга ихтыяҗ арткан. Андый йортлар да очраклы гына төзелмәгән.

– Бер кунагыбыз ничектер, сездә барысы да әйбәт, тик тулы бәхет өчен терраса гына җитми, диде, – дип аңлата Радик Гомәрович. – Әйтик, мин балык тотканда, хатыным өске катта кояшта кызынып утыра алсын...

Хәзер чыннан да шулай. Ирләр кармак тотып утыра, хатыннар террасада кояш ванналары ала. Хәер, гүзәл затлар арасында да балык тотарга һәвәсләр җитәрлек икән, өстәвенә, алар өчен дә, балалар өчен дә балык тоту бушлай.

Бирегә ир-атлар компанияләп тә килә, алар өчен иң мөһиме балык тоту да түгел, ә тынычлыкта рәхәтләнеп аралашу, ял итү. Андыйлар кармак тотып озак утырмый, монда балыкны сатып алып та була – һәрвакыт һәм теләсә нинди күләмдә, күпләп һәм ваклап. Кайбыч карплары башка хуҗалыкларда үстерелгәннәренә караганда тәмлерәк, диләр. Сүздә генәме икән?

– Без карпларга ашлык ашатабыз – бернинди эрзац-өстәмәләр юк, – дип аңлата Радик Җамалетдинов. – Безнең буалар агып тора, ике елга – Зөя белән Бөрлә арасында урнашкан. Суны елгалардан алабыз, аннары елгаларга агызабыз. Су туктап тормый, шуңа күрә буа балыгына хас ләм тәме безнекендә юк.

Тикшереп карау максатыннан без әле генә тотылган карпны каймакка салып пешереп карадык. Телеңне йотарлык тәмле килеп чыкты! Сезнең дә тәмләп карыйсыгыз киләме? Ⓣ

Ничек барырга: Казаннан Казан – Ульяновск трассасы буенча яисә М-12 буенча Колаңгы борылышына кадәр.
Юл өчен киткән вакыт – 40 минут – 1 сәгать 10 минут.

Тел.: 8 (987) 403-51-03

Сайт: кайбицкийрыбхоз.рф

Фото: Айдар Мөшәрәповтан, кайбицкийрыбхоз.рф сайтыннан. РЕКЛАМА

Олы Кайбычтан соң Сергач ягына юл тотабыз. Татарстанда тулы бак ягулык салу һәм, гафу итегез, суны азрак эчү кирәклеге турында тәҗрибәле машина йөртүчеләрнең киңәше бик урынлы икән. Татарстан Республикасыннан соң М-12 юлында ягулык салу станциясе күренми, ял итү зоналары хакында әйтеп тә торасы юк. Ата-бабадан калган гадәт белән юл буендагы куак төбенә туктау варианты шундук кире кагыла – трассадан борылыр-туктар урын таба алмыйсың. Ә трассадан чыгып киткән җирләрдә, диярсез? Олы Кайбыч белән Сергач арасындагы ике йөз чакрымда андый урыннар икәү генә: берсе – Канаш, икенчесе – Шөмерле ягына.

Алда – Сергач. Юл тактасындагы язу ял итеп алырбыз, яңа тәэсирләр алырбыз дигән өметләр уята. Иң әүвәл шуны искәртәбез: М-12 трассасыннан борылып, берничә метр узуга, үткән гасырга эләккәндәй булабыз. Россиянең ике бәласе бар… дигән әйтем искә төшә. Хәер, күңелсезләнергә тырышмыйбыз: Сергачка хәтле ун-унбиш чакрым гына барасы ла…

Фото: Александр Ефремов, Әскәр Сабиров

СЛУЖБА

СЕРГАЧ

Фото: Александр Ефремов, Әскәр Сабиров



СЕРГАЧ. КИЧӘГЕ БҮГЕНГЕБЕЗ

Әскәр Сабиров

Сергачка килеп керүгә, билгесез бер архитектор ясаган «җәүһәр» – аю скульптурасына юлыгасың. Аннары тагын берсенә, икенчесенә... Ә-ә, аңлашылды, аю почмагы икән, дип нәтиҗә ясап өлгерә ясалма булмаган интеллект, машина чираттагы түмгәккә эләгеп сикерткәндә...

– Аю шәһәр символы бит, ул шәһәр гербында да сурәтләнгән, – дип үпкәсен белдерер үтеп баручы шәһәр кешесе. Һәм, һичшиксез, борынгырак заманнарда җирле халыкның, аюны биергә өйрәтеп, алар белән кала-салалар буйлап тамашалар оештырып йөри торган табышлы кәсеп белән шөгыльләнүләре турында да сөйләр. Хәтта Европа буйлап та гастрольләрдә йөргән алар. Алай гына да түгел, Наполеон сугышы вакытында французларны куркытыр өчен, Сергачта хәтта махсус аюлар полкы да оештырганнар дип әйтәләр...

Тирә-яктагы урманнардан аюлар күптән юкка чыккан, ә аю почмагы истәлек булып калган. Кала башка күп кенә шәһәрләргә охшаган кебек: гыйбадәтханә, төп мәйданда гипстан ясалган Ленин сыны, үзәк урамда сәүдәгәр йортлары, бераз читтәрәк «хрущевка»лардан торган микрорайон, Мәскәүдәге Казан вокзалы һәм Ленин мавзолее авторы – архитектор Щусев үзе проектлаган вокзал бинасы да булган тимер юл станциясе, хәтта дендрарий да бар биредә.

Ләкин барысы да ничектер таушалган, тузанлы, күңелсез. Сәүдәгәр йортларына ремонт соңгы мәртәбә революциягә кадәр үк ясалган кебек, җимерек юллар исеме үзе үк әйтеп торган Пьяна елгасыдай боргаланып-боргаланып бара, ә Совет урамына кыек-мыек түшәлгән таш арасыннан чүп үләне баш калкыткан. Ирексездән патша заманына ук караган юл күрсәткечендә язылган сүзләр искә төшә: Сергач Түбән Новгород гу-

бернасының иң ярлы шәһәре, анда арзан поташ җитештерәләр һәм яхшы чабаталар үрәләр.

Юк, хәзер, әлбәттә, узган гасыр башы түгел, алга китеш күз алдында. Интерьеры белән 90 нчы еллар уртасын хәтерләткән Сергач кибетләрендә җаның ни тели, шул бар. Бәяләр дә мондагы халыкның сатып алу сәләтен теләсә кайсы статистикадан төгәлрәк итеп күрсәтеп тора. Айфон өчен «зарядка»ны хәбәрчегез, мәсәлән, 190 сумга гына сатып алды – могҗиза түгелмени?!

Ә Сергачта килгән кунакка хезмәт күрсәтү ничек соң? Шәһәр буйлап ашарга туктарга урын эзләп йөргәннән соң, үзәктә шактый яңгыравык исемле «Русь» кафесына тап булдык. Өстәлләр, салфетка, официантлар – барысы да бар, тик бәдрәфтә су гына юк. Аның каравы, меню ярыйсы күренә – сыер итеннән тәмле генә гуляш, бәрәңге боткасының да бәясе арзан кебек. Ашарга заказ бирәбез, тик нигәдер сыер ите урынына дуңгыз итеннән гуляш китерәләр.

– Ә нәрсә булган? Бездә сыер итен дуңгыз итенә алыштырган вакытлар булгалый, – ди, аптырап калган клиентлардан чебенне куган кебек котылырга теләгән официант, хатасын төзәтергә дә уйламыйча.

Совет чорының 80 нче яисә болгавырлы 90 нчы елларымы? Бу юлы кая эләгүебезне дә аңламыйча, тизрәк бу кунакчыл шәһәрдән чыгып китү җаен карыйбыз.

Хәер, тарихыбызның әле күптән түгел генә узган чорын күрәсегез килсә, Сергачка рәхим итегез!

Сергачка барып җитү җиңел. Ә менә шәһәрдән М-12 трассасына чыгу күпкә кыенрак икән. Навигатор да киреләнә: һич кенә түләүле юлны күрсәтергә теләми. Рәхәтләнеп адашып йөргәннән соң, барыбер трассага тап булабыз. Алда – Арзамас шәһәре. Ләкин Сергачтан ерак түгел, бары 80 километрда гына Пушкин иҗатында яктыртылган Болдино авылы калганын без белмибез, бу турыда күрсәткечләр дә дәшми...

М-12 трассасы буенча Сергачтан Арзамаска кадәр 130 чакрым икән. Якынча бер сәгатьлек юл – һәм менә без тарихи шәһәрләребезнең берсендә. Ләкин юл күрсәткечләре һәрвакыттагыча кыска язылган – торак пунктның исеме генә, туристны кызыктырырлык бернинди мәгълүмат юк.



Фотолар: Әскәр Сабиров, Александр Ефремов


АРЗАМАС

АРЗАМАС. КУПШЫ АГАЧ ЙОРТЛАР КАЛАСЫ

Әскәр Сабиров

Уеп бизәкләнгән тәрәзә йөзлекләре, нык агач йортлар, җыйнак кына коймалар белән тотып алынган уңайлы ишегаллары. Тыныч, рәхәт һәм бернинди ыгы-зыгы да юк – хыял бит бу! Тулы бәхет өчен яшел чирәмдә ашыкмыйча чемченеп йөргән каз бәбкәләре генә җитми сыман. Без – Арзамаста!



– Минем дә монда яшисем килә, – ди үз мегаполисының ыгы-зыгысыннан туйган шоферыбыз Александр.

Әлеге гади дә, купшы да гүзәллеге белән инде гасырдан артык хозурланып утырган су башнясы да аның белән тулысынча килешә төсле. Өстәвенә, әлеге манзараны тулыландырып казлар да пәйда була – алар урам буйлап хуҗаларча атлап йөри һәм, озын муеннарын сузып, чит-ятларга ысылдарга әзер сыман.

ПРОЛОМНАЯДАН АЛЫП ГАЙДАРГА КАДӘР

Аңлашыла ки, казлар чын түгел. Әмма алар XIX гасыр азагында гөрләп утырган шәһәрнең яңадан торгызылган идиллик картинасына искиткеч туры килеп тора.

– Элек Арзамас башкалада оештырыла торган каз сугышлары өчен үрчетелә торган кошлары белән дан тоткан, – дип, бик теләп аңлата безгә җәяүлеләр урамында әлеге бронза сыннарның пәйда булу тарихын бер юлдашыбыз. – Аларны Мәскәүгә йөзәрләп

Фото: Әскәр Сабиров, Александр Ефремов

алып киткәннәр. Әлбәттә, М-12 юлыннан түгел, җәяүләп куып алып барганнар. Юлда суелмасын өчен, тәпиләрен балавызлый торган булганнар. Башкалага кадәр дүрт йөз чакрымны кошкайлар шуңа шактый ансат үткән.

Җәяүлеләр урамы – ил тарихы һәм мәдәнияте өчен аерым әһәмияткә ия җирлекләр исемлегенә кергән шәһәрнең иң борынгы урамы ул. Арзамаска биш йөз ел чамасы – Карл Маркс урамына да шуның кадәр ук, диләр. Дөрес, элек урам үзенчәлеклерәк исем белән – башта Проломная, аннары Пушкарская дип аталган....

Урам тарихы – шәһәр энциклопедиясе ул. Йорт диварындагы язу да, Арзамас һәм аның халкы турында экскурсия үткәрүчедән ким сөйләми торган ачык һавадагы мини-музей да моңа ишарәләп тора. Менә нәрсәләр мәгълүм булды безгә: күршедәге тыкрыкта гына Аркадий Гайдар туып үскән, фашизмга каршы сугыш елларында Мәскәү һәм Бөтен Русь Патриархы булган епископ Сергий да тумышы белән шушыннан. Генерал-легенда Дмитрий Карбышев исә 1918 елда биредә Кызыл Армия штабында эшләгән....

ВОСКРЕСЕНСКИЙ СОБОРЫ. БАШКАЛА ДӘРӘҖӘСЕНДӘГЕ ЧИРКӘҮ

Гаҗәпләндерерлек нәрсәләр янәшәдә генә. Провинция урамы кинәт безне хәтта Европа башкалалары да көнләшерлек мәйданга алып чыга. Мәйданның бизәге булган матур Воскресенский соборы нәрсәсе беләндер Хельсинки үзәгендәге Кафедраль соборны хәтерләтә. Дөресрәге, соңгысы кай ягы беләндер Арзамастагы Воскресенский соборына охшаган – безнеке зуррак, нәфисрәк һәм борынгырак, аны Наполеонны җиңү хөрмәтенә 1814 елда ук салганнар.

Воскресенский соборының язмышы – үзе бер тарих.

– Ул беркайчан да ябылмаган, хәтта совет чорында да, – дип сөйли Арзамасның кыйбатлы кафесында кыяр фрешы эчеп утырган Галина исемле ханым. – Ышанмыйсызмы? Мине шунда чукындырганнар!

Шулай да бөтен нәрсәдән хәбәрдар төбәкне өйрәнүчеләр ачыклык кертә: дин әзәрлекләнгән 1930 нчы елларда Воскресенский соборы ябылып тора. Әмма ышанырлык булмаса да, большевиклар һәм дингә каршы көрәшүчләр гыйбадәтханәне таламый һәм җимерми, шул рәвешле аның борынгы күркәмлеге сакланып кала. Биредә атеизм музее ачыла, ул бинаның үзе өчен дә, аның уникаль интерьерлары өчен дә сак грамотасы булып тора.

Әмма чиркәү музей булып та чагыштырмача озак тормый. Бу вакытта инде каты авырудан интеккән Патриарх Сергий сугыш

бетәр алдыннан Воскресенский соборын дин тотучылар өчен ачуны сорап хакимияткә мөрәҗәгать итә. Патриархның үтенечен игътибарсыз калдырмыйлар, дөрес, аның вафатыннан соң гына. Югары карарны Сталин үзе кабул иткән, диләр. Воскресенский соборында беренче гыйбадәт 1947 елда уздырыла.

Узган гасырның 80 нче еллары азагына кадәр бу чиркәү илдә эшләүдән туктамаган иң зур гыйбадәтханә булган, дип сөйлиләр. Гаҗәп түгел, чөнки танылган реставратор Николай Померанцев: «Чиркәү архитектурасы ягыннан Арзамас – XVIII–XIX гасырларда башкала масштабындагы корылмалары булган шәһәр, алар янында хәтта Мәскәү чиркәүләре дә провинциаль булып күренә», – дип язып калдырган.

Су башнясы.

Воскресенский соборы.



Изге Николай Хатын-кызлар монастыре.

МОНАСТЫРЬГА ИКӘН – ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫКЫНА ГЫНА!

Арзамасны 33 чиркәү шәһәре дип йөртәләр. Революциягә кадәр биредә 36 гыйбадәтханә булган. Бүген егермедән артыгы эшли, барысын да карап чыгар өчен бер атна да җитмәячәк.

Безнең киңәш – һичшиксез Воскресенский соборына керегез. Диндар кешеме сез, юкмы – биредәге уникаль фрескаларның матурлыгы сезне барыбер таң калдырачак. Соборны атаклы Александр Ступинның Арзамас рәсем сәнгате мәктәбе шәкертләре бизәкләгән бит. Чиркәү алтарендагы өстәлнең Патшалар капкасын бизәп торган иконалар исә – сынлы сәнгать профессоры Николай Алексеев эше, Исаакий соборын да соңрак ул бизәкләгән.

Һәм, һичшиксез, XVI гасырдан бирле могҗизалы иконалары белән дан тоткан Свято-Николаевский хатын-кызлар монастырен карау мөмкинлеген кулдан ычкындырмагыз. Ерак барасы түгел – ул Собор мәйданында гына урнашкан. Теләгән һәркем керә ала, хәтта ир-атлар да. Бары тик күбрәк экияттәге тиремкәйләрне хәтерләткән хөҗрәләр янында гына: «Керү бары тик монахларга гына», – дигән таләпчән язу каршы ала.

Борын заманнарда монастырь үзенең монашкалары сатуга дип теккән итекләр белән дә дан казанган. Бүген инде биредә итек текмиләр, ә менә бакчаларында үстерелгән үрентеләрне сатып алырга була. Бөтен җир чәчәккә күмелгән, хәтта бәдрәф диварларында да гөлләр үсә. Бик матур!

ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ: ПАТРИАРХЛАР

Арзамас – рус патриархлыгы музее булган Россиядә бердәнбер шәһәр. Менә ул, шул ук Собор мәйданында, Воскресенский соборының подвалларында урнашкан.

Биредәге тәбәнәк түшәмнәр, тупас таш диварлар шундук җитдиләндерә. Борынгы кулъязма төргәкләре, төрле чор патриархларының киемнәре, берничә гасырлык чиркәү китаплары... – барлык бу экспонатларны тын да алмыйча карыйсың.

Менә витринада Россиядә патриархлыкны булдыру турында Константинополь Соборының 1590 елгы уникаль Грамотасы! Янәшәдә – Борис Годунов чорындагы беренче Россия Патриархы Иованың мантиясе һәм догалыгы. Ә менә бусы – инде безнең көннәр диярлек, Патриарх Алексий I пана-



Россиядә Патриархлыкны гамәлгә кую турында Константинополь соборын грамотасы, 1590 ел.

Арзамас магистраты.



Патриарх Алексий I панагиясе.

Патриарх Кирилл митрасы.

гиясе, янәшәдәге фотосурәттә ул беренче совет космонавтын сәламли. Тагын бер витрина, пыяла астында – XVII гасырда Патриарх Никон киеп йөргән мантия һәм тән чылбыры. Болары – хәзерге Мәскәү һәм Бөтен Русь Патриархы Кириллның митрасы, таягы һәм мантиясе...

ГАЛӘВЕТДИН МӘГАРӘСЕНДӘГЕ БАЛЧЫК ҖӘҮҺӘРЛӘР

Әйе, Арзамастагы Собор мәйданы кызыксынучан турист өчен Галәветдиннең хәзинә тулы мәгарәсенә тиң. Чиркәү һәм монастырьларда йөрергә яратмыйсызмы? Хатын-кызлар монастыре янында тагын бер хәзинә – XVIII гасыр архитектурасының тиңдәшсез ядкәре булган Арзамас магистраты урнашкан. Сүз уңаеннан, бу – Россиядә шул чордан сакланып калган бердәнбер магистрат бинасы.

Архитектура җәүһәрләре белән хозурлану да туйдырса, Арзамас базарына рәхим итегез. Инде үзегез дә сизенәсездер, сәүдә рәтләре дә борын-борыннан шул ук Собор мәйданында урнашкан. Арзамас һәм күршедәге Дивеево осталарының балчык эшләнмәләре биредә инде ике гасыр буе сатыла.

– Бу бит кул эше. Аны сатып алмыйсыз икән, димәк, Арзамаска килмәгәнсез дә! – дип аптыраште калдыра безне балчык раритетлар сатучы Татьяна.

Сатулашуның нәтиҗәсе шәп: без Арзамаста булдык, дип авыз тутырып әйтә алабыз хәзер!

АРЗАМАС

Арзамастан М-12 юлына ничек чыгарга? Мөгаен, бу безнең өчен юлда иң катлаулы квестка тиң башваткыч булгандыр. Навигатор, үзсүзлеләнеп, һаман түләүсез юлга чыгара, җирле халык аңардан әллә ни аерылмый, ә Арзамас үзәгендәге һәм шәһәр читендәге күрсәткечләрдә М-12 юлы традицион рәвештә юк. Бер машина йөртүчегә рәхмәт – безне «Мазда»-сы артыннан иártеп, тиешле урынга кадәр озатып куйды.

Арзамастан Муромга кадәр 130 километр, шулай ук бер сәгать чамасы вакыт китте. Илья Муромецның туган җирен үтеп китү мөмкин түгел: шәһәргә керү юлында Ока елгасы аша салынган челтәр күпер – иң яхшы күрсәткеч.

Фото: Александр Ефремов

МУРОМ
Н. НОВГОРОД
МУРОМ
МОСКВА
ЧЕБОКСАРЫ
КАЗАНЬ
40

Фото: Эскар Сабиров, Александр Ефремов



МУРОМГА. ИЛЬЯ МУРОМЕЦ ЯНЫНА

Әскәр Сабиров

Заманча архитектура могҗизасы – Ока елгасы аша сузылган атаклы челтәр күперне күрәсегез киләме? Димәк, сез Муромга юл тотарга тиеш. Ә Изге Петр һәм Феврония каберен күрер өчен шулай ук – Муромга. Әкият баһадиры Илья Муромец турында риваятьләр тыңларга, сөйләгәннәренчә, ул туган йортны күрергә? Ул вакытта да, һичшиксез, Муромга барыгыз!

Тарихка бай, Казанның яшьтәше диярлек бу шәһәрдә килеп керүгә, безне Илья Муромец каршы алды. Кулына шәһәрнең истәлекле урыннары исемлеге язылган төргәк тоткан экият батыры безне ат өстенә утырган килеш каршылады – моннан да яхшы экскурсоводны табып та булмыйдыр. Исемлектә иң беренче урында – Илья Муромец үзе. Бу юлы без аны Ока буендагы паркта очраттык. Кайберләребез аның буйсынына, һәйкәлнең сәнгати эшләнешенә сокланып торган арада, башкаларыбыз Ока елгасы яр буендагы манзара белән хозурланды – чыннан да бик матур биредә!

Илья Муромец-һәйкәл белән танышканнан соң, батырның туган йортына юл тоттык. Белешмәлек адресны Карачарово авылы, Карачарово Троица сөзәклеге дип күрсәтә. Ерак барасы түгел икән, бүген бу урыннар Муром шәһәре чигенә кергән. Утарда төтен юлы булмаган мичле, тупасрак, гади һәм тәбәнәк итеп салынган кышкы өйне, кәс түбәле кар базын, җәй өчен такта түбәле бура йортны күрдек. Риваятьләргә караганда, Илья Муромец 33 яшенә


Изге Троица хатын-кызлар монастыре.

кадәр хәрәкәтсез, гарип булып яшәгән, ә анннары баһадир көче туплана башлаган утар нинди икән ул!

Борынгы каһарманның йорты, аңлашыла ки, бары тик реконструкция генә: елъязмаларда язылганча, батыр XII гасырда яшәгән, ул вакыттагы йортлар бүгенгә кадәр берничек тә сакланып кала алмый. Ә Илья Муромец үзе чыннан да булганмы соң?

Скептиклар еш бирә торган әлеге сорауга җавап итеп, экскурсоводлар 1980 нче елларда галимнәрнең Киев-Печера лаврасындагы Илья Муромец каберен тикшерүләре турында сөйләрләр, анда йөрәгендәге ярадан үлгән батыр кыяфәтле сугышчы ята дип ачыклаулары хакында да әйтерләр. Моннан тыш, сугышчының бала вакытында аяклары параличланган булуы да ачыкланды диярләр…

Алга таба тагын бер атаклы урын – Изге Троица хатын-кызлар монастырена юл тотабыз. Бирегә диндарлар, алар гына да түгел, гади халык та гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык символы Изге Петр һәм Февронииягә табыну өчен килә. XVII гасырда ук нигезләнгән монастырь матурлыгы һәм мәһабәтлеге белән таң калдыра. Муромда архитектуралары, бизәкләре белән сокландырган гыйбадәтханәләр шактый күп, әмма Троица монастыре хәтта алар арасында да аерылып тора. XVII гасыр Муром осталары тудырган җәүһәрләр – төрледән-төрле бизәкле чынаяк кирпечләр Троица соборына аерым бер нәфислек бирә. Соборның стилен рус үрнәге дип атыйлар.

Монастырь территориясендә тагын бер кыйммәтле тарихи ядкәр бар. Сергий Радонежский гыйбадәтханәсе, ул агачтан яңа ясалган храм түгел. Вакыт йогынтысында каралып киткән гөмбәзләр һәм диварлар аңа егерме, йөз, хәтта ике йөз яшь генә булмавы турында сөйли. Гыйбадәтханә XVIII гасыр башында Красново авылында салынган, ә Муромга аны 1975 елда күчергәннәр. Бу рус агач архитектурасының иң кыйммәтле һәйкәле.

Һәм тагын Илья Муромец турында. Изге Троица монастырендa батыр җәсәденең бер өлеше – сул кулының бармагы саклана икән. Мөгаен, дошманга янаган бармагыдыр! Муромда Муромецтан башка бернишләп тә булмый! Хәтта чын «Илья Муромец» бронепоезды да бар, сугышта күп кенә фашистны һәм дошман техникасын юк иткән, ә үзе исән калган – чын батыр ул! Аңлашыла ки, «Илья Муромец» трактиры да бар, әмма ул күбрәк кыргый капитализмга һәйкәл кебегрәк – язу шаурма, кока-кола һ.б. турындагы алалы-колалы рекламалар арасында калган.

Тагын нәрсә карарга була? XIX гасыр йортларыннан торган Мәскәү урамы, сәүдәгәрләр урыны бу, борынгы су манарасы, чиркәү һәм монастырьлар... Борынгы Муром риваятьләргә, истәлекле урыннарга бай. Барып карагыз, үкенмәссез!



Сергий Радонежский агач храмы.

ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ

Муромнан чыгу юнәлешенә, өйгә таба юл алабыз. Без яңадан М-12 трассасына чыгабыз. Юл күрсәткече Казанга 517 км дип хәбәр итә. Шактый зур чакрымнар. Ләкин без бит М-12 автомагистралендә!

Алга таба тукталышларсызмы? Ә Иске Чүпрәле нәрсә? Юк, керергә кирәк, дибез без.

МУРОМ



ЧҮПРӘЛЕ РАЙОНЫ. ИҢ КУНАКЧЫЛ ТӨБӘК

Өйгә кайтканда юл һәрвакыт кыскарак тоела. М-12 трассасы өстенә зур итеп язып куелган «ТАТАРСТАН» баннеры «Татарстан» журналы экспедициясе әгъзаларын сокландырды да, сөендерде дә. Туган җиребездә башта безне Кайбыч районы каршы алды, аннары исә тагын бер газиз төбәгебез – Чүпрәлегә килеп җиттек: озын юлдан соң ял итеп алу да мәслихәт ич!

Алгарак китеп, шунысын да әйтү кирәктер: Чүпрәле районында авыл хуҗалыгы туристлыгын үстерү өчен шартлар менә дигән икән бит. Биредә теләгән һәркемне җиләк-җимеш үстерергә дә, тәмле сөт ризыклары әзерләргә дә, авыл мәктәпләре, балалар бакчалары, скверлары, парклары өчен үзенчәлекле урам җиһазлары ясарга да, яшәгән урынны туры мәгънәсендә гөлгә күмәрлек итеп авыл хуҗалыгы предприятиесе белән идарә итәргә дә өйрәтәчәкләр. Мәсәлән, Кече Чынлыдагы кебек.

Фото: Александр Ефремов

– Бөтен җирнең чәчәккә күмелүен бик яратам мин, – ди Барис Гафуров.

ЧӘЧӘККӘ КҮМЕЛГӘН ЧЫНЛЫ

Кече Чынлы ерактан ук балкып күренә – ул төрле төстәге петуния чәчкәләренә күмелгән.

– Үзебез утыртабыз, – ди «Чынлы» ҖЧҖ директоры Барис Гафуров, кызыл, ак, шәмәхә, алсу төстәге гөлләргә күрсәтеп. – Бөтен җирнең чәчәккә күмелүен бик яратам мин.

Авылдашлары исә үзләренең җитәкчеләренең һәр башлангычын күтәреп алырга гына тора. Чөнки нәкъ менә башта укытучы һәм мәктәп директоры булып эшләгән Барис Гафуров җитәкчелегендә предприятие республикадагы иң нык һәм икътисадый яктан тотрыклы хуҗалыкларның берсенә әйләнгән бит. Гафуров биредә, «Чынлы»да, ресурсларны саклый торган технологияләрдән алып хезмәткәрләр эшен гадел бәяләүгә кадәр – бар нәрсәдә иң алдынгы, нәтиҗәле ысулларны куллана.

– Бездә иң кызыклы Сабан туйлары үтә, иң шәп батырлар көрәшә, иң яхшы Яңа ел чыршылары бездә! – дип сөйләде безгә авыл халкы безне.

– Яңа ел алдыннан ишегалларын бизәүдә һәр гаилә дә катнаша, – дип раслый Барис Гафуров.

Һәм тагын әле Кече Чынлыда хезмәт сөючән, бик тырыш халык яши.

– Күп кеше сыер асрый, фермер хуҗалыклары да байтак, кемдер сөт, кемдер ит эшкәртә, бер фермер исә атлар үрчетә – аның 50 малкае бар! – дип горурланып сөйли авылдашлары хакында «Чынлы» җитәкчесе.

Авылда бөтен нәрсә җирле халык мәнфәгатьләрен кайгыртып эшләнгәндә ничек тырышмыйсың инде, дип җитәкчеләренә кушыла Кече Чынлы халкы да:

– Безнең мәктәп яхшы, көчле. Ә паркны күрдегезме әле?! Фонтаннар беләң! Ике мәчетебез бар, – дип санап китә алар. – ФАПны, почтаны ремонтладылар, модульле ветеринария пункты төзеделәр – анда безнең хайваннарны дәвалыйлар да, диагностика да үткәрәләр, чирләрне кисәтү буенча да эшлиләр... Болар барысы да авыл хуҗалыгы территорияләрен үстерүгә зур игътибар бирә торган федераль һәм республика программалары буенча гамәлгә ашырыла.

Ә монда ничек каршылаганны һәм сыйлаганны белсәгез икән! Чын менә, һәр кунакны туганнарыдай каршы алалар.

– Борынгы мишәр гореф-гадәте буенча бөтен ризыкны авыз итеп карамыйча сез китә алмаячаксыз! – дип елмая Барис Гафуров.

Һәм без сыйланабыз да. Кая килгәнебезне белеп килдек бит: Чүпрәле районы гербында тикмәгә генә ипи-тоз сурәтләнмәгәндер ул!

Альфред җәмәгате Фәридә белән бергә безгә уңышны да күрсәтте.

ДУВАН БАКЧАЛАРЫ: БАШКИСӘРЛӘР УРЫНЫНА – ҖИЛӘК

Рәхәтләнеп сыйланганнан соң, әлегә тулы составта Дуван бакчаларына юл тотабыз. Безне җир җиләге кырлары каршы ала – анда исә һәр җиләк уртача зурлыктагы помидор кадәр!

Кыр буена таралган җиләк җыючылар шундый зур җиләкне әледән-әле авызына озата һәм тәмләп ашап куя.

– Болар үзләре өчен җыеп алырга килүчеләр, – дип аңлата аларның бу гамәлен «Дуван бакчалары» кооперативы рәисе Альфред Хәйруллин.

– Алар бит җыйганнан күбрәк ашаячак!

– Юк, ашый алмаячак, – дип көлә Альфред. – Аны күп ашап булмый. Әйдәгез, үзегез дә җыеп карагыз әле!

«Татарстан» да җиләк җыючыларга кушыла. Һәркайсыбызның авызына бик зу-у-ур өчәр җиләк кереп китә. Әй тәмле дә соң! Тик... бүтән ашыйсы килми. Мөгаен, Чынлыда иртәнге ашны күбрәк ашап ташлаганбыздыр.

Альфред җиләк-җимештән кайнатма һәм башка тәм-том җитештерү белән җитәкчелек итүче хатыны Фәридә белән бергә безгә үзләренең җир җиләге, кура җиләге кырларын, алмагачларын күрсәтә... Әлеге җиләк-җимеш патшалыгының хуҗасы Альфред Хәйруллин Татарстанның Алтын йөзлегенә юкка гына кертелмәгән шул. Ул «Импортны алыштыру» номинациясендә бүләкләнгән.

«Дуван бакчалары» авыл хуҗалыгы кооперативы 2020 елдан бирле эшли. Алма, җир җиләге, кура җиләге, кара карлыган үстерәләр, кайнатма ясыйлар.

– Җир җиләге һәм кура җиләгенең гектарыннан 6–7 тонна уңыш алабыз, – ди Альфред Хәйруллин. – Алмаларның Россиядә чыгарылган сортлары, мәсәлән, «Беркутовское» дигәне, зур, кызыл, сусыл булып өлгерә. Үсентеләрне Мичуринскида сатып алабыз. Киләчәктә үз питомнигыбызны да оештырырга ниятлибез. Бик каты туңдырырга көйләнгән саклагычларыбыз да бар... Планнар күп әле...

Элегрәк исә Иске Дуван авылы үзенең башкисәрләре белән дан тоткан, диләр. Тик хәзер бу турыда хәтта Википедия дә хәтерләми. Ә менә Дуван җиләкләрен һәр җәйне әйләнә-тирәдәге бөтен шәһәр-авыллар искә төшерә... Сатып алучылар географиясенең киңлеге җиләк кырлары янына туктаган автомобиль номерларыннан да күренеп тора. Бирегә бөтен кеше тәмле җиләк җыярга дип килә.

СӨТ, КАТЫК, КЕФИР, МАЙ, ЭРЕМЧЕК, СӨТ ӨСТЕ, СЫР...

Чүпрәле җирендә бөтен нәрсә чүпрә белән кабарткандай үсә!

– Безнең җиргә таяк тыгып куйсаң, ул да тамырланыр, чәчәк атар һәм җимеш бирер иде, – дип кабатларга ярата район башлыгы Марат Гафаров.

Шунлыктан биредә сөт продукциясе дә яхшы «үсә». Сыерлар рәхәтләнеп тәмле үлән белән сыйлана, ә кечкенә генә «Исток» май-сыр җитештерү заводы бөтен районны сыйфатлы сөт продукциясе белән тәэмин итә.

– Без сөт өсте, каймак, катык, кефир, сыр, эремчек, атланмай җитештерәбез, – дип санап китә май заводын оештыручы Айрат Усманов.

Үзенең сөткә бәйле эшчәнлеген ул Иске Кәкерле авылындагы кабул итү пунктында халыктан сөт җыюдан башлаган булган. Хәзер исә инде еллык продукция җитештерүне 5,8 мең тоннага җиткерергә һәм 200 миллион сум керем алырга ниятли.

Завод иң заманча җиһазларда эшли, аның үз лабораториясе һәм әзер продукцияне саклау өчен суыткычлары бар.

– Ризыкларыбызның тәме һәм сыйфаты бик яхшы, безнең балачактагы кебек чын. Мин нәкъ менә шуңа ирешергә теләгән дә идем, – ди Айрат Усманов, безне сөт деликатеслары белән сыйлый-сыйлый.

– Җир җиләгенә сөт-катык-кефир-май-сөт өсте-эремчек-сыр кушсаң, нәрсә килеп чыга инде ул?..

– Бик тәмле булачак! – дип ышандыра безне директор. – Безнең бөтен продукция дә экологик чиста һәм бик сыйфатлы!

Аның сүзенә ышанмый хәлебез юк – барысыннан да авыз итеп карадык.

– Без сөт өсте, каймак, катык, кефир, сыр, эремчек, атланмай җитештерәбез, – дип санап китә Айрат Усманов.

УҢДА – КЫРЛАР, СУЛДА – КЫРЛАР...

Кояштай сары рапс кырлары буйлап «Чистай» холдингының иң уңышлы предприятиеләреннән берсе – «Чүпрәле Рассвет Агро» агрофирмасы биләмәләренә җилдерәбез.

– Бездә бик көчле һәм профессиональ команда эшли, – дип таныштыра «татарстанлыларны» кыр хезмәтчәннәре белән агрофирма гендиректоры урынбасары Алексей Храмов. – Һәм үзегез дә күрәсездер, барысы да иң заманча техника белән җиһазландырылган.

– Мондый машиналарда эшләве дә рәхәт, – ди тракторчылар, безгә үзләренең тимер атларының куәтен, көчен һәм матурлыгын күрсәтеп. – Элек исә ике сәгать эшлибез дә, ике көн төзәтә идек...

...Сулда да кыр, уңда да кыр, офыкка кадәр сузылган иксез-чиксез басу. Биредә Чүпрәле җирендә үстерелә торган бөтен нәрсәне дә күреп була: уҗымнар – 5550 гектар, сабан бодае – 2690 гектар, соя – 3953 гектар, рапс – 5567 гектар, бөртеккә дигән кукуруз – 2300 гектар, көнбагыш – 2900 гектар... Быел уңыш мул булачак. Хәер, уңдырышлы Чүпрәле төбәгендә бу һәрвакыт шулай.

«Солнечный круг» дип аталган продукция белән танышабыз. Булат Ибләмев җитәкчелегендә өлкәннәр үзләренә шундый кояшлы эш уйлап тапкан.

– Бездә бик көчле һәм профессиональ команда эшли, – дип таныштыра кыр хезмәтчәннәре белән Алексей Храмов. – Һәм барысы да иң заманча техника белән җиһазландырылган.

ҺӘРВАКЫТ БУЛСЫН КОЯШ!

Эссе кояш нурлары астында «Солнечный круг» дип аталган продукция белән танышабыз: таганнар, карусельләр, балалар өчен таулар, комлыклар... Булат Ибләмев җитәкчелегендә өлкәннәр үзләренә шундый кояшлы эш уйлап тапкан. Ульяновск өлкәсендә уйлап тапканнар, әмма әкренләп җитештерүне зурайтканнар да Иске Чүпрәлегә күченгәннәр.

– Чөнки биредә эшләр өчен шартлар яхшырак, район җитәкчелеге дә эшкуарларга карата зур кайгыртучанлык күрсәтә, – ди Булат.

Район җитәкчелегенең мондый эшчәнлеге мактауга лаек, чөнки конкрет территориядә инвестицион климатны яхшыртуның иң нәтиҗәле чарасы – яңа җитештерүләрне үстерү өчен мөмкин кадәр уңайлырак, кулайрак шартлар тудыру ул. «Солнечный круг» нәкъ менә шул рәвешле райондагы сәнәгать мәйданчыгы резидентына әйләнгән дә инде.

Хәзер исә әлеге җете төсләргә буялган, үзенчәлекле һәм, иң мөһиме, ышанычлы балалар һәм спорт комплекслары Чүпрәледәге, шулай ук күрше район-төбәкләрдәге күп ишегалларын, ял паркларын, балалар бакчаларын, мәктәпләрне, сәламәтләндерү лагерьларын бизәп тора.

Районның үзәк мәйданында исә оригиналь шахмат фигуралары, бизәкле эскәмияләр күзне сөендерә – һәм болар барысы да «Солнечный круг» компаниясендә ясалган.

Сулы экологик чиста буяулар, иң яхшы сыйфатлы ябыштырылган борыс, суга чыдам күп катлы фанера, тутыкмас корыч, арзан бәяләр, тиз арада ясап бирү һәм әзер продукциягә озак вакытлы гарантия... Өстәвенә, әлеге мәйданчыкта Чүпрәле тармак технологияләре техникумы студентлары практика уза. Аларны биредә эш нечкәлекләренә өйрәтәләр һәм үзләренә эшкә килүләрен көтеп калалар. Ихтыяҗ зур булган эретеп ябыштыручы һөнәрен сайлаган практикантларга исә хезмәт хакы да түләнә.

Бу бүлекне шушы кояшлы компаниягә исем биргән һәркемгә мәгълүм балалар җырыннан өзек белән тәмамлыйсы килә:

Тын кал, солдат,
Тыңла, солдат,-
Бар кеше курка шартлаудан.
Күккә карый
Меңләп күзләр
Һәм кабатлый иреннәр:
Һәрвакыт булсын кояш!
Һәрвакыт булсын һава!
Һәрвакыт булсын әни!
Һәрвакыт булыйм мин!

Иске Чүпрәледә бар нәрсә шундый җылы, нәкъ туган йорттагы кебек – оста куллы хатын-кызлар хәтта район картасын да чигеп куйган! Йә, тагын кайда күрер идегез әле шундый могҗизаны?!

– Хәерле юл! – дип сәламләде тантана хуҗаларын район башлыгы Марат Гафаров. – Белем алганнан соң кире үзебезгә кайтыгыз, без сезне көтәбез!

Чүпрәледәге вакыйгаларга бай көнебез район мәктәпләрен тәмамлаучыларның чыгарылыш кичәсе белән төгәлләнде. Зәвыклы күлмәк кигән сөйкемле кызлар да, тыйнак костюмлы җитди егетләр дә, яраткан укытучылардан аерылу сагышы да, җыр-биюләр, елмаюлар, теләкләр һәм, әлбәттә инде, бергәләп таңны каршылау да булды анда...

Түбән Чәке авылындагы «Туган як көне» төрле милләт кешеләрен берләштерде. Бәйрәмдә инде ярты гасыр буе бергә яшәгән, быел бергә яшәүләренең юбилей даталары булган, күп балалы гаилә парлары һәм туган авылын бернинди шәһәргә дә алыштырырга теләмәгән Данила Албутовның яшь гаиләсе дә хөрмәтләнде.

Чүпрәле техникумын тәмамлаучылар үзләренең уку йорты белән саубуллаша. Бүгеннән алар – төрле тармакларда көтеп алынган яшь белгечләр. Аларны «Исток»та да, «Солнечный круг»та да, «Чүпрәле Рассвет Агро» агрофирмасында да, «Дуван бакчаларында» да, Кече Чынлыда да кочак җәеп көтәләр...

«Акчарлак» балалар лагереннан киткәндә безне компот белән сыйладылар. Кипкән җимешләрдән кайнатылган компотның тәме нәкъ балачактагыча иде.

– Мондый компот бүтән беркайда да юк! – ди лагерь директоры Анатолий Мердюков.

– Без үзебез дә шулай дибез. Шуңа күрә кабат балачакка, Татарстанның иң уңдырышлы, иң кунакчыл һәм гаилә җанлы Чүпрәле районындагы лагерьга әйләнеп кайтырга телибез.

Чүпрәле районы буйлап аның башлыгы Марат Гафаров белән сәяхәт иткәндә, сокланып һәм хозурланып туя алмыйбыз. Кунакка килүчеләр күзенә чалынган иң беренче нәрсә – бу район бик матур, яшеллеккә күмелгән һәм җыйнак. Икенчедән, бик кунакчыл төбәк: кунакларны күптән күрешмәгән туганнарыдай каршы алалар. Өченчедән, моннан китәсе килми...

– Ә сез үзегез нәрсә әйтә аласыз районыгыз турында? – дип кызыксынабыз башлыктан. – Аның үзенчәлеге, уникальлеге нәрсәдә?

1. ДУС-ТАТУ

– Район тормышы – иң әүвәл биредә яшәүче халык ул, – дип җавап бирә безгә Марат Ринат улы. – Һичшиксез, аграр тармак көчле үсештә булган Чүпрәле районы барыннан да бигрәк үзенең хезмәт сөючән халкы, шулай ук күп милләтле мәдәни мирасы белән дан тота.

52 авылда татарлар, руслар, чувашлар бердәм, дус яши. Безнең көчебез менә шунда да!

Һәркем яраткан бәйрәмнәр – Сабан туе, Акатуй, «Троицкие напевы» фестивален, авыл көннәрен Чүпрәле халыклары дуслыгы символы дип санарга мөмкин. Алар безнең районда яшәүче барлык милләт халыкларын берләштерә, аларның бай мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән таныштыра, милләтара бәйләнешләрне ныгыта, янәшә тыныч яшәү кыйммәтләрен киләчәк буыннарга тапшыру, үзеңне бербөтен организмның кирәкле бер өлеше итеп тою мөмкинлеген бирә.

Бездә милли мәдәниятләр тарихын пропагандалаучы искиткеч фольклор коллективлары эшли: «Таң», «Умырзая», «Мишәрләр»,«Хельхем», «Сепрель», «Калинушка» – республика һәм төбәкара фольклор фестивальләренең күп тапкыр җиңүчеләре булган ансамбльләр.

Ана телләрен өйрәнүгә аеруча игътибар бирәбез. Безнең районда белем бирү процессы өч телдә алып барыла. Мәдәниятләр төрлелеген саклап укыйбыз һәм эшлибез – шулай яшәп ятабыз. Районыбызның гүзәллеге һәм кунакчыллыгы шушы татулыктан туа да инде.

2. ИДЕЯЛЕ

– Мондагы барлык эшкуар һәм фермерлар бертавыштан Чүпрәле районы хакимиятенең гаять зур ярдәмен тоеп эшләүләре хакында сөйли. Бирегә хәтта күрше шәһәрләрдән дә үз бизнеслары белән күченүчеләр бар икән. Нинди ярдәм ул һәм аны ничек бүләсез?

– Без яхшы идеясе һәм аны гамәлгә ашыру планы булган һәркемгә игътибар итәргә тырышабыз, барлык нечкәлекләренә кадәр тәфсилләп өйрәнәбез. Эшкуарлар шуны яхшы белә: әгәр ниндидер аңлашылмаучанлык яки кыенлык килеп чыкса, теләсә кайсы вакытта ярдәм сорый алалар.

Эшкуарларга федераль да, республика ярдәме дә, муниципаль ярдәм дә күрсәтелә. Бездә ул нигездә авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә тәгаенләнгән программалар буенча бирелә.

2023 елда 62 эшкуарга финанс ярдәме күрсәтелде. 105 эшкуар исә башка ярдәм чараларын сайлады. Әгәр безнең эшкуарларның 2024 елда республикадан һәм федераль финанс ярдәме алуга җәлеп ителү дәрәҗәсен карасак, бүген без рейтингта беренче урында торабыз.

Авыл хуҗалыгы кооперациясе системасын үстерүгә аеруча игътибар бирәбез.

РАЙОНДА 76 КРЕСТЬЯН-ФЕРМЕР ХУҖАЛЫГЫ (КФХ), 26 ГАИЛӘ ФЕРМАСЫ ҺӘМ 93 МИНИ-ФЕРМА ТЕРКӘЛГӘН. 2024 ЕЛДА ШӘХСИ ЯРДӘМЧЕ ХУҖАЛЫКЛАР ҺӘМ ФЕРМЕР ХУҖАЛЫГЫНА ЯРДӘМ ПРОГРАММАСЫ ТӨРЛЕ СУБСИДИЯЛӘР БИРҮНЕ КҮЗДӘ ТОТА. **«АГРОСТАПТАП» ҺӘМ «ГАИЛӘ ФЕРМАСЫ» ГРАНТЛАРЫ БУЕНЧА ҖИҢҮЧЕЛӘР САНЫ ЕЛДАН-ЕЛ АРТА БАРА.**

Ит эшкәртү буенча «Дуслык», сөт эшкәртү буенча «Исток», җиләк-җимеш үстерү һәм эшкәртү буенча «Дуван бакчалары» кооперативлары уңышлы эшли.

Бездә район үзәгендәге 19 гектар мәйданда урнашкан «Чүпрәле» сәнәгать паркы бар, анда резидентлар өчен салым түләүнең махсус шартлары һәм чыгымнарын компенсацияләү гамәлдә. Мәсәлән, җир салымы арзанрак һәм җир өчен аренда түләве алынмый, шулай ук резидентлар транспорт салымы һәм мөлкәт салымыннан да азат ителә. Өстәмә Build-to-suit эш форматы да бар – ягъни заказчы таләбе буенча биналар төзү, соңрак ул аренда өчен генә түли. Бүген сәнәгать паркында резидентлар балалар өчен уен мәйданчыклары, полимер эшләнмәләр, металл һәм тимер-бетон конструкцияләр, гранулалар, крахмал җитештерә, шулай ук икенчел чималны эшкәртү белән шөгыльләнә

БҮГЕН РАЙОНДАГЫ 414 КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШКУАРЛЫК СУБЪЕКТЫНДА 3176 КЕШЕ МӘШГУЛЬ. **БЕЗ ЭШКУАРЛАРЫБЫЗНЫҢ НЫГУЫНА ДА, ШУЛ УК ВАКЫТТА РАЙОНЫБЫЗНЫ ҮСТЕРҮЛӘРЕНӘ ДӘ БИК СӨЕНӘБЕЗ.**

3. ТӨЗЕК

– Хәзер Чүпрәле районында төзекләндерү буенча нинди федераль һәм республика программалары гамәлдә?

Без «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру», «Заманча мәктәп» федераль һәм республика проектларында, «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектында, «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасында катнашабыз.

Әлеге программалар районның төрле юнәлешләрдә үсүенә һәм төзекләнүенә булыша: фельдшер-акушерлык пунктлары, күпфатирлы йортлар төзелә, мәктәпләр, мәдәният йортлары һәм техникум ремонтлана, парклар булдырыла, территорияләр төзекләндерелә. Шул ук вакытта су ресурсларына да зур игътибар бирелә: халыкны эчәргә яраклы чиста су белән тәэмин итү максатында су юлларын көйләү чаралары үткәрелә, суүткәргечләр челтәрләре төзелә.

Бүген Яңа Чүпрәле һәм Үби авылларында парклар төзелә һәм тәртипкә китерелә, Яңа Ишле авылы мәдәният йорты бинасының фасады ремонтлана. Районның өч мәктәбендә ризык әзерләү блогына ремонт ясала. Проект гамәлдә булган 5 ел эчендә 13 парк һәм скверны, 11 функциональ зона һәм ризык әзерләү блогын төзекләндердек.

Мондый программалар халыкның тормышын яхшырту мөмкинлеген бирә, шул ук вакытта районыбызны тагын да уңайлырак һәм заманчарак итә. Боларның барысы өчен дә Рөстәм Нургали улы Миңнехановка һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә рәхмәт әйтәсе килә.

4. УҢАЙЛЫ

– Сез күптән түгел район мәктәпләрен һәм техникумны тәмамлаучыларны зур тормыш юлына озаттыгыз – шәһәрләргә, югары һәм махсус урта белем алырга. Әлеге яшьләр укуларын тәмамлагач кабат районга әйләнеп кайтсын өчен сезнеңчә нишләргә кирәк?

– Биредәге яшәү шартларын яхшыртырга тырышабыз – яшьләр гаилә корсын да биредә яшәп калсын иде. Махсус урта һәм югары белемле белгечләр өчен күбрәк эш урыннары булдырырга омтылабыз.

Уңайлы яшәү, эшләү, ял итү өчен бүген районда бөтен шартлар да бар.

РАЙОНДА 100 ДӘН АРТЫК СПОРТ КОРЫЛМАСЫ БАР, ШУЛ ИСӘПТӘН «ЧЕМПИОН» ФИЗКУЛЬТУРА-СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮ КОМПЛЕКСЫ, «АЛТЫН» УНИВЕРСАЛЬ СПОРТ ЗАЛЫ, «АКЧАРЛАК» ЯБЫК БАССЕЙНЫ ҺӘМ «АЛТЫН БАРС» БОЗ АРЕНАСЫНА ТЕЛӘГӘН ҺӘРКЕМ ЙӨРИ АЛА.

Чүпрәле районының матурлыгы паркларда йөргәннән соң бигрәк тә сокландыра. Бирегә күпләр эштән соң гаиләләре белән бергәләп ял итәргә килә. Уен мәйданчыкларында балалар рәхәтләнеп күңел ача.

Эшкә урнаштыруга килгәндә исә, мәсәлән, районның төп кадрлар әзерләүчесе – Чүпрәле тармак технологияләре техникумы студентлары инде укыган вакытта ук безнең оешмаларда эшләү һәм хезмәт хакы алу мөмкинлеген ия. Яшь белгечләр өчен нинди шартлар тудырылуын күргәч, алар киләчәктә үзләре дә кече ватаннарында яшәргә һәм эшләргә карар кыла.

Эшчәнлекнең төрле тармакларында вакансияләр бар, әмма авыл хуҗалыгы өстенлекле булып кала бирә: безгә агрономнар, зоотехниклар, ветеринария табиблары кирәк. Сүз уңаеннан, аларның эш хаклары да яхшы.

Безнең Иске Чүпрәле авылында «Созидание» яшүсмерләр клубы пәйда булды. Ул балалар һәм үсмерләрнең иҗади һәм социаль үсеше өчен кирәкле шартларны өстәмә белем бирү аша тәэмин итә, балаларның ялын оештыра. Клуб волонтерлары картларга, махсус хәрби операция зонасында булучыларга һәм аларның гаиләләренә булыша. Хәзер «Патриот» яшьләр үзәген капиталь ремонтлау бара – без аны Республика көнендә ачарга ниятлибез.

Билгеле инде, без яшьләрнең һөнәр алганнан соң үзебезгә кайтуын телибез. Кайберәүләр укырга кергәндә үк кире кайтуны планлаштыра – максатчан юллама алып китә. Хәзерге студентлар арасында бүген район оешмаларында практика үтүчеләр шактый, алар киләчәктә шунда кайтырга ниятли. Һәркем өчен мөмкинлекләр бар – яшьләрнең үзләренең теләге булу гына кирәк.

МОДУЛЬЛЕ ТЕХНОЛОГИЯ БУЕНЧА 5 ФАП ТӨЗЕЛГӘН, ИСКЕ ШӘЙМОРЗА УЧАСТОК ХАСТАХАНӘСЕНӘ КАПИТАЛЬ РЕМОНТ ЯСАЛГАН. 5 УНИВЕРСАЛЬ СПОРТ, 12 БАЛАЛАР УЕН ҺӘМ 1 СПОРТ МӘЙДАНЧЫКЛАРЫ ТӨЗЕЛГӘН ҺӘМ ФАЙДАЛАНУГА ТАПШЫРЫЛГАН. 3 ТОРАК ПУНКТТА КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТЛАРНЫҢ 4 ИШЕГАЛДЫ ТЕРРИТОРИЯСЕ ТӨЗЕКЛӘНДЕРЕЛГӘН.

5. ПЕРСПЕКТИВАЛЫ

– Районда бөтен нәрсә матур һәм төзек. Әллә болай түгелме? Нинди планнарыгыз бар?

– Биредә менә бу цитатаны китерү урынлы булыр: «Бер урында гына калу өчен, бик тиз йөгерергә кирәк, ә инде кая да булса барып җитәр өчен, кимендә ике тапкыр тизрәк йөгерү зарур». Без районыбызны һәрьяклап үстерергә тырышабыз. Әйе, төзекләндерү буенча нәтиҗәләр һичшиксез бар, әмма аны саклап калу һәм икеләтә арттыру өчен, бик күп нәрсә эшләргә кирәк әле.

СОҢГЫ БИШ ЕЛДА РЕСПУБЛИКА ҺӘМ ФЕДЕРАЛЬ ПРОГРАММАЛАР КЫСАЛАРЫНДА РАЙОНДА 9 МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ КАПИТАЛЬ РЕМОНТЛАНГАН, 2 КҮПФУНКЦИЯЛЕ ҮЗӘК ТӨЗЕЛГӘН ҺӘМ 5 АВЫЛ МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫНА КАПИТАЛЬ РЕМОНТ ЯСАЛГАН.

Ә 2024 елда республиканың «Татарстан Республикасы торак пунктларында халыкны су белән тәэмин итү» программасы буенча районда 4 торак пунктта 17 километрдан артыграк суүткәргеч челтәре салынды. Соңгы 5–6 елда районадагы 42 торак пункт су белән тәэмин ителде, бу исә 178 километрдан артыграк яңа суүткәргеч челтәре дигән сүз! Моның өчен республикабыз Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнехановка, шулай ук ТР Дәүләт Советы депутаты Ринат Рәүф улы Гайзатуллинга тагын бер кат рәхмәт әйтәсе килә.

5 елда 75,5 километр автомобиль юлының капиталь ремонтлануын да әйтеп үтәргә кирәк.

Мәдәният йортлары, мәктәпләр һәм балалар бакчаларында ремонт ясыйбыз: Алешкин-Саплык авылы мәдәният йортында, Иске Чүпрәледәге 1 нче «Кояшкай» балалар бакчасында, Зур Аксудагы «Тал» балалар бакчасында. Болар барысы да безнең үсеп килүче буынны кайгырту мәнфәгатьләреннән чыгып эшләнә. Чүпрәле тармак технологияләре техникумы бинасында да капиталь ремонт бара. Биредә яңа «Пилотсыз авиация системаларыннан файдалану» белгечлегенә укыту программасы кертеләчәк, аны тәмамлаучыларга «Пилотсыз очу аппаратлары операторы» квалификациясе биреләчәк. Хәзерге шартларда бу бик актуаль.

Тагын әле Иске Ишле авылында фельдшер-акушерлык пункты, Үби, Иске Шәйморза һәм Коршанга-Шигали авылларында суүткәргечләр челтәре төзелә. Иске Дуван авылында Кече Чынлы елгасында су юлын көйләү чаралары да үткәрәбез.

Алда планнар һәм проектлар бик күп әле, шул исәптән туристлык маршрутларын үстерү буенча да, чөнки без табигый ресурсларга да бик бай, урнашкан урыныбыз да бик гүзәл, кешеләребез дә бик кунакчыл.

Чүпрәле районы

ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ

Ләкин җырдагыча, кайтыр юллар алга дәшә. Шөкер, М-12 ардырмый торган шәп юл булды. Аның җитешсезлекләре турында кайткач сөйләшербез...

ЮЛЛАР, ЮЛЛАР, АЛГА ТАБА ДӘШӘ...

Өч шәһәр, борынгы храмнар, тарихи һәйкәлләр, музейлар, балык тоту, җиләк басулары, авыл матурлыклары... Ике көнлек сәяхәт, ә тәэсирләр – бер елга җитәрлек. «Татарстан» М-12 юлында, вакытны кыскартып, ераклыкны якынайтып, чын туристлык хабына әверелерлек хәлдә булуына инанды. Автобан буенда Казаннан Мәскәүгә кадәр бик күп урыннар бар, анда һичшиксез барырга кирәк.

Әмма «Татарстан» тагын бер нәрсәгә дә инанды: М-12 бүгенге халәтендә автомобиль туризмы өчен идеаль вариант түгел. Эш хәтта ял итү зоналарының, ягулык салу станцияләренең һәм кунакханәләрнең бөтенләй булмавында гына да түгел – болар барысы да әкренләп төзелә. Навигациянең камил булмавы теләсә кайсы шәһәр үзәгеннән түләүле автобанга керү юлын катлаулы бурычка әйләндерә.

Урамнарда, борылышларда, хәтта торак пунктлардан чыгу юлларында күрсәткечләрнең булмавына гаҗәпләнеп, без аның сәбәбен аңларга тырыштык. Күрәсең, трасса өчен җаваплы «Автодор» анда барлык билгеләр, торак пунктлар, елгалар, юнәлешләр һ. б. күрсәтелгән язуларны урнаштыруга бик җаваплы караган. Әмма М-12 юлыннан читтәрәк булган өчен ул җавап бирми, монысын башкалар эшләргә тиеш.

«Башкалар» үз эшләрен эшлиләр: урамнарда бушлай магистральләргә кадәр генә барып җитәргә ярдәм итә торган күрсәткечләр куелган. Монда үз мантыйгы бар кебек: коммерция белән шөгыльләнүчеләр өчен нигә тырышырга, ди, бу эшкә үзләре акча кертсен... Тик ничек кенә булмасын, нәтиҗәдә барыбыз да оттырабыз: машина йөртүче – кирәкле керү юлын эзләп вакытын әрәм итә, магистраль хуҗалары – адашып йөрергә теләмичә түләүсез юлдан китүче потенциаль клиентларны һәм, димәк, акчаны югалта...

Интернет чорында юл күрсәткечләре кирәкме икән соң? Ләкин бүген барлык навигаторлар, интернет-ярдәмчеләр А пунктыннан Б пунктына кадәр маршрутны М-12 буенча күрсәтмиләр – күбрәк бушлай вариант тәкъдим итәләр. Төрле сәбәпләр аркасында, навигатор эшләмәгән вакытлар да еш була...

М-12 трассасы буенча куелган юл күрсәткечләрнең аз булуы да туризм файдасына эшләми. Әйтик, Сергачка борылганда, Пушкин «Евгений Онегин»ны язган Болдиноның да ерак түгеллеген аңлаткан күрсәткеч булса, без анда керми китәр идекмени? Ә болай – үз машинасында юлга чыккан турист белми үтеп китә.

Аңлыйбыз, тизйөрешле трассада күп мәгълүмат урнаштырып булмый – бу куркыныч та. Әмма М-12 юлындагы шул ук күпфункцияле зоналарны үзенчәлекле туристлык инфоүзәкләре итәргә нәрсә комачаулый? Якындагы истәлекле урыннар һәм аларга кадәр күпме барасы – әлеге мәгълүмат язылган карта-юл күрсәткече ясар өчен миллионнар кирәкми. Әгәр шундый карта Олы Кайбыч янындагы ял зонасында пәйда булса, Подберезье авылындагы тегермән һәм халык көнкүреше музеена килүчеләр саны, мөгаен, бермә-бер артыр иде. Ә инде М-12 гә бәйләнешле мондый юл күрсәткечләре интернетта да пәйда булсамы...

Автотуризм үсешенә аяк чала торган тагын бер нәрсәне атыйк. Бу М-12 трассасыннан чыгу урыннарының бик аз булуы, шуның аркасында якында урнашкан истәлекле урыннарга кадәр юл еш кына дистәләрчә, хәтта йөзләрчә километрга озыная, мондый сәяхәтләрне мәгънәсез итә.

Шушы ук проблеманы, сүз уңаеннан, берничә ай элек РФ Президенты да билгеләп үтте. Май күрсәтмәләрендә ул Хөкүмәткә, «аерым алганда, «Нева» М-11 һәм «Көнчыгыш» М-12 автомобиль юллары уза торган районнарда автомобиль туризмын үстерү буенча чаралар планын («юл картасын») эшләү һәм раслау бурычын куйды, әлеге юллардан чыгу урыннарын оештыруга һәм мондый туризм өчен кирәкле ярдәмче автомобиль юлларын үстерүгә, туристларны җәлеп итәрлек урыннарны, тыюлыклы табигать территорияләрен дә кертеп, туристлар һәм җәяүлеләр маршрутларын оештыруга, шулай ук туристларны урнаштыру урыннарын өстенлекле үстерүгә аерым игътибар бирде». Автотуризмны үстерү буенча «юл картасы» төзү өчен җавап бирүчеләрнең барысына да «Татарстан»ның тәкъдимнәре артык булмас дип уйлыйбыз. Алар исәпкә алынырмы, әгәр шулай икән, тиздән ничек булыр? Президент күрсәтмәсе буенча беренче хисап – инде декабрьдә.

М-12 буенча сәяхәт иттек: Татьяна Вафина, Әскәр Сабиров, Евгения Чеснокова, Александр Ефремов, Виктория Зубова, Александр Гайнетдинов.

АНА ТЕЛЕННӘН ИМТИХАН: БАТЫРЛЫКМЫ?

Руфия Фазылова

Август башы. Югары уку йортлары беренче дулкын белән кергән абитуриентлар исемлеген элде. Димәк, яшьләребезне алда күңелле дә, җаваплы да студент тормышы көтә. Ә БДИга әзерләнгән чаклары куркыныч бер төш кебек кенә артта калды.

Сөенеч (бер карасаң, бу бит табигый хәл булырга тиеш), татар теленнән дә бердәм дәүләт имтиханын сайлаучылар бар. Андыйлар быел 7 укучы иде. Мөслим, Түбән Кама, Казан шәһәренең Идел буе, Совет һәм Авиатөзелеш районнары мәктәпләрендә белем алучы җиде кыз ана телләрен шулай ярата булып чыкты. Менә шул кызларның берсен – татар теленнән БДИны 100 баллга тапшырган Камилә Гыйләҗиеваны редакциябезгә чакырдык.

ЯХШЫ ҮРНӘК!

– Мондый зур игътибар булыр дип көтмәгән идем!

Камиләнең беренче сүзе шул булды. Чынлап та, быел ана теленнән имтихан тапшырган укучылар күз өстендәге каш кебек булды. Узган ел да җиде укучы татар теленнән БДИ тапшырган, тик алар турында белми дә калдык. Ә быел бу укучылар ТР Мәгариф һәм фән министрлыгына чакырылып бүләкләнде. Алар белән ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыкларның туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре буенча комиссия рәисе Марат Әхмәтов, ТР мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов очрашты. Җитәкчеләр кызларга уңышлар теләде, ихлас рәхмәт сүзләрен җиткерде.

Бер карасаң, бу балаларга шундый зур игътибар күрсәтү гаҗәп тә – ана теленнән имтихан тапшыру Айга менү түгел бит. Ләкин, икенче яктан, милли үзаңлы балалар елдан-ел кими. Әлеге вазгыятьтә бу җиде кыз, батырлык эшләмәсә дә, бик матур үрнәк күрсәтте. Һәм шуны аңлаган җитәкчеләргә рәхмәт, башка татар балалары өчен дә бер стимул булып торсын. «Минем ике укучым алдагы елларда татар теленнән БДИ язды, әмма мондый игътибар булмады», – диде Казан мәктәпләренең берсендә эшләүче бер мөгаллимә. Димәк, әле бу укытучылар өчен дә яхшы үрнәк.

Имтихан тапшырган җиде кыз арасыннан түбән балл алучы юк. Әйткәнемчә, Камилә Гыйләҗиева иң югары нәтиҗәгә ирешкән. Казан шәһәре Идел буе районының 127 нче урта гомуми белем бирү мәктәбен алтын медальгә тәмамлаган ул. Барлык фәннәрне дә рус телендә укыган. Унынчы, унберенчедә татар теле бер сәгать, әдәбият та бер сәгать кергән. Аңа карамастан, татарчасы камил, сөйләменә ник бер рус сүзе кыстырсын!

– Хәзер күп балалар ярым-йорты сөйләшә, Камилә. Хәтта авылларда да шулай. Ә син ничек болай ана телен камил беләсең? – дим.

Фотолар: К. Гыйләҗиеваның шәхси архивыннан, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтыннан

– Кечкенәдән өйрәнелгән. Мин хәтта сыйныфташлар белән дә гел татарча сөйләшәм. Дөресрәге, алар үзләре миңа гел татарча эндәшә.

– Ә соң сыйныфта барлык балалар да татарча беләме?

– Гади сүзләрне генә беләләр инде. Тәнәфестә килеп, теге сүзнең татарчасы ничек дип сорыйлар. Мин алар өчен русча-татарча сүзлек кебек. (Көлә.)

«ҮЗЕ ШУНДЫЙ БАЛА...»

Бу урында шуны әйтим: Камиләнең әнисе татар теле укытучысы. Балык Бистәсе районының Биектау авылында яшәүче дәү әнисе дә татар теле укытучысы. Күрәсең, бу гаиләдә ана теленә мәхәббәт күкрәк сөте белән керә.

Камилә редакциябезгә әнисе Альбина ханым белән килде.

– Камиләнең ана телен шулай яратуында сезнең өлеш зурдыр, – дибез.

– Бардыр инде. Әмма ул үзе шундый татар җанлы бала. Безнең белән рус телендә сөйләшкәнен һич хәтерләмим.

– Камиләне татар теленнән БДИга сез әзерләгәнсез икән?

– Әйе, дип әйтергә мөмкин. Камилә тугызынчыны тәмамлагач та, татар теленнән имтихан бирде. Шулай булгач, аның базасы яхшы иде. Күбрәк үзлегеннән өйрәнде дисәм

дә була. Камиләне кечкенәдән гел авылга алып кайттык. Әнием татар теле укытучысы булгач, әдәби әсәрләр, әкиятләр укый иде. Кызыбыз кечкенәдән шигырь конкурсларында катнашты, җиңүләр яулады. Үсә төшкәч, татар теленнән олимпиадаларда катнашты, җиңүче дә булды.

Хәзер яшьләр китап укымый, дибез. Камилә моның киресен раслый – өйләрендә тулы бер китапханә икән. «Китап кибетеннән беркайчан буш кул белән чыкмыйбыз», – диде татар теленнән БДИны 100 баллга тапшырган кыз. Рус, татар әдәбияты, чит ил язучылары иҗатына, бигрәк тә төрек теленә мөкиббән икән.

– Төрек телен мәктәптә өйрәндеңме? – дим Камиләгә.

– Юк, үзлегемнән өйрәндем. Төрекчә кинолар карыйм, китаплар укыйм. Тагын әле инглиз телен дә өйрәнәм.

– Яраткан китапларың нинди?

– Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» һәм Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәрләре. Аларны инде әллә ничә кат укыдым. Спектакльләрен дә карадым. Әдәбият белән бергә, театрны да яратам. Камал театрында карамаган спектакльләрем бер-ике генә.

Инде хәзер төп сорау: ана телен ихлас яраткан, яхшы белгән кыз укырга кая кергән соң? Әлбәттә, гуманитар юнәлешне сайлаган – КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар филологиясе һәм журналистикасы бүлегендә укыячак. Камиләнең яхшы тәрҗемәче буласы килә. Татар теле, рус теле белән бергә, университетта төрек телен дә өйрәнәчәк.

– Кулга диплом алгач, Төркиягә барып, андагы уку йортында белем алуымны дәвам итәсем килә, – диде сәләтле кыз. – Төрек теле татарчага якын, һәм бу юнәлештә ихтыяҗ да зур. Мәктәпне тәмамлагач та, Төркиягә барырга мөмкин иде, аның өчен әчке имтиханнарны тапшырырга кирәк. Тик башта белем дәрәҗәмне тагын да үстерергә, аз булса да тәҗрибә тупларга кирәк дигән нәтиҗәгә килдем.

...Ике бала әнисе буларак фикерем катгый: татар теле мәктәптә укытылырга тиеш. Атнага бер сәгать «исәнмесез», «сау булыгыз» сүзләренең тәрҗемәсен өйрәнеп кенә ерак китеп булмый. Әйе, Камилә Гыйләҗиева кебек рус классында укып та ана телен камил белеп була. Без моңа инандык. Ләкин бу кагыйдәдән искәрмә. Әлеге очракта мине иң сокландырганы шул: туган телендә сөйләшү, татарча уйлау Камилә өчен гадәти хәл. Аның милли үзаңы хәтта гаҗәпләндерде дә. Күпләр татар теле нәрсә өчен кирәк дигәндә, Камилә телебезнең перспективасын аңлый һәм шул юнәлештә үсәргә тели.

ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДА ТАТАР ТЕЛЕННӘН БДИ ТАПШЫРУЧЫ УКУЧЫЛАР САНЫ

2008 елда – **385**
2011 елда – **40**
әдәбияттан – **5**
2016 елда – **67**
2017 елда – **74**
2018 елда – **18**
2019 елда – **15**
2020 елда – **9**
(2021 елда, пандемия сәбәпле, имтихан булмады)
2022 елда – **1**
2023 елда – **7**
2024 елда – **7**

«ТУГАН ТЕЛЕБЕЗ АТЛАНЫП ЙӨРИ ТОРГАН ВЕЛОСИПЕД ТҮГЕЛ!»

Марат Әхмәтов, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыкларның туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре буенча комиссия рәисе, – татар теленнән БДИ тапшырган укучылар белән очрашуда:

– Сез туган телегезгә мөнәсәбәтегез белән бик матур үрнәк күрсәттегез. Республикабызның киләчәк язмышы өчен, милли мохитебез өчен бик кирәкле адым ясадыгыз. Ни кызганыч, туган телебезгә төрле караштагы кешеләр бар. «Нәрсәгә кирәк ул миңа?» – дип, аны тормыш ихтыяҗы белән генә бәйләүчеләр дә бар. Туган телебез атланып йөри торган велосипед түгел. Шул ук вакытта сезнең кебек җаны-тәне белән телебезгә бирелгән милләтпәрвәр кешеләр дә бар. Сезнең кебек кешеләр белән телебезне саклау юнәлешендә эшләргә тырышабыз.

Укытучыларга рәхмәт. Телебезнең дәрәҗәсе югары булу-булмавына карамастан, күңелләрен төшермичә, балалар белән матур итеп эшләүләрен дәвам итәләр. Укучыларыбызга, әти-әниләрегезгә рәхмәт. Әгәр дә гаиләдә телгә мөнәсәбәт җылы булмаса, аны ярату булмаса, укытучыларның тырышлыгы белән генә мондый нәтиҗәләргә ирешә дә алмас идегез.

Сезнең үрнәк безгә бик кадерле. Сезнең кебекләрне күбрәк күрәсе килә. Укучыларның, укытучыларның тырышлыгын дөресрәк, лаеклырак бәяләү турында сөйләшербез. 9 нчы сыйныфта татар теленнән имтихан сайлаган укучыларның барысы да 11 нче сыйныфта татар телен сайламастыр, әмма телебезнең сакланышы – балаларда.

7 укучының 5 се шәһәр мәктәбеннән – шул күренешкә сөендем әле. Укучы кызларыбызның киләчәк язмышына без дә игътибарлырак булырбыз. Үтенеч-гозерләрегез булса, ишекләребез ачык. Мөмкин булганча, ярдәм күрсәтергә тырышырбыз.

«БАЛАЛАРНЫҢ 63 ПРОЦЕНТЫ ТАТАР ТЕЛЕН САЙЛАГАН»

Илсур Һадиуллин, Татарстанның мәгариф һәм фән министры:

– Мәктәпләрдә туган тел әти-әниләр сайлавы буенча укытыла. Республикабызда балаларның 63 проценты татар телен сайлаган. Бу – безне сөендерә торган, алга таба өмет бирә торган күрсәткеч. Без аны тагын да үстерергә һәм киметмәскә тиеш. Бу – укытучылар, мәгариф идарәсендә эшләүчеләр, мәктәп директорлары һәм әти-әниләрнең күмәк эше. Туган телдән имтихан тапшыручылар – безнең өчен игътибар үзәгендәге мәсьәлә. Алга таба туган телебез үссен, саклансын, милләтебезнең киләчәге якты һәм ышанычлы булсын өчен, туган тел – татар теленнән имтиханны сайлап алучылар тагын да күбрәк булырга тиеш.

КЕМ КАЯ УКЫРГА КЕРГӘН

– **Гарипова Диләрә**, Әтнә районы; Казан дәүләт мәдәният институты, хореография юнәлеше

– **Минһаҗева Камилә**, Мөслим районы; КФУ, филология һәм журналистика юнәлеше

– **Инсапова Регина**, Казан; В. Г. Тимирясов исем. Казан инновация университеты, психология-педагогика юнәлеше

– **Гыйләҗева Камилә**, Казан; КФУ, филология һәм журналистика юнәлеше

– **Куренщикова Элина**, Казан; КФУ, татар һәм инглиз телләре укытучысы

– **Хәйруллина Карин**а, Казан; Казан дәүләт аграр университеты, икътисад юнәлеше

– **Сәгыйтова Сәмирә**, Түбән Кама; КФУ, программист

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Дөнья гизәр өчен **нәрсә** кирәк

Гүзәл ханымнар иртән **кемгә** коймак пешерә

Әгерҗедә якты киләчәкне **ничек** төзиләр

Иж-Бубый мәдрәсәсендә **кемнәр** укыган

Ни өчен 95 яшьлек әби печән чабарга ярата

СӘЯХӘТНЕ ТУГАН ҖИРДӘН БАШЛАУ ЯХШЫ

Руфия Фазылова

Атаклы француз язучысы Анатоль Франс: «Сәяхәтләр барысына караганда да күбрәккә өйрәтә. Кайвакыт чит җирләрдә уздырган бер көн өйдә яшәгән ун елга тиң», – дип язган. Редакциябезнең бүгенге кунагы да нәкъ менә шул фәлсәфә белән яши. Дөньяның утыз өч илендә булган Рәис Мәрдән улы Миңнуллинга декабрьдә 70 яшь тула. Һаман да елына ким дигәндә ике тапкыр сәяхәт итә. Ул булмаган илләр картада шактый әле. Максаты – әнә шул җирләрне барып күрү.

Рәис әфәнде, сәяхәтче булудан бигрәк, гомерен авыл хуҗалыгына багышлаган кеше дә. Бүгенге әңгәмәбез кызыклы гына түгел, фәлсәфи дә, белемне арттырырга да ярдәм итә.

«ҖИРНЕ ИЗВЕСТЬ БЕЛӘН ТУЕНДЫРУ МӨҺИМ»

– Рәис абый, белгечлегегез буенча сез инженер – геолог-геофизик. Һәм ТРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре дә әле. Шуның өчен дә әңгәмәбезне җир, туфрак турында сөйләшүдән башласак иде. Бүген Җир-анабыз нык таушалган, туфрак ярлыланган, шуңа күрә дә ашламасыз бернәрсә үсми, диләр. Бу дөресме?

Фотолар Рәис Миңнуллинның шәхси архивыннан

– Тагын әле икенче югары белемем буенча авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты да. Дөрес. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын саклау турында 101 нче Федераль закон бар. Анда җир турында барысы да язылган: күпме һәм кайчан ашлама кертергә, уңдырышлылыкны ничек арттырырга һ.б.

Татарстандагы авыл хуҗалыгы җирләренең 40 проценттан артыгы әче туфраклы. Органик ашламалар һәм известьтән башка бездә югары уңышка өметләнеп булмый. Әче туфрак нәрсә соң ул? Димәк, анда файдалы бактерияләр үлгән. Хәзер бит авыл хуҗалыгы тармагы көчле, югары уңыш алу өчен җирнең бөтен мөмкинлеген кулланалар. Ә бу туфракны эштән чыгара.

Гади итеп аңлатам: кеше организмында өч килограмм чамасы файдалы бактерия бар. Антибиотик эчсәк, ул бактерияләр үлә, һәм ашаган ризыгыбыз эшкәртелми башлый. Җир белән дә шул хәл. Белмичә күп итеп ашлама кертсәк, файдалы бактерияләр үлә. Шуның өчен дә җирне иң беренче известьләргә кирәк. Известь – табигый кальций һәм магний ул. Җиргә водород утыра, кальций аны юк итә. Нәтиҗәдә, җир уянып китә һәм эшли башлый.

Бүген Татарстанда утыздан артык известь карьеры бар. Ягъни җирдән таш алалар һәм шуны ваклап кырларга сибәләр. Гомерем буе диярлек шушы юнәлештә эшлим, шуның өчен әлеге теманы бик яхшы өйрәндем. Җирне известь белән туендыру бик мөһим. Әнә, Белоруссиядә бу мәсьәләгә бик зур игътибар бирәләр. Шуның өчен дә аларда уңыш яхшы.

Закон нигезендә туфрак биш елга бер тапкыр тикшерелергә тиеш: күпме фосфор, калий, магний, азот җитми. Һәм шуның нәтиҗәсендә картограмма ясала.

– Бөтен бәрәңге бакчасына да известь кертергә кирәкме?

– Башта туфракны тикшертергә кирәк. Кеше организмына да белер-белмәс витаминнар кулланырга киңәш ителми. Монда да шул хәл.

– Әче туфраклы районнарны әйтә аласызмы?

– Алар шактый. Мисал өчен, Аксубай районында – 59 процент, Актанышта – 69 процент, Әлки районында – 57 процент, Алабуга районында 66 процент җир әче туфраклы. Бу белгечләр тикшергән бөтен мәйдан буенча дигән сүз. Алда әйткәнемчә, Татарстан буенча бу сан 40 проценттан артыкны тәшкил итә.

«ҖИР ШАРЫНДА ГЛОБАЛЬ ҖЫЛЫНУ БАРА»

– Татарстан климат шартлары тотрыксыз булган зонага карый. Вакыт-вакыт көчле давыллар, бураннар булып ала. Ләкин Россиянең көнчыгышында урнашкан Камчатка ярымутравы белән чагыштырганда без җәннәттә яшибез. Анда җир тетрәүләр

Африка. Занзибар утравында 150 яшьтән зуррак ташбака белән.

Эльбрус тавына күтәрелер алдыннан. Дуслар янәшәсендә.

Вьетнам. Хон Лао утравында филдә йөргәннән соң.



Кения. Җирле кабилә башлыклары белән истәлеккә фото.

гадәти хәл бит. Татарстанда да җир тетрәүләр булырга мөмкинме?

– Камчаткадагы кебек җир тетрәүләр була алмый. Әйе, Җир шарында глобаль җылыну бара, моннан берничек тә кача алмыйбыз.

Татарстан Рус платформасының көнчыгышында урнашкан. Хәтерләсәгез, Кама Аланында атом электр станциясе төзелешен туктаттылар, чөнки ул геологик яктан куркыныч: җирнең ярылу, убылу куркынычы бар.

Татарстан территориясе берничә геологик платформадан тора. Алар селкенсә, үзгәрсә, әлбәттә, бездә дә ниндидер үзгәрешләр булырга мөмкин. Ләкин ул барыбер көчле җир тетрәүләргә китермәячәк. Җир шары ул – тере организм. Без сезнең белән менә монда сөйләшеп утырганда да, Җир шары үз күчәре тирәсендә сәгатенә 1666 км тизлек белән әйләнә. Шуның өчен аның үзгәрүе табигый хәл.

– Рәис абый, инде сезнең өчен бик якын тема – сәяхәтләр турында да сөйләшәсе килә. Сездән, мөгаен, кайларда булдыгыз дип түгел, кайларда булмадыгыз дип сорарга кирәктер?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Синең күпме белүең түгел, ә күпме йөрүең мөһим», – дигән. Бөтен дөньяны гизү мөмкин түгелдер. Утыз өч илдә булдым, Россияне исә аркылыга-буйга гиздем. Кеше сәяхәт итүне иң беренче туган җиреннән башларга тиеш дип саныйм.

Миңа кечкенәдән сәяхәт итү бәхете насыйп булды: мәктәпне тәмамлаганчы Татарстанның биш районында яшәп чыктым. (Әти җитәкче урыннарда эшләде.) Сарман районында туганмын, аннан Тукай районына күченгәнбез. Шуннан соң Тау ягына киткәнбез: Кама Тамагы, Тәтеш һәм Апас районнары. Хәтерлим, алты яшемдә Кама Тамагында Идел буенда уйный идек. Аннан Лобач тауларына менәбез... Менә шул вакытта ук Татарстанның нинди зур, матур булуын аңладым. Башка төбәкләрне, башка илләрне дә күрәсе килү теләге нәк шул чакта ук бөреләнде.

Апас урта мәктәбен тәмамлагач, КДУның геология факультетына укырга кердем. Анда инде чын мәгънәсендә сәяхәтләр өчен юл ачылды. Эш шунда ки, университетта яхшы укыган студентларны дүрт айга практикага СССРның төрле төбәкләренә җибәрәләр иде. Ә начаррак укыганнар Татарстанда гына кала. Әнә шулай итеп биш ел студент булу дәверендә Камчаткадан Кырымга кадәр, Ямал, Урал, Себер, Казахстан, Үзбәкстан, Белоруссия – барысын да йөреп чыктым. Элек бит чит илләргә чыгу юк иде. Чикләр ачылгач, ягъни 1990 нчы еллардан соң гына дөнья буенча сәяхәт итә башладым.

«ИСӘН КАЛУЫБЫЗГА ҮЗЕБЕЗ ДӘ ГАҖӘПЛӘНДЕК»

– Иң истә калган сәяхәтегез? Куркыныч янаган очраклар булдымы?

– Булды, әлбәттә. Иң истә калган сәяхәт дип, Гвинея утравына (Папуа-Индонезия) баруымны әйтә аламдыр. Гадәттә, без сәяхәткә өчәү йөрибез – табиб дустым Айрат Хәкимов, геолог дустым Рөстәм Гәрәев белән. Бер айга якын йөргән чаклар да була.

Иң истә калган сәяхәтне иң озыны дип тә әйтә алам. Бервакыт без башта Кытайга киттек. Аннан, Филиппиндагы шарлавыклар, вулканнарны карагач, Австралиягә очтык. Шуннан Индонезия архипелагы составына керә торган Яңа Гвинеягә барырга ниятләдек. Андагы кебек су асты дөньясы беркайда да юк. Ләкин Индонезия архипелагына болай гына эләгеп булмый, виза ясатырга кирәк. Аның өчен сине кемдер ул илгә чакырырга тиеш. Танышлар аша Индонезиянең мулласын таптык, ул безне каршы алды.

– Нәрсә карыйсыгыз килә? – дип сорады.

– Катер белән ачык океанга чыгасы килә. Су астындагы мәрҗәннәрне күрәсе килә, – дидек.

Кыскасы, безне төнлә Тын океанга алып чыгып киттеләр. Һәм сигез баллы шундый көчле шторм башланды, сөйләп аңлатып булмый. Катерны очырта гына. Безгә паспортларны полиэтилен белән билгә бәйләп куярга куштылар. Иң аянычлысы, алай-болай булса, безне эзләмәячәкләр дә, чөнки Индонезиягә рәсми рәвештә килмәдек. Кичке унбердә башланган давыл иртәнге дүрттә генә тынды. Исән калуыбызга үзебез дә гаҗәпләндек.

4000 метрдан парашютта сикерү вакытында.

– Һәм тиз генә яңадан утрауга кайту ягын карадыгызмы?

– Юк шул. Безнең папуаслар белән очрашасы килде. Тамак ялгап алгач, пляжга киттек. Карасак, папуаслар учак ягып казан аскан, нидер пешерә. Болар безне уратып алды, сәер итеп карыйлар. Дөресен әйтәм, куркып калдык. Ул да түгел, дустыбыз Айрат намаз укый башлады. Баксаң, папуаслар да мөселман диненда икән, безне менә шул коткарды. Шуннан безнең белән кочаклаштылар, әле сыйладылар да. Ярканат тотып, шуңардан аш пешереп ашаттылар.

Тын океанга чыгуыбызның тагын бер максаты су астын күрү иде. Маскалар киеп, океан төбенә төшеп киттек. Мәрҗәннәрнең матурлыгы... Чын могҗиза инде. Карасак, океан төбендә нәрсәдер йөзә. Видеога төшерергә дип артыннан киттек. Баксаң, бу келәмсыман, яки мыеклы акула икән. Моңа кадәр бер дә күргәнем юк иде, чынлап та келәмгә охшаган, киң. Янына барып ук видеога төшердек. Безне катер белән утрауга алып килгән егетләргә ул видеоны күрсәткән идек: «Сезне бит ул акула тешләргә, пешерергә мөмкин иде. Башка янына якын бармагыз», – диделәр. Яңа Гвинея утравыннан менә шулай бик күп тәэсирләр алып кайттык.

«ҺӘР СӘЯХӘТКӘ НЫКЛАП ӘЗЕРЛӘНӘМ»

– Рәис абый, сезне тыңлыйм да, гаҗәпләнеп утырам: гомерегезне куркыныч астына куюлар күп булган икән. Бу сезгә нигә кирәк?

– Берәү, судан куркып, мич башында ятып та, сулы ләгәнгә егылып төшеп үлгән. Шулай ук Казан урамында да машина бәреп китәргә мөмкин. Аллаһка тапшырган, начарлык турында уйламаска, позитив булырга кирәк. Мондый сәяхәтләрдән алган тәэсирләр бик озакка җитә, яңа көч бирә.

– Ә тагын кайларга барырга ниятлисез? Сәяхәт алдыннан маршрутны билгелисезме?

– Аллаһ Тәгаләне көлдерәсең килсә, планнарыңны сөйлә, диләр. Мин дә кая, кайчан сәяхәткә җыенуым турында берәүгә дә сөйләмим. Кайткач кына сөйлим. Һәр сәяхәткә ныклап әзерләнәм, күп укыйм. Маршрутны, планны төзим. Әзерлексез беркайчан чыгып китмим.

«ҺӘР СӘФӘРЕМ ТУРЫНДА ТӘФСИЛЛӘП ЯЗАМ»

– Тагын бер мавыгуыгыз турында сөйләшәсе килә: журналистика. Бу юнәлешкә ничек кереп киттегез?

– Мәктәптә укыганда ук «Йолдыз» Апас район газетасына яздым. Сигезенче сыйныфта укыганда, укытучыбыз безне төрле җирләргә сәяхәтләргә алып чыга иде. Беренче язмаларым шулар турында булды. Университетка укырга кергәч, студентларның «Ленинец» газетасына яза башладым.

Тора-бара шуңа гадәтләндем: һәр сәяхәтем турында тәфсилләп язам. Беренчедән, алай истә кала, икенчедән, тарихка керә. Сәяхәттән кайтып язма әзер булгач кына тынычланам. Аннан соң аларны газета-журналларда бастырам. Республиканың берничә басмасы белән элемтәдә торам.

– Рәис абый, сез бит сәяхәтләр турында гына язмыйсыз, ә еш кына экология, башка проблемаларны да күтәрәсез. Газета-журналларда чыккан язмалардан соң проблема хәл ителәме?

– Бөтенесе булмаса да, хәл ителә. Мин ул проблемаларга кат-кат кайтам.

«КЕШЕ ДӨНЬЯГА ҮЗЕ БУЛДЫРЫР ӨЧЕН ТУА»

– Лаеклы ялда булсагыз да, эшләп йөрисез. Үз яшегезне һич биреп булмый. Яшь булып калуның сере нәрсәдә?

– Беренчедән, җәяү йөрим. Көн саен ун мең адым атлыйм. Эшкә җәяү киләм. Икенчедән, тормышны яратып яшим, үзеңнең теләк-максатларыңны икенче планга куймау да сине яшәртә дип уйлыйм. Ул яктан мин бәхетле: нык гаиләм, тугры дусларым бар.

Кечкенәдән эти белән әни безне эшкә өйрәтеп үстерде. Кеше бу дөньяга үзе табар, үзе булдырыр өчен килә. Без шул фәлсәфә белән үстек. Һәм үз балаларыма да бу кыйммәтләрне сеңдерергә тырыштым. Җәмәгатем белән өч бала: ике ул, бер кыз үстердек. Югары белем алып, тормышта үз урыннарын таптылар. Дүрт оныгыбыз бар. Алар да еш сәяхәт итә, чөнки кечкенәдән шуңа өйрәнеп үстеләр.

– Рәис абый, тормыштагы иң зур хыялыгыз, максатыгыз нинди?

– Әле барасы килгән җирләрем бик күп, әнә шуларны күрергә исәнлек, мөмкинлек булсын, дип телим. «Россиянең җиде могҗизасы» буйлап йөреп чыктым. Искиткеч тәэсирләр алдым. Бөтен кешегә дә киңәш итәм.

ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегендә 1199 объект исәпләнә. Бу исемлектә Россия Федерациясенең дә 31 объекты бар. Шулай булгач, барыр җирләрнең исемлеге озын, географиясе киң әле!

Фото: Инесса Герасимова, Алеся Салахова. РЕКЛАМА

РАДЖАНА СОЛТАНОВАНЫҢ ТӘРҖЕМӘЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Эшмәкәр ханым Раджана Солтанова ни өчен ясалма интеллектның беркайчан да кешене алыштыра алмаячагы, ни өчен бернинди таҗлар да чын королеваларны «әни» вазыйфаларыннан азат итмәве турында сөйли.

ОТЛИЧНИК КЫЗЛАР НӘРСӘ САТА?

– Мин эшмәкәрлек белән 2004 елда, Казан дәүләт университетының икътисад факультетында дүртенче курста укыган чакта шөгыльләнә башладым. Гап-гади гаиләдә туып үстем. Язмышыма шулай язылгандыр, миңа үземне генә түгел, әнием, сеңелләремне кайгыртырга, иртә акча эшләргә туры килде. Минем кебек отличница өчен үзем белгән юнәлештә эшкә керешү – үз белемнәремне сата башлау гаять табигый иде. Курс һәм диплом эшләре яза башладым. Бу вакытта текстлар тәрҗемә итеп бирүне сораучылар да табылды, нәкъ менә шундый мөрәҗәгатьләр миңа 2009 елда «Мир Переводов» агентлыгын ачуга этәргеч бирде.

БИЗНЕСНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ НӘРСӘДӘ

Мин балачактан амбицияле, тәвәккәл идем, лидер булырга омтылдым. Мин һәрвакыт ниндидер максатлар куеп, кыю рәвештә шуларны тормышка ашырырга омтыла идем. «Мир Переводов» – нульдән башлаган хезмәтем. Уңышның сере – үз-үзеңә чын күңелдән ышануда, эшкә җаваплы карауда. Шул чагында барысы да килеп чыгачак! Бу юл җиңел булмастыр, әмма үз эшеңне чын күңелдән ярату, үсешкә омтылу барлык авырлыкларны җиңәргә булыша. Дисциплина, җаваплылык, партнерларга, заказчыларга һәм хезмәткәрләргә кешелекле мөнәсәбәт мөһим. Мин мотивацияне, мәнфәгатьләрне һәм ихтыяҗларны аңлау өчен, үземне алар урынына куеп карарга тырышам. Бу исә компаниягә win-win* стратегиясе, ягъни ике якка да отышлы юл белән яшәргә һәм идарә итәргә мөмкинлек бирә. Бизнесның киләчәге әнә шунда икәнлегенә ышанам.

КӨНДӘШЛЕК ТҮГЕЛ, Ә ҮСЕШ ТУРЫНДА ГЫНА

Бүген Татарстанда лаеклы компанияләр күп, һәркемнең үз урыны бар. Мин беркем белән дә көндәшлек итәргә теләмим, ә бары тик үсәргә һәм заман белән бергә атларга телим. Һәркем үз мөмкинлекләре һәм потенциалына карап эшли.

Җитәкченең шәхси сыйфатлары да зур әһәмияткә ия. Без яхшы белгечләрне, үз эшенең чын осталарын еш очратабыз, әмма эшмәкәр булу өчен бу гына җитми. Монда табигый сәләт, сизгерлек һәм барыннан да бигрәк тәвәккәллек кирәк. Миңа күренекле психотерапевт Алексей Ситниковның: «Лидерлык – 50% генетика һәм 50% тормыш тәҗрибәсе ул», – дигән сүзләре ошый. Минем тормышымда барысы да нәкъ шулай килеп чыкты да: эти үлгәннән соң, язмыш гаилә терәгенә әйләнергә мәҗбүр итте, ә яңа нәрсә булдыру, берләштерү һәм идарә итү омтылышы миндә балачактан ук бар иде.

ТӘРҖЕМӘ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Гомумән алганда, мин биш тел беләм. Туган телләрем икәү: рус һәм азәрбайҗан телләрен камил беләм. Төрек теле – бик яхшы сөйләшер-

* Вин-вин.

НАЦИОНАЛЬНЫЙ СЕРТИФИКАТ

ПРЕДПРИЯТИЕ ГОДА 2023

Общество с ограниченной ответственностью

«АГЕНТСТВО «МИР ПЕРЕВОДОВ»

За весомый вклад в развитие экономики страны, добросовестную уплату налогов и безупречную деловую репутацию, что позволило предприятию занять лидирующие позиции в отраслевом рейтинге на основании отчетности Федеральной статистической службы России

ОКВЭД 74.3 «Деятельность по письменному и устному переводу»

Standard Chartered Rating
Доктор Клаус Таллер

«Лига лучших»
Пекарева П.А.

International Rating Association
Зарий Фиайн

Москва, 2024

ОБЩЕРОССИЙСКАЯ ОБЩЕСТВЕННАЯ ОРГАНИЗАЦИЯ
«СОЮЗ ПЕРЕВОДЧИКОВ РОССИИ» (СПР)»
Union of translators of Russia (UTR)
Член Международной федерации переводчиков
(Fédération Internationale des Traducteurs – FIT)

СВИДЕТЕЛЬСТВО

Общество с ограниченной ответственностью
АГЕНТСТВО «МИР ПЕРЕВОДОВ»
(г. Казань)

является партнерской организацией (ассоциированным членом) Общероссийской общественной организации «Союз переводчиков России» (СПР)
и

в соответствии с Уставом СПР имеет право указывать в своей официальной и деловой документации, а также в своих изданиях статус ассоциированного члена СПР.

Президент СПР /О.Ю. Иванова/

СПР- № 117 Дата вступления 27.03.2024 г.

лек дәрәҗәдә, инглиз теле – көнкүреш һәм туристлык дәрәҗәсендә. Татарча барысын да аңлыйм һәм бераз сөйләшә алам, чөнки ул төрки телләргә керә һәм туган телемә охшаган.

Компанияне ачкан вакытта мин, белгечләр эзләп, төрле игъланнар карадым, төрле ысулларны кулландым, хәтта телеканалда «йөгерек юл»лар да әйләндердем. Эш барышында тәрҗемәчеләр үзләре дә безне табып, хезмәтләрен тәкъдим итә башлады. Хезмәттәшлек итү теләге белән мөрәҗәгатьләр көн саен диярлек килә, резюмены тикшереп, тест тәрҗемәсе ясатып караганнан соң, бергә эшли башлыйбыз. Телләр күп, тәрҗемәчеләрнең күбесе – штаттан тыш хезмәткәрләр. Ә ихтыяҗ зур булган телләрдән тәрҗемәчеләр компаниядә даими нигездә эшли. Оешманың 15 еллык эш дәверендә без төрле характердагы текст һәм документларны тәрҗемә иткән телләр арасында 49 пар санадык. Минем тарихта без документны тәрҗемә итә алмаган бер очрак булды. Анда Малайзиядә бирелгән белешмәнең тәрҗемәсе кирәк иде, без аны кабул итә алмадык, чөнки нотариуста үз имзасы белән тәрҗемәне раслый алырлык белгечебез юк иде.

Әмма нигездә заказчылар тәрҗемә ителергә тиешле документларның стандарт пакеты белән мөрәҗәгать итә.

Гомумән, бик борынгы тарихи архив документларын тәрҗемә итү – катлаулы фәнни һәм филологик мәсьәлә. Миңа калса, мондый документлар белән махсус учреждениеләр генә шөгыльләнә ала, мәсәлән, Фәннәр академиясе яисә китап нәшрияты. 2019 елда агентлыгыма гарәп хәрефләре белән язылган иске татар телендәге туу турында таныклыкны тәрҗемә итүне сорап килделәр. Ни кызганыч, ул вакытта моны эшләп булмады. Әмма быел без Россия тәрҗемәчеләр берлегенең ассоциацияләнгән әгъзасы булдык һәм хәзер тәрҗемә белән бәйле теләсә нинди мәсьәләләрне хәл итә алабыз.

Тәрҗемәләр барлыкка килгән заманнан ук ул кеше эшчәнлегенең иң катлаулы төрләреннән санала. Лингвистлар еш кына бер телдән икенче телгә тәрҗемә турында сөйләсә дә, чынлыкта эш моның белән генә чикләнми. Чөнки тәрҗемәдә төрле чорлар да, төрле мәдәниятләр, гореф-гадәтләр дә очраша, берләшә.

КЕШЕМЕ, ЯСАЛМА ИНТЕЛЛЕКТМЫ?

Бүген ясалма интеллект популярлык казана. Тиздән аның теге яки бу профессиядә кешене алыштыра алачагы турында бәхәсләр куера. Тик, миңа калса, машина тәрҗемәсе беркайчан да кеше эшләгәнне алмаштырмаячак, чөнки ул контекстны, грамматиканы, диалектларның үзенчәлекләрен тулы күләмдә исәпкә алмый. Өстәвенә, базада нинидер сүз булмаса, программа аны тәрҗемә итмәячәк. Катлаулы техник текстлар, аерым бер өлкәгә генә караган язмалар, медицина документлары һәм дәүләт әһәмиятендәге документлар турында әйтәсе дә юк.

Шуңа күрә хәзерге көндә интернет-тәрҗемә безнең өчен көндәш түгел.

ҮЗ-ҮЗЕҢ БЕЛӘН ТАНЫШУ

Тормышта берни дә очраклы түгел дип уйлыйм. Халык күзенә күренү турындагы фикерләр шактый күптән барлыкка килде. Һәм тормыш миңа шундый мөмкинлек бирде.

Барысы да «Мисс һәм Миссис Бизнес Татарстан 2024» конкурсының төбәк этабыннан башланды. Аның искиткеч финал тамашасы 2024 елның 27 апрелендә узды. Ай дәвамында 30 эшмәкәр ханым җитди әзерлек узып, үзләренең һәм талантларының бөтенләй яңа якларын ачты. Һәркайсыбызның үз-үзең белән танышу нинди мөмкинлекләр ачуына һәм үз сәләтләренә гаҗәпләнгәнлегенә ышанам.

Перфекционист буларак, мин конкурста катнашуга аеруча җентекләп әзерләндем. Аның һәр этабын мин тормышым этаплары белән чагыштырып карадым һәм үз-үземә: «Мин нинди кадерле нәрсәләремне аудитория белән белән уртаклаша алам?» – дигән сорау бирдем. Жюри минем катлаулы тормыш бәяныма ваемсыз калмады. Бәйгенең «Grand prix business Tatarstan 2024»* дип исемләнгән төп титулын алгач, мин юлымны дәвам итәргә һәм яраткан республикамны федераль дәрәҗәдә – «Мисс һәм Миссис Бизнес Россия 2024» конкурсында тәкъдим итәргә булдым.

Дөресен генә әйткәндә, Казанда да, Санкт-Петербургта да конкурста катнашучыларның югары дәрәҗәсенә шаккаттым: масштаблы проектлар дисеңме, миллионлаган сумлык товар әйләнеше, базарда иң көчле позицияләр дисеңме! Һәм болар барысы да күз алдына да китереп булмаслык харизма, намуслылык һәм затлылык белән бергә! Бу үземне мөмкин кадәр ачып күрсәтүгә генә түгел, ә алардан өйрәнеп, кызларның тәҗрибәсен сеңдерүгә дә бер этәргеч булды. Шуңа күрә, титуллар алганнан соң да, әлеге уңышлы һәм матур хатын-кызлар даирәсендә үземне алар белән бер югарылыкта хис итәм!

КОРОЛЕВАДАН КОЙМАК

Конкурста катнашу карарын шактый авырлык белән генә кабул иттем. Бу үземне күрсәтергә вакыт җитте дигәнне белдерә иде, ә мин бу тойгыдан стресс һәм уңайсызлык кичердем. Ләкин үз хис-кичерешләремне гаилә белән уртак-

* «Гран-при делового Татарстана 2024».

лашкач, алар тарафыннан шундый ярдәм тойдым ки, һич шикләнер урын калмады.

Конкурста катнашуның төп мотиваторлары кызларым – Афина һәм Малейка булды. Миңа хатын-кызның яхшы хуҗабикә, әни һәм хатын гына түгел, ә уңышлы бизнес-леди, чын королева да була алуын күрсәтеп бирү мөһим иде. Бәйге үренә бару юлында кызларым илһам чыганагы һәм канат куючыларым булды. Мин аларга, ихлас күңелдән, җаның-тәнең тырышып, үз хыялларыңа таба барганда, һәрнәрсәне чынга ашырырга мөмкин икәнлегенә чын үрнәк күрсәтергә теләдем.

Алар икесе дә минем өчен бик борчылдылар, тик шул ук вакытта һәрвакыт ярдәм иттеләр, син безнең өчен болай да королева, дип тордылар. Һәм беренче таҗлар да минем «әни» вазыйфаларымны гамәлдән чыгармый – титулың бармы-юкмы, барыбер иртән коймак пешерергә туры килә.

ГАИЛӘ БӘХЕТЕ СЕРЕ

Бизнес һәм гаиләне уңышлы һәм артык стресс кичермичә генә бергә алып барыр өчен, хатын-кыз иң элек үзе өчен шуны аңларга тиеш: тегендә дә, монда да тулы функциональны саклап калу мөмкин түгел! Шуңа күрә, бик тиз булмаса да, мин шәхси тормышта да, компания эшчәнлегендә дә мәҗбүри катнашуымны таләп итмәгән вазыйфа-бурычларның бер өлешен бүлешү кирәклеге фикеренә килдем. Мәсәлән, кызларымның эмоциональ тормышына якынрак һәм сыйфатлырак катнашу мөмкинлеге булсын өчен, мин ярдәмчемә үтүкләү һәм җыештыру, репетиторга – балалар белән дәрес хәзерләү эшләрен тапшырам. Әмма ризык әзерләү һәм, мәсәлән, көндәлек гардероб сайлау кебек вазыйфаларны үзем башкарам, чөнки бу гамәлләр аша гаиләмә үз мәхәббәтемне белдерү, аны шул рәвешле кайгырту ошый.

Минем гаилә бәхете сере гаиләнең һәр әгъзасына җитәрлек шәхси пространство бирүдән гыйбарәт. Бу безгә көндәлек ыгы-зыгыда җитешмәгән тынычлыкны табарга мөмкинлек бирә, үзеңә багышланган вакыт, тормыш тәҗрибәм күрсәткәнчә, үзара гармонияле, ихтирамлы мөнәсәбәтләр урнашуга булыша.

Әгерҗе районы

Фото: Айдар Мешерепов, Александр Ефремов, Әскәр Сабиров, agryz.tatarstan.ru. Иллюстрация: Оксана Кузнецова

ӘГЕРҖЕ РАЙОНЫ. АЛГА, ЯКТЫ КИЛӘЧӘККӘ!

Акбүз атка атланган принц турындагы әкияткә хәзер ышанучылар сирәк. Янәсе, кайда алар, принцлар, акбүз атлар?.. Юкка ышанмыйлар югыйсә! Без менә уйламаганда гына аларның пәйда булган урыннарын таптык. Әгерҗе районының гербында ул акбүз атка атланган чын принц.

Гербның тасвирламасыннан түбәндәгеләрне белеп алабыз: «...Татар милли киемендәге җайдак бу җирлеккә нигез салучы кеше турындагы легенданы гәүдәләндерә. Җайдакның алга төбәгән кулы Әгерҗе районы халкының якты киләчәккә омтылуын, ә калкан өстендәге сигез почмаклы йолдыз районда яшәүче барлык халыкның уртак максатка ирешү өчен берләшкән көчен символлаштыра».

Без бик урынлы килеп кергәнбез алайса. Мондый районда безне якты киләчәккә алып барырлык күркәм эшләр күтеп торачагына ышанабыз.

ҖИЛӘКЛЕ БАСУЛАР

Кечкенә генә Касай авылын үтеп биш минут баруга, фермер Әминә Әхмәдиеваның «көньяк» плантацияләренә тап булабыз. Юк, болар шәфталу яки авокадо да, рапс белән карабодай да түгел. Республикадагы иң салкын һәм дымлы дип саналучы районда Әминә апа сәнәгать күләмендә җиләк үстерә. Офыкларга тоташучы плантацияләр – аның җиләк басулары.

– Кайнатма ясарга җитәме?

– Бераз күбрәк, – дип елмая ул. – Ике гектардан быел өч тонна җиләк җыйдым. Августта икенче уңышы өлгерә, тагын шуның кадәр булыр дип уйлыйм.

Әминә апаның җиләкләре баллы, хуш исле, аларны сатуда кыенлык юк: интернет булыша. Күбесенчә товар «экспортка» – Ижауга, Сарапулга китә. Җиләккә дип Чаллы шәһәреннән дә киләләр. Бәяләр базардагыча, күпләп алучылар килограммын 400 сумнан ала.

Шушы килосына 400 сумны эшләр өчен күпме хезмәт кирәген сезгә теләсә кайсы һәвәскәр бакчачы аңлатып бирә алачак. Үзеңнең ике-өч сутый җиреңдә яхшы уңыш алу да һәркемнең кулыннан килмәслек ба-

1

– Ике гектардан быел өч тонна җиләк җыйдым. Августта икенче уңышы өлгерә, тагын шуның кадәр булыр дип уйлыйм, – ди Әминә Әхмәдиева, елмаеп.

тырлыкка тиң. Әминә апа исә ике гектарлы җиләк басуын берүзе эшкәртә.

– Берүзем үк түгел инде, – дип, тыйнак кына ачыклык кертә ул, – сезон вакытында ярдәмчеләр алырга туры килә, дүрт-биш кеше чакырам. Бергә эшлибез, бергә уңышны җыябыз. Иң мөһиме: һава торышы сюрпризларны күп әзерләмәсен.

Әминә апага бизнесын башлап җибәргәндә һава торышы белән җитди алышка чыгарга туры килә. 2018 елда беренче сигез сутый җиргә җиләк утыртып, 400 килограмм уңыш җыеп ала. Аннары җиләкне өстен каплап үстерергә карар кыла һәм мәйданны арттыра. Шәһәрдән булышырга кайткан уллары белән тамчылы сугаруны көйлиләр, теплицалар төзиләр. Ләкин нәтиҗәдә алар көчле җилләргә каршы тора алмый... Бер елдан яңа сынау: кышын җиләк үсентеләре салкыннарга чыдамый, өши...

Хаталана-хаталана өйрәнәләр. Бүген Әминә апа җиләкне ничек эшкәртәсен, салкыннарда өшемәсен өчен өстен ничек каплыйсын белә, ашлау, үстерү серләренә төшенгән, перспективалы сортларны профессиональ агрономнардан ким аермый. Узган ел үзләре өчен рекордлы уңыш – алты тонна җиләк җыйганнар. Ә җитди бизнес булдырырга эш башлаучы фермерларга бирелә торган грантлар булышты дип саный ул – аларны ике тапкыр откан, өч миллион сум акча алган.

Әйе, дөрес. Ләкин бу чандыр гәүдәле энергияле ханымның гаҗәеп эшсөярлегә дә ул грантлардан кимрәк булышмагандыр. Ял, бәйрәм, буш вакытны белми ул. Гектарлаган җиләктән тыш, хуҗалыкта тагын өч сыер һәм терлек азыгы культуралары чәчелгән иген кыры булганда нинди буш вакыт ди ул?

Әхмәдиева крестьян-фермерлык хуҗалыгы – Әгерҗе районындагы 50 крестьян-фермерлык хуҗалыгының берсе генә. Крестьян-фермерлык хуҗалыгы һәм хосусый предприятиеләр районның чәчүлек җирләренең 40 процентын эшкәртә. Узган ел районадагы барлык терлекчелек һәм игенчелек продукциясенең якынча өчтән берен алар җитештергән.

Ә иң зур авыл хуҗалыгы оешмасы булып бирердә «Нәүрүз» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тора. Әгерҗе районындагы терлекчелек продукциясенең 70 процентын әлеге предприятие җитештерә.

ПЕРСПЕКТИВАДА – МЕГАФЕРМА

Проблемалармы? Алар районда теләсә кайсы авылдагы кебек үк. Яшьләр елдан-ел күбрәк шәһәрне сайлый. Туган якның табигате никадәр генә матур булмасын (Әгерҗе ул – Кама да, Иж да, урманнар да. Монда урманнар республикабызның башка районнарындагылардан күбрәк), бер таңнан икенче таңга кадәр эшләү, үз фермерлык хуҗалыгында эшләсәң дә, бөтен кешене дә кызыктырмый шул.

Ләкин, бөтен җирдә дә шулай инде дип, кул кушырып утыру әгерҗеләр эше түгел. Авылның киләчәге бар, ди алар, ә терлекчелектәге һәм игенчелектәге бүгенге нәтиҗәләр – киләчәктә сан буенча да, сыйфат буенча да үсеш өчен таяну ноктасы гына. Һәм бу сүзләрен эшләре белән ныгытып та куялар.

Җиләк плантацияләреннән соң безгә кеше буе булып үскән кукуруз басуларын күрсәтәләр. Тик торганнан гына бу басуны күрсәтмәде алар. Уңыш яхшы булырга охшаган, ләкин бу очракта анысы иң мөһиме түгел. Кукурузны Удмуртиядән килгән инвестор чәчкән. Әгерҗе туфрагына җиң сызганып эшләргә дип һәм озакка килгән ул. Кукуруз кыры белән янәшә истәлек ташы. Аны төзеләчәк агроферма урынына июнь аенда салганнар. Бу агрофермааны инвестор – «СобинАгро-Әгерҗе» ҖЧҖ инде киләсе елга ук ачарга ниятли.

– Берьюлы унсигез мең баш мөгезле эре терлек асрау мөмкинлеге булган, алты мең савым сыерына исәп тоткан мегаферма булачак, – дип рухланып сөйли Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Илгиз Салихов. – Автоматлаштырылган эшләр, компьютерлар, һәркайсында берьюлы җитмеш ике сыерны савып була торган ике савым каруселе... – заманча югары җитештерү комплексы.

Инвестор әлеге проектка чама белән дүрт миллиард ярым сум акча кертергә исәпли. Бик зур акчалар, ләкин әгерҗеләр комплексның булачак хуҗалары барысын да яхшылап уйлагандыр дип саный. Киләчәктә сатып алу хокукы белән арендага алынган бу җирләр эшкәртү өчен менә дигән, җитештергәнне сату базары – 50–100 километр ераклыкта... Кыскасы, бу – барысы да отышта калырдай очрак. Районда сөт җитештерү күләме бермә-бер артачак, ә заманча югары технологияле предприятиедә 100 эш урыны – яшьләрне җәлеп итү мөмкинлеге. Комплексны тулаем 2027 елда төзеп бетерергә ниятлиләр.

РЕКЛАМА

2

– Бередә алты мең баш савым сыерына исәп тотылган мегаферма булачак, – дип рухланып сөйли Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Илгиз Салихов.

3

Җиләк плантацияләреннән соң безгә кеше буе булып үскән кукуруз басуларын күрсәтәләр. Монда да уңыш яхшы булырга охшаган.

4

Төзеләчәк агроферма урынына июнь аенда истәлек ташы салганнар. Бу агроферманы инвестор – «СобинАгро-Әгерҗе» ҖЧҖ инде киләсе елга ук ачарга ниятли.

5

Мәктәп каршына укучылар һәм укытучылар үзләре утырткан бакча – авыл ландшафт дизайнының чып-чын үрнәге. Бакчаның үз исеме дә бар – кайчандыр аңа нигез салган биология укытучысы Мөнирә Закирова хөрмәтенә «Мөнирә бакчасы» дип атала.



МӘКТӘП – ҮСЕШ НОКТАСЫ

Кеше эш белән генә яшәми. Төзеләчәк мегафермага якын гына урнашкан Кадыбаш авылына баргач, киләчәген авыл хуҗалыгы белән бәйләргә теләүчеләр кайда ял итәргә дип борчылмас дигән фикергә килдек. Капиталь төзекләндерүдән соң бүген-иртәгә ачылырга торган мәдәният йорты безне хәйран калдырды. Сәхнә, тамаша залы, грим бүлмәләре, спорт залы – барысы да башкаладагыча уңайлы, заманча, бар да зәвыклы.

– Заманча типлаштырылган клублар, әлбәттә, уңайлы да, җыйнак та, ләкин безнеке совет чорында төзелгән. Зур, купшы, түшәмнәре дә бик биек. Шуңа да капиталь реконструкция ясарга дип уйладык, – дип сөйли Кадыбаш авыл җирлеге башлыгы Хәлил Закиров. – Нәтиҗәдә чып-чын патша сарае килеп чыкты. Карагыз, мондый тамаша залы бөтен шәһәрдә дә юк әле. Мәдәният йортыбыз ачылгач, безгә театрлар, артистлар да ешрак киләчәк. Район күләмендәге концертлар, форумнар – монда барысын да уздырып булачак. Кемгә нинди түгәрәк, нинди секция кирәк... Болар барысы да бер кадыбашлар өчен генә түгел – якындагы авыллар өчен дә.

Кадыбаш районндагы иң зур авыл түгел. Бүген анда яшәүчеләр саны 400 кешедән кимрәк, ә район үзәгенә кадәр 50 километрдан артык. Ләкин аның киләчәге юк дип әйтергә тел әйләнми. Мәдәният йорты, яңа ФАП, кибет, яхшы юллар – рәхәт яшәр өчен кирәк булганның барысы да бар. Мәктәп? Күптән түгел генә үзенең 125 еллыгын билгеләп үткән Кадыбаш урта мәктәбе – авылның бизәге, терәге һәм киләчәге.

Бизәге, чөнки мәктәп каршына укучылар һәм укытучылар үзләре утырткан бакча – авыл ландшафт дизайнының чып-чын үрнәге. Әллә ничә төрдәге дистәләгән, йөзләгән чәчәк – төрле еллардагы чыгарылыш сыйныф укучыларының бүләге – биредә шундый традиция. Сүз уңаеннан, бакчаның үз исеме дә бар – кайчандыр аңа нигез салган биология укытучысы Мөнирә Закирова хөрмәтенә «Мөнирә бакчасы» дип атала.

Мәктәп булганда авыл яши, диләр. Кадыбаш мәктәбе чынлап та авылның терәге. Әйе, бүген анда бары 35 кенә укучы укый (тагын алты бала авыл балалар бакчасына йөри). Ләкин менә инде 30 елга якын Фәния Рәшитова җитәкләгән педагоглар коллективы шундый: бер генә әти-әнинең дә башына үз баласын көчлерәк һәм уңайлырак мәктәпкә күчерергә кирәк дигән уй килми. Беренчедән, көчлерәк мәктәпне таба алулары шикле – укучыларның физика, химия, математикадан узган олимпиадаларында җиңүләре, БДИ алган тотрыклы югары баллар кебек үк, күпне сөйли. Бу гына да түгел, монда «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында табигый-фәнни һәм технология

6

Күптән түгел генә үзенең 125 еллыгын билгеләп үткән Кадыбаш урта мәктәбе – авылның бизәге, терәге һәм киләчәге.

7

– Мәдәният йорты чып-чын патша сараедай килеп чыкты. Мондый тамаша залы һәр шәһәрдә дә юк әле, – дип сөйли Хәлил Закиров.

8

– Чын күңелдән янып йөрүчеләр тотына икән, бөтенләй булмастай тоелган хыяллар да чынга ашуын тормыш үзе раслый, – ди Әгерҗе районы башлыгы Ленар Нургаянов.

9

Яңа ФАП.

юнәлешендәге «Үсеш ноктасы» белем бирү үзәге ачыла. Табигый-фәнни һәм технология юнәлешендә өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру, заманча лаборатория һәм робот техникасы җиһазларын кулланып, тәҗрибәләр һәм экспериментлар ясар өчен яңа мөмкинлекләр барлыкка килә. Шулай булгач, безнең киләчәк – ул да биредә, Кадыбаш урта мәктәбендә.

Авыл мәктәбе һәм югары технологияле киләчәк, әллә кайдагы авыл һәм грандиоз планнар. Болар никадәр реаль? Чын күңелдән янып йөрүчеләр тотына икән, бөтенләй булмастай тоелган хыяллар да чынга ашуын тормыш үзе раслый. Моның шулай икәнлегенә инанасыгыз киләме? Алайса, сезгә Иж-Бубыйда булырга кирәк.

ИЖ-БУБЫЙ: ҮТКӘННӘН КИЛӘЧӘККӘ

Челтәр кәрнизле бай агач йорт. Монда кайчандыр беренче гильдия сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Әхмәтҗанов яшәгән. Сугышларны һәм революцияләрне исән кичә алмаган бу йортны элеккеге сызымнар һәм фотографияләргә нигезләнеп торгызганнар. Торгызырга тиеш булганнар: Мөхәммәтҗан ачкан мәдрәсәне аны балалары Гобәйдулла, Габдулла һәм Мөхлисә бөтен төрки-мөселман дөньясына билгеле алдынгы мәгариф үзәгенә әйләндерә.

Ул монда, Иж-Бубыйда, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында заманы өчен революцион саналган җәдиди укыту алымнары кертелә, дөньяви фәннәр укытыла. Шәкертләр мәдрәсәдә тригонометрия, геометрия, рус, француз, гарәп телләрен өйрәнә. Россиядә хатын-кызлар өчен беренче мөселман училищесы биредә барлыкка килә. Анда күренекле Мөхлисә Бубый укыта – соңрак ул мөселман дөньясында беренче һәм бердәнбер хатын-кыз казый булачак.

XX гасыр башында белем алыр өчен дип, Иж-Бубыйга Россия империясенең бөтен шәһәрләреннән киләләр: Мәскәүдән һәм Санкт-Петербургтан, Казаннан һәм Бохарадан, Сәмәрканд белән Ташкенттан... Зур шәһәргә түгел, хәтта иң якындагы Сарапулга кадәр дә илле чакрым булган бер авылга киләләр!

Иж-Бубый авылы тарихы музее директоры Раиф Гәрәев кунакларга Мөхәммәтҗан

Әхмәтҗанов һәм аның балаларының фидакарьлеге турында сөйләгәндә, аларның мәдрәсәдән белемле, дөньяви тормышта уңышка ирешә алырдай кешеләр чыксын өчен, барысын да эшләүләренә дә тукталмый калмый. Кызыклы бер документ күрсәтә: ир-егетләр мәдрәсәсе өчен 1909 ел белән тамгаланган атналык уку сәгатьләре. Аннан күренгәнчә, рус теленә атнага 12 сәгать бирелгән – бу татар һәм гарәп телләренең икесенә бергә бүленгәннән бер сәгатькә артык. Менә шундый факт.

– Әле тагын сәүдәгәрләр ерактагы авылларга күп кенә технологик яңарышларны да алып килгән, – дип сөйли экскурсовод. – XX гасыр башында аларның өйләрендә су торбалары һәм хәтта... чыбыксыз телефон да булган. Бу хакта «игелек теләүче» берәүнең өяз хакимиятенә язган һәм бүгенгәчә сакланган дәгъвасы сөйли. Авылда ике су тегермәне эшләгән, кымыз белән дәвалый торган ике шифаханә, уникe лавка һәм ике кирпеч заводы булган. Һәр кирпечкә җитештерүченең үз кeләймәсе сугылган...

Бәлки, Иж-Бубыйда күп кенә борынгы мирасның (ә алар монда башка авыллар белән чагыштырганда һичшиксез күбрәк) безнең көннәргәчә сакланып калуына кирпеч заводлары да сәбәпчедер. Иж-Бубыйны ачык һавадагы музей – туристлар Мәккәсе итү идеясе дә барлыкка килгән. Зур матур стенд рәвешендә ясалган грандиоз планны бүген сәүдәгәр йорты стеналарында күрергә мөмкин.

Тормышка ашмастай хыял дип уйлыйсызмы? Әгерҗеләргә үҗәтлек белән тырышлыкны башкалардан алып торасы юк. Фидакарьләр юкка чыкмаган әле монда.

10

Челтәр кәрнизле бай агач йорт. Монда кайчандыр беренче гильдия сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Әхмәтҗанов яшәгән.

11

Ир-егетләр мәдрәсәсе өчен 1909 ел белән тамгаланган атналык уку сәгатьләре.

12

Сәүдәгәр кибете.



Недельная сетка часов для мужского медресе, 1909 г.[1]

Названия предметов	1	2	3	4	5	6	7	8	всего
Татар. яз.и л-ра	2	2	2	2	2	2	3	2	17
Араб. яз.и л-ра	4	4	4	3	2	3	2	2	24
История ислама	2	2	2	2					8
Вс. ист. и филос.					2	2	2	2	8
Арифметика	3	4	2	1					10
Алгебра					2	2			4
Геометрия					1	2	2		5
Астрономия								1	1
Толков. Корана							2	2	4
Хадис						2	2	4	
Осн. шариата						2	1	1	4
Естеств. история						1	1	1	3
Природоведение							2	2	4
География	2	2	2	1	1	2	1		11
Химия						2	2	4	
Тригонометрия							1	1	2
Гигиена								1	1
Этика					1	1	1	3	
Экономика							1	1	2
Рисование	1	1	1	1	1	1			6
Каллиграфия	1	1	1					1	4
Логика						1	1	1	3
Правила наслед.								1	1
Мусульм. право	1	1	2	1	1	3	2	2	13
Богосл. и ритор.			1	1	1	2	1		6
Физика	2	1	1						4
Французский яз.						1	1	1	3
Педаг. и метод.							1	1	2
Русский язык	12	12	12	18	18				72
Чтение Корана	2	2	2	2	1	2	2	2	15
Всего часов	32	32	32	32	32	28	30	30	248

Ул монда, Иж-Бубыйда, XIX гасыр ахыры–XX гасыр башында заманы өчен революцион саналган җәдиди укыту алымнары кертелә, дөньяви фәннәр укытыла. Шәкертләр мәдрәсәдә тригонометрия, геометрия, рус, француз, гарәп телләрен өйрәнә.

ИРТӘГӘГӘ ИЛТҮЧЕ ТИМЕР ЮЛ

Әгерҗе авыллары буйлап йөргәннән соң, без, ниһаять, район үзәгенә килеп җитәбез. Шәһәр статусын Әгерҗе 1938 елда ала. Моңа, әлбәттә, тимер юл салу да үзенең саллы өлешен кертә.

Тимер юл белән турыдан-туры бәйле булган шәһәр тарихын безгә локомотив депосының административ бинасында урнашкан музейда сөйлиләр.

– 1914 елда Казанбург тимер юлы дип йөртелгән тармакны төзү эшләре башлана, – ди элек Горький тимер юлының Ижау бүлеге җитәкчесе, ә хәзер Әгерҗе районы Иҗтимагый советы рәисе Александр Лапшин. – Юл Казан белән Екатеринбургны тоташтырырга тиеш була... 1915 елда Әгерҗе аша беренче поездлар уза.

Музейда сезгә бер кызыклы факт турында сөйләделәр: юл төзү эшләре белән композитор Чайковскийга күп еллар буена ярдәм күрсәтеп яшәгән хәйрияче Надежда фон Меккның улы Николай Карлович фон Мекк идарә итә.

Тимер юл төене зур тизлек белән төзелә, инфраструктура да таләп ителә: тимер юл салучылар өчен торак, балалары өчен мәктәп, фельдшерлык пункты, сәүдә нокталары, коммуналь челтәрләр, энергетика... Әнә шул рәвешле тимер юл тирәли без хәзер белгән Әгерҗе күтәрелә.

1919 елда Әгерҗенең үз паровоз депосы барлыкка килә. Аның тарихы – ул илебез тарихы да. Музейда бронепоезд модельләрен күрергә мөмкин. Әгерҗедә ике бронепоезд җыела, икесе дә – хәрби чорда: 1918 һәм 1942 елларда. Гражданнар сугышы барганда да, Бөек Ватан сугышы чорында да тимер юлчыларның үз каһарманнары була – аларның исемнәре белән тепловозларны атыйлар, портретларын музей түренә эләләр.

Хәзерге көндә Әгерҗе – Россия тимер юллары системасындагы иң эре сортировка станцияләренең берсе. Тәүлек эчендә станция аша 10 меңгә якын йөк вагоны уза, шуларның 3 меңенә биредә сортировка ясала, һәм алар төрле тарафларга җибәрелә. Социаль мохит өчен хәзер инде җирле депо җавап бирми, моның белән шәһәр шөгыльләнә. Шулай да шәһәр бюджетының бик зур өлешен элеккечә тимер юл тәэмин итә. Һәм аңлашыла да, алып баручы юл булмаганда, нинди якты киләчәк турында сүз булырга мөмкин? Район гербына төшерелгән җайдакның алга сузган кулын да искә төшерик.

Һәркемнең – үз юлы, ә минә эгерҗелеләрнеке – тимердән.

Фото: Александр Ефремов

УҢЫШНЫҢ ГАДИ РЕЦЕПТЫ

Әгерҗедә киләчәккә зур өметләрне, һичшиксез, үсеп килүче буын белән бәйлиләр.

Мәсәлән, Тажи Гыйззәт исемендәге 3 нче шәһәр мәктәбе укучылары белән – алар үз укытучыларын укуда, спортта, иҗатта ирешкән уңышлары белән куандыра. Әлеге уңыш, әйтик, 8 А сыйныфы укучыларының, сыйныф җитәкчеләре Венера Ишмөхәммәтова һәм ата-аналары белән бергә, зур театральләштерелгән презентация ясауларында да чагылыш таба. Шуңа тикшеренү проектын да өстәп, алар ата-аналар комитетларының «Тату сыйныф серләре» дип аталган республика бәйгесендә катнаша. Проект сугыш вакытында Әгерҗедә эшләгән эвакогоспитальгә багышланган.

Серләр, дигәннән. Ул нинди серләр икән?

– Үзара аңлаша белү...

– Бер-береңә ярдәм итү... – дип, узыша-узыша аңлатырга керешә укучы балалар.

Әти-әниләре аларның сүзен җөпләп тора. Һәм без уңышның сере бердәмлектә булуын аңлап алабыз. Балаларның, педагогларның һәм әти-әниләрнең бер йодрык булып эшләвендә. Кичләрен гаиләләре белән җыелышып репетицияләр уздырганнарын да рәхәтләнеп искә ала үсмерләр: идеяләре белән ничек бүлешкәннәрен, бәхәсләшкәннәрен, елаганнарын, көлгәннәрен... Шул кичләрдә алар тату бер гаиләгә әверелүләрен сизми дә кала. Нәкъ менә шул җиңәргә булыша, көч бирә дә инде...

Җиңү өчен бүләге дә шәп була – 8 А сыйныфы 21 көнгә Кырымдагы «Ак Барс Форос» лагерена барып ял итеп кайта. Хәзер аларның уртак тәэсирләре һәм истәлекләре тагын да күбрәк.

Якты киләчәккә килгәндә, кызлар белән малайлар аңа чын күңелдән ышана. Педагоглар да аларның кыю ниятләрен хуплап тора, күренекле якташларының уңышлары турында сөйләп, зур хыялларга рухландыра. Әйтик, якташлары Тажи Гыйззәтне дә монда яхшы беләләр һәм иҗатын яраталар. Әгерҗе районының кечкенә генә Барҗы-Омга авылында күп балалы ярлы крестьян гаиләсендә туып үскән бу малай күренекле татар драматургына әйләнә. Мәктәп музеендагы экспонатлар аның тормышы һәм иҗаты турында сөйли: монда кулъязмалар да, спектакльләрдән күренешләр чагылыш тапкан фотографияләр дә саклана. Язучының эш кабинеты өлешчә торгызылган: чын язу машинкасы, эш өстәле, борынгы буфет һәм савыт-сабалар... Әлеге шәхси әйберләрне музейга язучының улы Казбек тапшыра. Ул хәзерге заман Әгерҗе укучыларының күз алдында этисенең үрнәге торуын тели. Уңышка талант, хезмәт һәм үҗәтлек аша ирешеп булуын аңлап үссеннәр, ә киләчәк – күрсәтер.

– Бәхетле гаилә тормышының сере нәрсәдә? – дип сорыйм мин Фирая һәм Рафаэль Гыйззәтуллиннардан. Алар инде 49 ел иңгә-иң куеп яши. Рафаэль Равилович бер мәзәкне искә төшереп көлә: «Ире хатынына әйтә ди: «Тиздән алтын туйны бәйрәм итәчәкбез». Хатыны аптырый: «Без бит әле биш ел гына бергә торабыз». «Синең белән торган бер ел ун елга тиң», – дигән, имеш, ире».

Һәм өстәп куя:

– Ә безнең киресенчә, илле елыбыз биш елдай узды да китте... Сизми дә калдым!

ЯРТЫ ГАСЫР – БЕР ЕЛДАЙ...

Евгения Чеснокова

Әгерҗенең Иске Эсләк авылында яшәүче Гыйззәтуллиннарның алтын туе киләсе елда булачак. Ә быел аларга «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медале тапшырылган. Бу ике йөрәкне үзара хөрмәт кенә түгел, ә һөнәрләренә тугрылык та берләштерә: икесе дә утыз елдан артык туган мәктәпләрендә укытучы булып эшләгән. Рафаэль Равилович – биология белән географияне, ә Фирая Изаховна химия укыткан, завуч вазифаларын да башкарган.

ӘТИ-ӘНИ КИҢӘШЕ БЕЛӘН

Гаилә кыймммәтләре алар өчен һәрчак беренче урында тора. Ник укытучы булырга уйладыгыз, дигән сорауга да Рафаэль Равилович болай җавап бирде: «Әни киңәше буенча, ул укытучы иде». Фирая Изаховна да әтисенең аны укытучы итәсе килүе турында әйтте. Шулай итеп, икесе дә Казан педагогика институтына керә. Әлеге һөнәрне сайлауларына беркайчан да үкенмәгәннәр. Җитмәсә, бу уку йорты аларны кавыштырган да – бер төркемдә укыганнар.

Уллары турында да: «Безнең сүздән чыкмадылар», – ди алар. Олы уллары Алмаз, әтисе кебек үк, биологияне сайлаган – ул фән кандидаты, Казан федераль университетында укыта. Кече уллары Илназга әти-әнисе юрфакка барырга киңәш итә. Ул да башта биологияне сайларга талпына, әмма шулай да ахыр чиктә әтисе белән әнисен тыңлый. Хәзерге вакытта Илназ Гыйззәтуллин – Түбән Кама шәһәр суды рәисе урынбасары.

Фотолар: Александр Ефремов; Гыйззәтуллиннарның шәхси архивыннан

ТЕОРИЯ БЕЛӘН ПРАКТИКА

Фирая белән Рафаэль дүрт ел очрашып йөри. Институтны тәмамлагач, Рафаэль үз районына эшкә билгеләнә, ә Фирая үз ягына – Буага кайтып китә. Диплом алганнан соң бер ел узгач кына өйләнешә алар.

– Студент чакта өйләнешмиләр иде ул чакта, торырга урын да юк, акча ягы да такыр... – ди Фирая апа.

Рафаэль Гыйззәтуллинның укучылары республикакүләм яшь натуралистлар слётында һәм биология буенча олимпиадаларда әллә ничә мәртәбә урыннар яулаган. «Педагог буларак, серем гади минем, – ди Рафаэль Равилович, – даими укырга, үзеңне үстерергә, өстәмә китапларны укучыларыңа да укырга тәкъдим итәргә кирәк. Шуңа өстәп, мәктәп яны хуҗалыгы, биолог буларак, мәктәпне ел буена уңыш белән тәэмин итү – синең бурыч!»

Хәзер авылда мәктәп юк, балалар аз калган. Ул ябылганда инде Гыйззәтуллиннар лаеклы ялга чыккан була. Әмма күрше авылга йөрергә мәҗбүр булган укучылары да аларны сагынган: «Сезнең кебек укытучыларыбыз юк», – дигән сүзләре әле бүген дә гомерләрен укытуга багышлаган мөгаллимнәрнең күңелен җылыта.

БАЛ КОРТЫ – КАЙДА, ЧӘЧӘК – ШУНДА

– Мин биология белән мәктәптән соң да хушлашмадым, – дип елмая Рафаэль абый. Аның балы, чыннан да, телне йотарлык! Бал кортларын карарга каникулга кайткан оныклары да булыша икән, алар – дүртәү.

Фирая апа пенсиядә чигү белән мавыгып киткән. Хәзер аларның ишегалды, бакчалары гына түгел, өй эче дә чәчәккә күмелеп утыра. Шуның өстенә ул тагын гарәп телен өйрәнергә ниятләгән, аның бу теләген авыл мәчете имамы да хуплаган.

Алар мәктәпнең ябылуына әрниләр, билгеле. Яшьләрнең авылдан китүенә, балаларның аз калуына да борчылалар.

– Әмма аңа карап кына тормыш барыбер туктап калмый бит, – дип фикер йөртә Фирая апа. – Хәзерге яшьләрнең омтылышлары башка, аларга заманнан калмый алга барырга кирәк...

Үзләре исә гомер кичкән авылларында бик рәхәтләнеп яши. Йортны да кадерле, диләр, шулай булмыйча, кайчандыр этиәниләре белән бергә күтәргән нигез бит.

– Хәзер бит авылда бөтен нәрсә бар, – ди Рафаэль абый, – юллар да салынды, телефон да сузылды, интернет та эшләп тора. Кайчак уйлап куям-куюын – шәһәрдә яшәсәк, дим, хуҗалык белән болай шөгыльләнмәс идек, ә аннары ул уйдан кире кайтам. Монда – саф һава, тынлык, табигать... Пенсиягә чыккач, авылда яшәүдән дә рәхәте юк инде барыбер!

«ДӨНЬЯГА БЕР КҮЗ БЕЛӘН КАРЫЙБЫЗ»

– Ә шулай да, бергәләп бәхетле гомер кичерүнең сере нәрсәдә соң? – дип, һаман үзсүзлеләнәбез без.

Фирая Изаховна гаилә альбомнарын алып килә. 1975 елгы фотодан безгә аларның яшьлеге – кияү белән кәләш чагындагы сурәтләре карап тора. Карашларында – бер-беренә хөрмәт, наз. Ә бит бу наз аларның карашында хәзергә кадәр сакланып калган.

– Иремнең холкы бик яхшы минем, – дип елмая Фирая Изаховна. – Беркайчан да киреләнми ул, үпкәләми. Андый кешеләр сирәк бит...

Моңа җавап итеп Рафаэль абый үзенекен өсти:

– Хатынымның холкы әйбәт, зирәк ул. Җитмәсә, без дөньяга икебез дә бер күз белән карыйбыз, шул яктан уңдык. Фикерләребез дә гел туры килә.

Чыннан да олы бәхет бит бу!

МӘСНӘВИЯ ИСМӘГЫЙЛЕВАНЫҢ ГАИЛӘ БӘХЕТЕ СЕРЛӘРЕ

Әгерҗедә аның таң белән бакчасында үлән чапканын күреп берәү дә аптырамый. Җил очыртып китәрдәй җиңел гәүдәле Мәснәвия апа чалгысы белән алны ирләрдәй алдырып бара. Өйләрендә газон кисә торган җайланма юклыктан түгел, ә эшне менә шулай яратып эшләргә күнеккәннән. Чалгы тотарга аны 12 яшендә әнисенең ир туганы өйрәткән.

– Әйбәт кеше иде, – дип искә ала аны 95 яшьлек Мәснәвия апа. – Мине күп нәрсәгә өйрәтте ул.

БАКЧА ФАНАТЫ

Мәснәвия Сәгыйтовна бакча эшләрен бик ярата. Аны бакча фанаты дисәк тә ялгыш булмас.

– Бәрәңге утыртырга яратам, суган чүбе утарга, үлән чабарга... – дип санап китә ул. – Әгәр болар барысы да гөрләп үсеп утырса, бакчаны карау ул – җан рәхәте генә. Уңышка куану да – бер рәхәт! Хәзер бит бөтен нәрсә бар, аптырап торасы юк. Сугыш вакытындагы кебек түгел инде. Ул чакта ач тамакны туйдырыр өчен үлән, алабута ашадык... Туң йөгергән җирне актарып, казып, черегән бәрәңге тапсаң да – бәхет иде. Ач булды халык, кырылып үлде...

ЫШТАН ТУЛЫ – БАЛЫК

Әни безне – биш баланы – сугыш елларында берүзе күтәрде. Әти – фронтта. Елгада никтер балык күп булды. Ул балыкны әйбәт тота иде – ыштан тутырып. Ыштаннарын буып бәйләп куя да, балыкны судан сөзеп кенә ала. Чиләк белән сөзгәндәй – ыштан тулы балык кайта өйгә, ач булмыйбыз.

Авыр заманнар иде ул: сугыш барганда да, сугыш беткәч тә, әмма бу минем балачак һәм яшьлек елларым. Ничек кенә булмасын, барыбер анда кайтырга теләр идем. Чөнки анда әти белән әни исән-сау, туганнарым. Хәзер инде берсе дә юк. Гаиләбездән бер мин исән...

ИТӘК ТУЛЫ ОНЫК

Шулай да ул ялгыз түгел: балалары, оныклары, онықчыкларының фотолары белән өй диварлары тулган. Аның зур, тату гаиләсендә – өч кыз, 10 онык, 14 онықчык. Кадерле, яраткан өч киявен дә онытырга ярамый!

Фото: Александр Ефремов; Исмәгыйлеваның гаилә архивыннан

– Барысы да – бик әйбәтләр, барысын да бик яратам, – дип елмая Мәснәвия апа, 95 яшьлек юбилеенда төшкән фотоларны күрсәтеп. Биредә аның бөтен кадерле кешеләре җыелган. Бик күңелле булды, дип куанып туймый. Бәйрәм торты да булган. Бүләкләрне инде – әйтеп торасы да юк.

МАГНОЛИЯЛӘР ҮСКӘН ТАРАФТА

– Ә күптән түгел генә без әнине диңгезгә алып бардык, – дип сөйли Мәснәвия апаның кече кызы Идия. – Әни анда да өздерде генә – кичләрен яр буенда музыка ишетсә, рәхәтләнеп бии башлый!

Безгә Мәснәвия апаның диңгез яры буенда – магнолияләр үскән тарафта биегән видеоларын да күрсәтте...

Аның көр кәефенә, тормышны яратуына сокланып туеп булмый.

«ЭШЛӘРГӘ КИРӘК, ЗАРЛАНЫП УТЫРЫРГА ТҮГЕЛ»

– Барысы да начар дип зарланып утырырга түгел, эшләргә кирәк! – ди Мәснәвия апа. – Хәзер начар түгел лә заманнар, бөтен нәрсә дә бар. Менә юк чакларны күрсәгез... 15 яшемдә колхозда чөгендер эшкәрткән чагымны хәтерлим. Сузылып киткән иксез-чиксез чөгендер басуы әле дә күз алдымда тора... Эссе, сулап булмый... Мин үз артымнан чүп калдырмый идем, җитез дә. Тырышып эшлим. Ә күршедәгеләрнең чүбе кала. Җыя башлагач, малай, минем түтәлгә кермәсеннәрме... Чөгендер җыю планын үти идем гел! Булдыклы идем! Миңа ул чакта хәтта премия дә бирделәр әле, – ди Мәснәвия апа һәм премиясен исенә төшереп көлә. – Акча дип уйлыйсызмы? Каян булсын?! Ике кәтүк! И сөенгәннәрем шул кәтүккә – ул вакытта җеп табу бер бәла иде...

ХАНСУӘР – ТРАНССЕБЕР

19 яшендә Мәснәвия апа Баулы районындагы туган авылы Хансуәрдән Юрга тимер юл станциясенә юл тота (Транссебер магистрале, Кемерово өлкәсе. – Ред.).

– Анда урман эшендә эшләдек. Ирләр урманны ега, ә без ботакларны кисәбез, җыябыз.

Шул урман эшендә Мәснәвия апа булачак ире Хәйдәрне очрата.

– Әйбәт кеше икәне шунда ук күренеп тора, – дип сөйли. – Кулында эш уйный. Балта остасы диярсең, эшли дә куя. Кызыксынучан да иде. Башка балта осталарына барып, бушка да эшләде – өйрәнеп кайта тегеләрдән. Кешедән өйрәнеп, мич тә чыгара башлады. Безнең бу өебезгә инде 60 ел буладыр. Бөтен нәрсәне аның белән үзебез эшләп, җиткереп чыктык – түшәмен дә, идәнен дә.

РУС ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ

Мәснәвия апа ире белән Әгерҗегә тимер юл эшенә килгәндә, бер авыз да русча белми торган була.

– Тамчы да, – дип көлеп искә төшерә үзе. – Ул курыкканнарым! Ничек сөйләшермен, кеше белән аңлашырмын икән, дим. Башкаларны ничек аңлармын? Мин экипировщица булып эшләдем, снабжение иде өстемдә. Ә ирем депода кочегар иде. Курыксам да, өйрәндем. Кайчагында, машинистлар тыңламаганда, аларга өч катлы сүз белән дә кычкырып, ачуланып ташлый идем... Шунда ук аңга киләләр!

АЛАР МИНЕМ ЮЛДАН КИТТЕ

Тормышын күздән кичереп, Мәснәвия Сәгыйтовна ирен гел җылы сүзләр белән генә искә төшерә, балаларын да гел мактый.

– Алар да минем юлдан китте. Без ирем белән гел эштә булдык, тырыштык. Балалар да эш сөя торган, булдыклы булып үсте. Дөрес тәрбиянең сере шул гына аның – эшне яратырга өйрәнсеннәр.

Кем эшләми йөри, андый кешегә гел әйтәм: «Эшләргә кирәк! Тырышырга! Ялкауланырга ярамый! Кулыңда эшең булса – бар да әйбәт булачак!»

TILLERMASTER

УРТАЧА ТИЗЛЕКЛЕ КУЛЬТИВАТОР

AGROMASTER

- Тоташ, парга һәм чәчү алдыннан эшкәртү һәм дымны каплау өчен кулланыла торган тиз йөрешле агрегат
- Бер тапкыр йөреп чыгып культивацияли, тыгызлап яту урыны булдыра, чүп үләннәрен кисә, мүлчәли, туфракны тыгызлый. «Компакторларга» охшаш.
- Югары тизлекле булуы туфракны эшкәртүнең яхшы сыйфатын тәэмин итә.
- Спираль-пружиналы терәкләрдә уксыман табан тирбәлә һәм туфракның вак структурасын формалаштыра.
- Колачының киңлеге - 3,3 метрдан 20 метрга кадәр

MEGADISK

КИҢ КОЛАЧЛЫ ДИСКЛЫ АГРЕГАТ

- Зур мәйданнарны, мәсәлән, бөртеклеләрне җыеп алганнан соң камылларны тиз һәм җитештерүчән итеп беренчел эшкәртү өчен каралган киң колачлы агрегат.
- Арттырылган алым киңлеге (18 метрга кадәр) һәм уникаль җитештерүчәнлеге белән аерылып тора.
- 560 мм зурлыктагы агрессив авыр дисклар куелган. Һәр дискны индивидуаль борылыш күчәренә урнаштыру эшкәртү почмагын туфрак шартларына карап көйләргә мөмкинлек бирә.
- Тәүлегенә 400 гектарга якын җирне эшкәртә ала!

LANDMASTER

КҮЧӘРЛЕ КУЛЬТИВАТОР

- Туфракны 18 сантиметр тирәнлеккә кадәр төп тоташ эшкәртү өчен каралган.
- «Landmaster» культиваторы белән эшкәртү туфракның кибүен, катып китүен, туфрак кабыгы хасил булуны кисәтә.
- Органик һәм минераль ашламаларны, үсемлек калдыкларын туфракка тулысынча кертүне тәэмин итә.
- Тырма-штригель туфракны ваклый, аның өслеген тигезли, мүлчәләнгән катлам формалаштыра, үсемлекләрнең тамырын ныгыта һәм орлык шытымын арттыра.
- Агрегатның тиз күчеп йөри алуы. Эксплуатацияләүдә һәм хезмәт күрсәтүдә таләпчән түгел.

COMBIMASTER

БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ДИСКОКУЛЬТИВАТОР

- Туфракны интенсив эшкәртүне күздә тоткан авыр дисклы һәм чөйсыман табанлы җайланма туфракны 5 см дан 18 см га кадәр тирәнлектә югары сыйфатлы итеп эшкәртү өчен ясалган.
- Туфракка тагын да интенсиврак һәм төрле яклап тәэсир итү хисабына җир бер йөреп чыгуда ук яхшы итеп эшкәртелә.
- 12 см тирәнлеккә җитә торган ике рәт авыр диск һәм 5 см тирәнлеккә җитә торган өч рәт культиватор табаны куелган.
- Россия шартлары өчен махсус эшләнелгән органнар һәм сынау үткән узеллар кулланылган гади һәм ышанычлы конструкция.

ПРОИЗВОДСТВЕННАЯ КОМПАНИЯ
AGROMASTER
ЕВРОПЕЙСКОЕ КАЧЕСТВО - РОССИЙСКАЯ ЦЕНА!
www.pk-agromaster.ru
тел.:8(85556) 2-39-08, 8(85556) 2-43-56

тел.: 8(85556) 2-39-08
тел.: 8-939-396-83-44
e-mail: agromaster@mail.ru

Татарстан Республикасы,
Мөслим авылы,
Тукай урамы, 33 а

www.pk-agromaster.ru

Европа сыйфаты – Россия бәясе!

РЕКЛАМА

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Шаһбазгәрәй Әхмәрев **кайда** эшләгән

Кем ул тәнкыйть күгендәге якты йолдыз

Сарсак-Омга **кайсы** ягы белән үрнәк авыл

Татарстанның иң шәп блогерлары Сабан туен **кайда** үткәрә

МӘГЪРИФӘТЧЕ ИНСПЕКТОР

Илдус Заһидуллин

XIX гасырның икенче яртысы татар мәгърифәтчеләренең фикри эзләнүләрендә рус уку йортларында укыткан Каюм Насыйри, Мөхәммәтгали Мәхмүтов кебек шәхесләрнең хезмәтләре мөһим урын били. Бу кечкенә төркемдә Казан университетын тәмамлаган, 1881–1900 елларда Казан татар укытучылар мәктәбе җитәкчесе булган мәгърифәтче рухлы Шаһбазгәрәй Исмәгыйль улы Әхмәревнең эшчәнлеге дәүләт биргән мөмкинлекләрне татар милләтен үстерү өчен файдалану ягыннан игътибарга лаек.

УКУ ЕЛЛАРЫ

Шаһбазгәрәй Әхмәревнең төпчек кызы Заһидә Тинчурина истәлекләреннән күренгәнчә, нәсел-нәсәбе Сембер губернасыннан булган «чабаталы морза» Исмәгыйль Әхмәр улы рекрут хезмәтеннән русча укырга-язарга өйрәнеп кайткан. Казанда дәүләт хезмәтенә кереп, «губернский секретарь» чинында отставкага чыккан. Улы Шаһбазгәрәйне һәм кызы Фатыйманы үзе татарча һәм русча укыткан, дин сабагын да өйрәткән. Ләкин икенче гимназиядә казна хисабына укучы улының аттестат алуын күрмичә үлеп киткән.

Тормыш үз агымы белән барганда, VII сыйныфка күчкән Шаһбазгәрәй белән хакимият вәкилләре кызыксына башлый. Казан уку-укыту округының татар, башкорт һәм казах уку йортлары буенча инспекторы Василий Радлов, 1872 елда Уфада Татар укытучылар мәктәбен ачкач, яңа уку йортында эшләрлек югары белемле мөселманнар булмавын ачыклый һәм Казан гимназияләрендә укучы татарларны барлый, шул рәвешле сукыр әнисе һәм сеңлесе белән Иске татар бистәсендә көн күрүче Шаһбазгәрәй белән таныша.

Радлов егетнең университетка кереп укырлык акчасы булмавын ачыклангач, 1873 елда халык мәгарифе министрыннан 20 яшьлек Шаһбазгәрәй өчен 200 сумлык стипендия алуга ирешә. Акча егет университетның тарих-филология факультетын тәмамлаганчы һәр елны түләнеп бара. Әйтергә кирәк, 1870 елда шундый ук стипендия шушы ук факультет студенты чуваш Иван Яковлевка да түләнә.

Бер ел хөкүмәт стипендиясенә укыгач, Шаһбазгәрәй, Медицина-хирургия академиясенә укырга керергә теләге булуын әйтеп, 1874 елның августында ректорга укудан чыгаруны сорап гариза бирә. Гариза вакытында каралмый, егет университетта калырга карар кыла.

Студент вакытында Шаһбазгәрәй Казанда үзе мөдир булган башлангыч рус-татар училищесында һәм 5 нче мәчет каршындагы Сәгыйтов мәдрәсәсенең рус классында укыта. Шәһәрдә беренче рус-татар училищесы ачкан Каюм Насыйри белән таныша.

1876 елны Казан татар укытучылар мәктәбен (КТУМ) оештыргач, Василий Радлов университетның өченче курсын тәмамлаган студентны шунда рус теле һәм әдәбияты укытучысы итеп чакыра. КТУМда инспектор (мөдир) булып Мөхәммәтгали Мәхмүтов эшли, дин сабагын 1880 елның җәенә кадәр мулла Шиһабетдин Мәрҗани укыта. Шушы шәхесләр белән аралашу Әхмәревнең мәгърифәтче булып формалашуына зур йогынты ясый.

КТУМ ҺӘМ МӨСЕЛМАН УКУ ЙОРТЛАРЫ ИНСПЕКТОРЫ

1881 елда Мәхмүтов КТУМ инспекторы вазифасыннан киткәч, аның урынына 28 яшьлек Шаһбазгәрәй Әхмәрев билгеләнә.

1884 елны төрколог Василий Радлов, Санкт-Петербург Фәннәр академиясенә сайланып, башкалага күчә. Моңарчы

Фотолар автордан алынды, tatarica.org

КТУМда уку-укыту эшләре белән Радлов шөгыльләнгән булса, хәзер бу мәшәкатьләр дә инспектор җилкәсенә күчә. Ул да түгел, Әхмәрев 1885 елда Радлов урынына Казан уку-укыту округының татар, башкорт һәм казах мәктәпләре инспекторы вазифасын башкара башлый, шул елны Казан губернасы авылларында 2 рус-татар мәктәбе ачуга ирешә. 1885 елда - Вятка һәм Казан губерналарындагы, 1887 елда - Әстерхан шәһәрендәге, 1890 елда Вятка губернасындагы рус-татар мәктәпләрен барып тикшерә.

Башкалада йогынтылы элемтәләргә ия миссионер Николай Ильминский тәэсирендә Казан уку-укыту округы җитәкчелеге бу елларда яңа рус-татар мәктәпләре ачу белән белән кызыксынмый башлый. 1889 елда округтагы татар, башкорт һәм казах мәктәпләре инспекторы штаты кыскартыла һәм аның вазифаи бурычлары КТУМ инспекторына йөкләнә.

Әхмәрев, тырышып эшләп, 1892 елга шәһәр мөселманнарының КТУМга карата булган тискәре карашын уңай якка үзгәртүгә ирешә, аның үзенчәлеген саклап калу һәм укытуны яхшырту турында кайгырта. 1892 елда башкалада КТУМны ябу турында сүз чыккач, шәһәр чиновниклары белән бергә аны саклап кала, казна хисабына укучылар санын 24 тән 30 га җиткерүгә ирешә. 1898 елда ул җитәкләгән педагоглар коллективы, округ попечителенең КТУМ укучыларының татар бүрекләрен – фуражкага, казакиларын – европа костюмы белән алыштыру турындагы боерыгына каршы чыгып, элекке кием формасын саклап кала. 1900 елда КТУМда татарлар белән бергә русларга да белем бирү тәкъдимен дәлилле итеп кире кага.

1897 елдан башлап, КТУМда даими рәвештә укучылар көче белән рус телендә пьесалардан өзекләр куела, төрле кичәләр, концертлар оештырыла башлый. Дисциплинаны саклау йөзеннән, тәртип бозган укучыларга карата кырыс чаралар да кулланыла, кайберләре укудан чыгарыла һ.б.

Ул инспектор булган елларда КТУМда Гайнетдин Әхмәрев, Исхак Казаков, Габдрахман Рафиков, Мөхетдин Корбангалиев, Садри Максуди, Гаяз Исхакый кебек XX гасыр башында татар милләте үсеше өчен зур хезмәт куячак егетләр белем ала.

МӘГЪРИФӘТЧЕ ГАЛИМ, ПЕДАГОГ ҺӘМ ЧИНОВНИК

1887 елда сәүдәгәр һәм татарча беренче драма әсәре авторы Габдрахман Ильяси, туган телдә «Казан» исемле атналык газета нәшер итәргә рөхсәт сорап, Матбугат эшләре буенча баш идарәгә гариза бирә. Бу инициатива бер төркем шәһәр зыялыларының, шул исәптән Шаһбазгәрәй Әхмәревнең дә, уртак проекты булып чыга. Инспектор, Казанда көнчыгыш телләр буенча цензор булмау сылтавы белән тискәре җавап алынудан куркып, газета чыгарырга рөхсәт бирелсә, мин матбагага бушлай цензура ясарга алынырмын идем дип, гариза яза. Шунысы игътибарга лаек: аның гаризасы - 11 октябрьдә, Ильясиның гаризасы, бер көн соңга калып, 12 октябрьдә язылган була.

Ләкин башкаладан барыбер тискәре җавап килә.

1894 елны КТУМ инспекторы үз редакторлыгында «Казан» исемле татарча һәм русча атналык газета нәшер итәргә рөхсәт сорый.

Гаризада Әхмәревнең мәгърифәтчелек карашлары чагылыш таба. Газетаның программасында редакциянең Санкт-Петербургта үз хәбәрчесе булачагы, рәсми хәбәрләрдән тыш, төбәк, башкала һәм чит дәүләтләрдә булган вакыйгалар хакында мәгълүмат биреләчәге, мәктәп һәм мәгариф, авыл хуҗалыгы мәсьәләләре, сәнәгать һәм мәдәният үсеше, юбилейлар һәм рус телендә яңа басылган китаплар, шулай ук татар тормышы, дәреслекләр һәм укыту программалары хакында язу карала.

Әхмәрев, татарча матбаганың кирәклеген дәлилләп, болай дип аңлата: татарларның мәгърифәтле катлавын тәшкил иткән руханилар урта гасырда язылган дини китаплар буенча гына белем бирә һәм дөньяви фәннәр гыйлем түгел, ә һөнәр дигән фикер тарата. Татарларның 60 проценты укый

Шаһбазгәрәй Исмәгыйль улы һәм Хәдичә Шаһиәхмәт кызы. Казан, 1879 ел.



Шаһбазгәрәй Әхмәревнең «Синтаксический разбор глагола в казанско-татарском наречии» исемле китабы.

белә, әмма бу көнгәчә аларны рус мәдәнияте һәм иҗтимагый тормышы белән таныштырырлык бер генә китап та басылмаган. Шул ук вакытта алар, шәһәр һәм земство үзидарәсе органнарында сайланган әгъза, шулай ук мәхкәмәләргә чакырылган утырышчы буларак, төбәк тормышында катнашалар, госманлы телендә яки шул телдән тәрҗемә ителгән күпсанлы тарихи һәм башка әчтәлекле китаплар укыйлар. Фәкать татар телендәге басма сүз генә аларга дәүләт кануннарының кирәклеген һәм файдасын аңлатачак, Ватаныбызның дәүләти, иҗтимагый корылышына дөрес караш уятачак, халык арасында дөньяви белемнәр һәм файдалы һөнәрләр турында мәгълүмат таратырга мөмкинлек бирәчәк, дип дәлилли.

Инспектор үз гаризасын, алдан хәстәрен күреп, ягъни башта Казан уку-укыту округы попечителе һәм губернаторның уңай фикерләрен алып юллаган була. Ләкин Казан губернаторы, инспектор белән сөйләшкәндә теләктәшлек күрсәтсә дә, үзе Матбугат эшләре буенча үзәк идарәгә икенчерәк фикерле хат юллый. Хатында Әхмәревне шәхес һәм чиновник буларак мактап һәм аның редакциясендәге газетаның бернинди куркыныч тудырмачаягын әйтеп, кайбер шик-шөбһәсен дә белдерә. Аныңча, татар телендәге әдәбият һәм вакытлы матбага үсеше Россиядә көн күрүче рус булмаган кавемнәргә тәэсир итми калмаячак. Бу үсеш әйткән кавемнәрнең рус халкы белән якынаюы һәм кушылуы өчен хезмәт итә алыр микән: татарларның үз диненә һәм теленә булган мәхәббәте Россиядә яшәүче барлык инородецларга караганда да көчлерәк, татарлар руслар йогынтысына бик аз бирелә, туган телләрендә әдәбият үсеше фәкать инородецлар арасында милли үзаң уянуга, ә бәлки тагын да артыгракка китерергә – сәяси хыяллар уятырга мөмкин. Сүзен Казанда чит телләр буенча цензор булмавын да әйтеп йомгаклый. Башкаладагы көнчыгыш телләрдәге әдәбият цензоры В.Д. Смирнов, эксперт сыйфатында чыгыш ясап, газета төрле төбәкләрдә таралып яшәүче татарларны берләштерергә ярдәм итәр иде, ә патша хөкүмәтенә алар арасында элемтәләр никадәр йомшак булса, шулкадәр яхшырак, дигән фикерен җиткерә.

Әлбәттә, бу сүзләр рәсми тискәре җавапка кертелми.

Инспектор 1895 елда да газета чыгарырга рөхсәт сорап карый, ләкин бу юлы да уңышка ирешми.

Бер үк вакытта Әхмәрев рус вакытлы матбугатында, «Мусульманин» тәхәллүсен куеп, мәкаләләр дә бастыра. Кайберләрендә русча укырга өнди. Әйтик, «Волжский вестник»та (1885 ел, № 23, 27 гыйнвар) милләттәшләренә мөрәҗәгать итеп, Казанда 18 мең татарга университетта 2 генә студент туры килүен һәм өч ирләр гимназиясендә укучылар саны унга да җитмәвен ассызыклап, һәр мөселман белергә тиешле ислам диненең дөньяви белем

Әхмәревләр гаиләсе. Казан, 1912-1913 еллар.

алуга комачауламавын яза. Икенчеләрендә («Городской и сельский учитель», 1897 ел, 2, 3 чыгарылыш) рус укучыларын татар җәмгыяте, аның казанышлары һәм проблемалары, дини укыту системасы белән таныштыра, Мөхәммәтгали Мәхмүтов, Галимҗан Баруди кебек шәхесләрне мактый.

Балаларның туган теленә нигезләнеп рус теленә өйрәтүче педагог тел гыйлеме белән дә кызыксына. 1890 нчы елларның беренче яртысында үз йортында булачак тел галиме Корбангали Мөхетдинов һәм Насыйбуллин фамилияле укучысы белән «Бәдәвам», «Алма китабы», «Бүз егет» исемле әсәрләрне әдәби яктан тикшерә. Аның татар теленең грамматикасы буенча хезмәте тәмамланмый кала һәм юкка чыга, ә «Синтаксический разбор глагола в казанско-татарском наречии» дәреслеге 1895 елда нәшер ителә. Ул рус теле укытучысы Миргаяз Иманаевның шул ук елны дөнья күргән «Русское слово» уку әсбабын басмага әзерләүгә дә үзеннән лаеклы өлеш кертә.



Казан татар укытучылар мәктәбе. XX гасыр башы.

ГАИЛӘ ТОРМЫШЫ ҺӘМ АРАЛАШУ ДАИРӘСЕ

Шаһбазгәрәй 1879 елда Казанның элекке полицмейстеры дворян Шаһиәхмәт Алкинның кече кызы Хәдичәгә өйләнә.

Ир традицион тәрбия алган хәләл җефетенә заманча тәрбия бирү өчен зур хезмәт куя. Мәҗлес-балларда башкалар сокланырлык итеп биергә өйрәтә. Репетитор яллап һәм үзе дә булышып, Хәдичәсен русча укырга һәм язарга өйрәтә, рус әдәбиятын укырга гадәтләндерә. Әхмәрева, Лев Толстойның берничә хикәясен татарчага тәрҗемә итеп, 1901 елда Оренбургта китап нәшер итә.

Әхмәревләр Татар бистәсендә дворян Алкиннар, Саиновлар, Терегуловлар белән кунакка йөрешә, хатыны ягыннан кайберләре белән туганлык җепләре бу аралашуны тагын да якын һәм мәгънәле итә. Әхмәрев татар зыялылары Мөхәммәтгали Мәхмүтов, Габдрахман Ильяси белән дә якын мөгамәләдә була.

Инспектор – XIX гасырның соңгы чирегендә Казанда татарлар арасында иң югары дәрәҗәгә ирешкән шәхес, дисәк, ялгыш булмас. Ул губернатор, Казан уку-укыту округы попечителе һәм башка мәгариф системасы чиновниклары белән эшлекле мөнәсәбәттә тора. Дуслары – университет хезмәткәрләре Николай Матвеевич Любимов, Николай Павлович Загоскин, Николай Федорович Катанов белән дә кунакка йөрешә. Шулай да аның иң якын фикердәше булып мөхтәрәм остазы Василий Радлов кала. Галим башкалага күчкәч, Казан белән Санкт-Петербург арасында бик җылы һәм әчкерсез хатлар йөри.

Гаилә хәленә килгәндә, яшьләр, өйләнешкәч, башта КТУМ бинасыннан ерак түгел дәүләт фатирында яши, гаилә ишәйгәч, Әхмәревләр Иске татар бистәсендә ике катлы йортка күченә. Соңрак шәһәрнең рус өлешендә зур йорт сатып ала. Яңа йортта ике улы белән Шаһбазгәрәйнең тол калган сеңлесе Фатыйма Терегулова да яши.

Әхмәревләр гаиләсендә 10 бала дөньяга килә, шулардан дүрт кыз һәм өч малай исән-сау үсеп җитә, барысы да русча дөньяви белем ала. Олы балалары Маһипәрвәз татар хатын-кызлары арасында беренчеләрдән булып 1891 елда Казанда рус гимназиясенә укырга керә.

Шулай бәхетле гаилә булып яшәп ятканда, 1900 елның 9 апрелендә 47 яшен тутырган Шаһбазгәрәй вафат була. Сәбәбе – вакытында дәваланмаган аппендицит перитонит китереп чыгара. Тол калган 38 яшьлек Хәдичә ханымга балаларын аякка бастыру һәм укыту өчен нык тырышырга туры килә.

Әхмәрев балалары Казанның рус уку йортларында татар укучыларының иң ишле төркемен тәшкил итә. Шуңадырмы, 1903 елда Казанда рус уку йортларында укучы татар яшьләренең «Шимбә» түгәрәге Әхмәревләр йортында оеша.

Татар һәм рус дөньясын үзенә сыйдырып, аларны бер-берсенә якынайтып яшәгән мәгърифәтче тормышының фәлсәфи мәгънәсе хакимият вәкилләре һәм рус зыялыларының, студентлар һәм гимназистларның, шәкерт һәм муллаларның аны соңгы юлга озатырга күпләп килүендә дә чагылыш таба.

КЫРЫС МИҺЕРБАНЛЫЛЫК

Фоат Садриев

Тәнкыйть юлын сайлаган әдипләргә икеләтә авырдыр. Сүзеңне заманның зилзиләләренә, айкалып торган айбалтасына, кешеләрнең кинә-ваклыгына карамыйча, бер үк вакытта каты итеп, әмма иҗатның асылына кул (тел) күтәрми, аны чалып ташламый җепкә тезәргә кирәк. Бүгенге заманда «тәнкыйть» төшенчәсен «әйтә беләмлек», дорфалык, затсызлык, аннан да хәтәре – белемсезлек алыштырганда затлырак затлар булган чаклар сагындырып куя.

Сүзне Фәрваз Миңнуллинның замандашы – язучы Фоат Садриевка бирик әле.

«МИН АННАН ШӨЛЛӘБРӘК ЙӨРИ ИДЕМ...»

– 1959–1965 елларда мин Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә читтән торып укыдым. Һәрбер яңа әсәрне йотлыгып укый торган, алар турында кызып-кызып бәхәсләшә торган яшьлек еллары... Нәкъ шул чорларда Фәрваз Миңнуллин югары эстетик зәвыклы, яңа әдәби әсәрләргә дәлилле бәя бирүче тәнкыйтьче буларак танылды һәм гомере буе үз принципларына тугры калды. Аның «Казан утлары» журналында аерым әсәрләргә күзәтүләрен, рецензияләрен без көтеп ала идек. Язучылар җыелышларында ясаган чыгышларында, саллы мәкаләләрендә, китапларында әдәби хәрәкәтебезнең уңай һәм кимчелекле якларын күрсәтеп, әдәби процессның үсеш юлларын да билгеләде. Олпат галим һәм язучы Тәлгат Галиуллинның аны «Тәнкыйть күгендәге якты йолдыз» дип атавы Фәрваз абыйга ифрат та туры килә.

– МИНЕМ БЕЛҮЕМЧӘ, УЛ РӘСМИ ИДЕОЛОГИЯГӘ ЫШЫКЛАНЫП, БЕР АРТЫНА, БЕР АЛДЫНА КАРЫЙ-КАРЫЙ КУРКЫП ЯЗМАДЫ. ӘГӘР АЛАЙ БУЛСА, ТӘНКЫЙТЬ МӘКАЛӘЛӘРЕННӘН ТОРГАН КИТАБЫНА «БАЛТА ЯВЫЗЛАР КУЛЫНДА» ДИГӘН ИСЕМ КУЙМАС ИДЕ. ГАДЕЛ ТӘНКЫЙТЬ СҮЗЕН УЛ АВТОРЛАРНЫҢ КҮҢЕЛЕ КИТЕЛМӘСЛЕК СҮЗЛӘР БЕЛӘН, АЛАРНЫ РӘНҖЕТМӘСЛЕК КИМӘЛДӘ ӘЙТӘ БЕЛДЕ.

Яшермим, мин Фәрваз Миңнуллиннан бераз шөлләбрәк йөри идем. Аның чыгышлары күбесенчә бик җитди, йөзендә дә кырыслык чалымнары булганга, тәнкыйть күсәге миңа да эләкмәгәе дип куркыбрак йөрелгәндер инде. Гел көтмәгәндә-уйламаганда безгә очрашырга туры килде. Бу 1983–1984 еллар тирәсендә килеп чыкты. Мине Әлмәт язучылар бүлеген җитәкләргә кыстый башладылар. Җитәкчелек эшеннән уттан курыккандай курка идем, төрле сәбәпләр табып баш тарттым. Ризалатырга диптер инде, Казанга Язучылар идарәсенә чакырдылар. Йөрәгемне учыма кысып бардым идарәгә. Гариф Ахунов Мәскәүгә киткән иде. Миңа аның урынбасары Фәрваз Миңнуллинга керергә куштылар. Бетү шушы икән дип, аның кабинетына атладым. Фәрваз абый, җитди карашы белән гипнозлагандай, мине каршысына утыртты һәм йомшак кына итеп:

– Фоат, син нишләп безнең тәкъдимнән баш тартасың? – диде.

Мин төп дәлил итеп гаилә мәсьәләсен куйдым. Беренче хатыным белән аерылышканымны әйттем. Әгәр мин Әлмәткә күчсәм, икенче хатыным белән дә аерылышырга туры киләчәк, чөнки ул шәһәргә аяк та басмаячак, дидем. Әнкәйнең дә авылда ялгызы яшәвен, аңа ярдәм кирәклеген әйттем. Фәрваз абый бер сорау да бирмәде, аның

Фотолар Йолдыз Миңнуллинаның шәхси архивыннан

күзләрендә әллә сагыш, әллә мине кызгану чаткылары күренгәндәй булды. Нишләптер, урыныннан торып, ишек яныннан урап килде һәм мине яклагандай йомшак кына итеп:

– Бар, Фоат, Мөслимеңә кайт, тынычлан. Мин сине аңладым, – диде.

Кабинетыннан чыкканда, мин дә аның күңеленең нечкәлеген, миһербанлылыгын аңлаган идем инде.

БИШ АЙЛЫК ЧИРАТ

Икенче очрашуыбыз Фәрваз Миңнуллин Татарстан китап нәшриятында эшләгәндә, 1987 елда булды. Мин «Шаһзаманов эше» дигән повесть һәм хикәяләрдән торган җыентыгымны нәшриятка алып килдем. Повесть әле басылмаган, аны «Казан утлары» журналына әле генә тапшырдым. Дөресен әйтим, икеләнебрәк тапшырдым. Чөнки әсәрдә партия райкомы секретареның үз кәнәфиен саклау өчен коточкыч түбәнлеккә төшүе күрсәтелә иде. Моның аяныч нәтиҗәләренең Илһам Шаһзаманов кебек гади кешеләр язмышына, гомумән җәмгыять тормышына китергән зарарын җанлы образларда гәүдәләндерергә тырыштым. Миңа нәшриятның матур әдәбият бүлеген җитәкләүче Фәрваз абыйның повесть турында нәрсә әйтүе бик тә, бик тә мөһим иде. Ул икеөч айдан шалтыратырга кушты. Өч ай үткәч шалтыраттым, ул укырга өлгермәдем, тагын бер-ике ай көт инде, диде. Ике айдан шалтыратам:

– Фәрваз абый, мин теге «Шаһзаманов эше» буенча... – дип җөмләмне әйтеп тә бетергәнче ул:

– Фоат, әллә син ул китабыңны укырга монда чират торалар, дип уйлыйсыңмы соң?! – диде.

Кәефсезрәк чагына туры килдем бугай. Аннары, ни генә булмасын, ул хаклы иде ләбаса! Мин ирексездән көлеп җибәрдем.

– Фәрваз абый, син ике айдан шалтырат, дигән идең. Синең әйткәнеңә җавапсыз калсам, бу бик әшәке сансызлык булыр дип уйладым да шалтыраттым инде.

Минем сүзләремә Фәрваз абый йомшак кына көлеп җавап бирде:

– Хәйләкәр син, Фоат. Ярар, укыгач хәбәр бирермен.

Аның җавабын озак көтәргә туры килмәде. Ул повестьны мактады. Миңа шуннан башка сүз кирәкми иде. Әсәр «Казан утлары»нда да басылды, аны нәшрият та 1989 елда китап итеп чыгарды.

АЛМАГАЧТА ПЕШКӘН ШАШЛЫК

Фәрваз Миңнуллин белән иң истә калган очрашулар Мөслимдә булды. 1992 елның җәендә Фәрваз абый белән Асия Минһаҗева, кызлары Йолдызны җитәкләп, безгә кайтып төштеләр. Озын юлдан соң, хәл-әхвәл сораша-сораша, күңелле генә ашап-эчкәч, мин аларны Салауз-Мухан авылына Асиянең әнисе Һашия апа өенә илтеп куйдым. Иртәгә табигать кочагына чыгарга сөйләштек.

Мин үзем шашлык пешерү остасы түгел. Шуңа күрә Бүләк белән Мөслимне сагынып ялга кайткан Наис Гамбәровны ярдәмгә чакырырга туры килде. «Шампур-мазарлар

1 Фәрваз Миңнуллин – Арча педагогика училищесы студенты.

2 «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә.

3 Шагыйрь Сибгат Хәкимне искә алырга җыелган бер төркем татар зыялылары.

4

Арча педагогика училищесы студентлары.

5

Яшь чак – шаян чак.

6

Фәрваз Миңнуллин.

7

Каләмдәшләр белән бергә.

8

Зәрия һәм Харис Хәбибуллиналарда кунакта. Әлмәт шәһәре.

да кирәк булыр бит инде», – дип сүз башлауга Наис: «Барысы да булыр», – диде, серле елмаеп. Кунаклар тәкъдиме буенча Салауз-Муханның алма бакчасына юнәлдек. Ярар, кирпечләр куеп, корыган агачлар ваклап учак яктык. Наис кайдадыр алма бакчасының түрендә йөри. Култыгына ниндидер чыбык-чабык кыстырып килеп җитте бу.

– Шампурлар кайда соң? – дип сорыйм, сабырсызланып.

– Менә бит, – ди Наис, култыгындагы чыбыкларга күрсәтеп.

Алмагачның нечкәрәк ботаклары икән бу. Ботакларны пычак белән юнгалап тигезләгәндәй итте дә, шашлыкларны шуларга кигереп чыкты, кирпечләр тезеп, күмер өстенә куйды.

– Белеп торыгыз, иң тәмле шашлык алмагач күмере өстендә, алмагач ботагында пешерелгән шашлык булыр! – диде.

Шашлыкны беренче кабуга ук, без аның сүзләренең хаклыгына ышандык. Озаклап, шау-гөр килеп сөйләшеп утырганда, шашлыкны да, аны пешерүчене дә, ул пешергәнне ашаучыларны да мактадык, табигатьнең гүзәл почмагына, безне очраштырган шушы мөлаем кояшлы җәйге көнгә рәхмәт укыдык.

«ӘҖӘЛЛӘРЕҢ ҖИТСӘ, ӘЙТ ҮЗЕМӘ...»

Әлбәттә, без, бер агачка бәйләп куелган дүрт аргамактай, нәрсә генә сөйләшсәк тә, әдәбият мәсьәләләреннән әллә ни ерак китә алмадык. Мин кайчандыр бик кырыс, җитди дип йөргән Фәрваз абыйның туктаусыз елмаеп-көлеп сөйләшүләре, нечкә ирониясе барыбызның да күңелен күтәрде. Шашлык ашап хушлангач, төрле чәчәкләр, үләннәр, агач яфраклары салып, учак өстенә чәй куйдык.

Каршыбызда җәйрәп яткан яшел болыннар, бормаланып аккан Ык елгасы, бик еракта кайнар рәшә дулкыннарында тирбәлгән иген басулары, әрәмәләр бездән нидер көтә иде. Бу илаһи тынлыкка чыннан да нидер җитмәгәндәй тоелды. Фәрваз абый Асиягә елмаюлы карашын төбәде. Асия, аны шундук аңлап, акрын гына җыр башлады:

Базарларга барсаң, ак тула ал,
Хаккайларын үзем түләрмен.
Әҗәлләрең җитсә, әйт үземә...

Асиянең күңелләрне айкалдырып яңгыраган моңлы җыры безне татлы да, ачы да хыял дөньясына алып китте. Асиянең кинәт бәреп чыккан вулкан ташкынындай кайнар тавышы көчәйгәннән-көчәйде:

Янбикәм, Янбикәм,
Синең өчен үзем үләрмен.

Урманнарга керсәм, адашмамын,
Менгән атым акбүз ат булса.
Авыр юллар үтеп, мин кайтырмын,
Көтәм диган сүзең хак булса.

Бу серле моң түбәнгә – Ык буйларына, болыннарга, басуларга, рәшәле офыкларга тарала, зәңгәр күк йөзенә күтәрелә. Без яшәү яменә сокланып, шушы җыр-моңда эреп,

бер кешегә әверелдек... Шул ук вакытта һәркайсыбыз үз язмышын күңеленнән уздыра, авыр сынауларның артта калуына куана иде.

Беренче җырны икенчесе, өченчесе алыштырды. Асия илаһи моңы белән безне тәмам әсир итте. Без барыбыз да бәхетле идек. Шулай да миңа бу мизгелләрдә Фәрваз абый белән Асиядән дә бәхетле кеше юк кебек тоелды. Алар Мөслимгә, Салауз-Муханга кайткан саен безнең очрашуларыбыз иң якты истәлекләр калдыра иде, һәм мин хәзер дә ул очрашуларны хәтеремдә яңартып ләззәтләнәм, сагышланам, уйланам...

КҮҢЕЛДӘ ОЧРАШАБЫЗ...

Соңгы очрашуыбыз 1993 елның көзендә булды. Нииндидер йомыш белән Казанга баргач, нәшриятка да кагылдым. Матур әдәбият бүлеге мөдире, районлашым Харрас Әюпов Фәрваз абыйны, биле авыртып, күптән түгел генә больницага салганнарын әйтте. Эш көне беткәндәрәк без аның хәлен белергә больницага бардык. Ул бер кешелек палатадагы караватында ятып тора иде. Безне чиксез шатланып каршы алды. Хәлен сорауга:

– Менә түшәмгә төкереп ятам, – дип көлеп куйды.

Аның йөзендә алай авыру билгеләре сизелми дә иде кебек. Биле белән ботының сызлавыннан, йоклый алмаудан зарланды, врачларның бик җентекләп тикшерүләре турында сөйләде. Без аны, дәвалангач үтәр, аяк кайсыбызныкы гына авыртмый инде ул, дип юаттык. Тизрәк терелеп чыгуын теләп саубуллаштык. Әмма минем өчен бу аның белән бөтенләйгә хушлашу булганлыгын мин соңрак аңладым.

Казан белән хәбәрләшкәндә, аңа куелган өч хәрефле диагноз иң элек йөрәккә шом салса, аннан соң да өметле хәбәр ишетелмәде. 1994 елның декабрендә аның вафатын ишеттек. Хәзер инде күңелдә сакланган истәлекләрдә генә очрашабыз...

БЕЛЕШМӘ

Фәрваз Миңнуллин – язучы, тәнкыйтьче, тәрҗемәче, редактор. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1984).

1934 елның 5 августында Арча районы Ишнарат авылында дөньяга килә. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, 1950–1954 елларда Арча педагогика училищесында укый, 1954–1959 елларда Казан дәүләт университетында филология буенча белем ала.

1959–1961 елларда Фәрваз Миңнуллин «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә бүлек мөдире булып эшли. 1961–1964 елларда Казан дәүләт университеты каршында аспирантурада укый. Аны тәмамлагач, берникадәр вакыт ТАССР Мәдәният министрлыгының сәнгать бүлегендә өлкән инспектор хезмәтен башкара. 1965 елда кабат «Казан утлары» редакциясенә әйләнеп кайтып, 1976 елның азагына кадәр анда тәнкыйть бүлеген җитәкли.

1977 елда аны Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре итеп сайлыйлар. 1978 елдан ул – идарә рәисенең урынбасары, 1984 елдан – Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире.

1975 елда– «Якты юллар», 1983 елда – «Прозаның гражданлык йөзе», 1984 елда– «Талантлар юлы», 1990 елда – «Затлылык», 1994 елда «Балта явызлар кулында» исемле әдәби тәнкыйть мәкаләләре тупланган җыентыклары дөнья күрә.

Татар әдәбияты буенча дәреслекләр төзүдә катнаша, шулай ук әдәби тәрҗемә эше белән дә актив шөгыльләнә. Герберт Уэллсның «Күренмәс кеше», «Галәмнәр сугышы», Джек Лондонның «Мартин Иден» әсәрләрен татар укучысы аның тәрҗемәсендә укый.

1994 елның 11 декабрендә вафат була. Туган авылы зиратында җирләнгән.

Әлмәттә кунакта.

30 ЕЛЛЫК СӘЯХӘТ

Яна Шевцова

Татарстанның уңышлы предприятиеләре республика һәм аның халкы мул тормышының нигезен тәшкил итә. Сәнәгать гигантлары, кече һәм урта бизнес мегаполислар, кече шәһәрләр һәм бистәләр үсешенә яхшы этәргеч бирә, яңа эш урыннары ача, мөһим социаль бурычларны хәл итәргә булыша. Яшел Үзәннең «Берёзка» төзелеш материаллары кибетләре челтәре – югары дәрәҗәсе вакыт белән сыналган урта бизнес предприятиеләреннән. Әлеге гаилә бизнесына быел 30 яшь тула. Хәбәрчебез аңа нигез салучы Рузилә Равил кызы Тимергалиева белән республика көне алдыннан әңгәмә корды.

СИСТЕМАЛЫ ИТЕП ҺӘМ ТӘМЕН ТОЕП ЭШЛӘРГӘ КИРӘК

– Рузилә ханым, өч дистә ел эчендә кеше үсәргә, өлкәнәергә, белем алырга, шәхес буларак формалашырга, үз урынын табарга өлгерә. Ә бу утыз ел «Берёзка» өчен нинди булды?

– Без беренче юл яручылар арасында идек: эшне 1994 елда, илдә иҗтимагый строй алышынганнан соң башладык. 30 ел – тулы бер чор... Ә барысы да Яшел Үзәннең Королёв урамында 70 кв. метрлы сәүдә ноктасыннан башланды. Бүген «Берёзка» 5 шәһәр һәм бистәдә DIY («Do it yourself» – «Моны үзең эшлә» дигән гыйбарәдән аббревиатура) форматындагы алты кибеттән торган сәүдә челтәрен тәшкил итә. Еллык әйләнеш миллиард ярым сумга җитте, коллективта 300 ләп кеше исәпләнә. Бу Россиянең үсәргә мөмкин һәм үсәргә кирәк булган ил икәнлегенә

Фото Тимергалиева ШЭдән алынды. РЕКЛАМА

бер дәлил түгелмени? Безнең республика җитди тотынып, системалы, дәвамлы рәвештә, «тәмләп» эшләргә мөмкинлек бирә. Иң мөһиме: син кешеләр өчен дә, үзең өчен дә файдалы булырга тиеш.

– Соңгы еллар ил өчен шактый катлаулы булды. «Берёзка» аларны ничек кичерде?

– Әйе, пандемия дә, 2022 елда сатып алучыларның кайгы-борчулары да читләтеп узмады. Әлбәттә, җиңел булмады. Ләкин кешеләргә төзелеш һәм ремонт өчен товарлар һәрвакыт кирәк, ә халыкка сатып алу уңайлы һәм рәхәт булсын өчен, «Берёзка» челтәре үз кибетләрендә барысын да эшли. Соңгы 6 елда кибетләр челтәре хезмәткәрләр һәм сатылган товар саны буенча 4 тапкырга үсте. Һәм шуны да искә алып үтим: бу үсешкә күршедә генә ике эре көндәш эшләп килгәндә ирештек.

– Республика бүген төзелеш тармагы чын күтәрелеш чорын кичерә. Күпфатирлы комплекслар калкып чыга, шәхси торак йортлар да актив төзелә…

– Яшел Үзән – төзелеш кайнап торган үзәкләрнең берсе, биредә йортлар гына түгел, ә микрорайоннарны бер-бер артлы файдалануга тапшыралар. Безнең шәһәр – Казанга якын, шул ук вакытта торак бәяләре арзан булган мөһим сәнәгать үзәге. Куәтле товар бүлү-тарату үзәге барлыкка килү һәм аның зураюы да алга таба үсеш драйверына әйләнде. Бу – «Берёзка» өчен бер сынау, һәм без аны кабул итәбез.

Гомумән, минем өчен Яшел Үзән – беренче чиратта, тормышымның яраткан урыны, матур почмагы, анда хәтта сулыш алулар да башкача, чөнки монда тудым бит. Моннан китәсе килми.

СЕРВИС ҺӘМ ИННОВАЦИЯЛӘРГӘ ӨСТЕНЛЕК

– Ремонт эше (төзелеш турында әйтәсе дә юк) – йорт яки фатир хуҗасы өчен катлаулы вакыт, барысы да берьюлы кирәк...

– Без моны аңлыйбыз, шуңа күрә бездә һәрвакыт акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирә торган программалар гамәлдә булды. Мәсәлән, бушлай китереп бирү һәм 3D-дизайн, кибеткә кичектереп түләү, ташламалар системасы, ә хәзер яңа фатирга күченүчеләргә 100 мең сумлык сертификатлар бүләк итәбез.

– Компаниянең миссиясе – һәр йортка ямь, уңайлылык һәм бәхет алып килү. Мондый иҗади юнәлештә эшләү рәхәтме?

– Әлбәттә. «Берёзка» ярдәмендә кешеләрнең сыйфатлы төзелеш һәм ремонт материаллары алуын, көчләрен, акчаларын янга калдыруын һәм өйдәге уңайлы яңа мохит белән ләззәтләнүен белү үзе бер куаныч. Яңа ваннада, яңа душта җырлаган кебек, беркайда да шулкадәр рәхәтләнеп җырламыйсың. Ә сабыйның яңа идәндә тәпи йөреп китүе – ул хисне бернәрсә белән дә чагыштырып булмый.

Эшемнең мөһимлеген тоюдан барлыкка килгән илһам-дәртне хезмәткәрләребезгә дә җиткерә алуыма мин бик шат. Безгә эшкә килгәч, аларның үз тормышларында да яңа этапка аяк басуларына игътибар иттем – ремонт ясый башлыйлар, сәяхәткә чыгалар. Безнең күп кенә хезмәткәрләр турында үз һөнәренә гашыйк дип әйтү бер дә арттыру түгел.

– Ләкин бит сез укыту-өйрәтүгә дә көч-вакыт кызганмыйсыз.

– Әйе, шулай, персоналны үстерү-камилләштерүгә зур әһәмият бирәм. Әгәр кеше үзгәрә, үзе өчен яңа офыклар ача икән (сүз уңаеннан, профессиональ планда гына түгел, шәхси планда да), компаниягә карата җылы мөнәсәбәт арта.

Бизнес-процессларда да мин даими рәвештә үзгәртеп корулар уздырып торам, инновацияләр кертәм. Мәсәлән, маркетингта ясалма интеллект технологияләрен актив кулланабыз.

– Сүз уңаеннан, сәяхәтләр турында. «Берёзка» хезмәткәрләренең компания хисабына сәяхәт итүе дөресме ул?

– Әйе, бездә «Геройлар сәяхәте» проекты бар: быел компаниянең 30 еллыгы уңаеннан бүлекчәләр арасында миллион сум акча уйнатабыз. Моңа кадәр без 500 мең сум уйнаткан идек. Куелган максатка ирешеп, ярышта җиңәсез икән, – сәяхәткә сертификат аласыз. Кемдер Таиландны сайлый, кемдер – Санкт-Петербургны.

– Компаниянең юбилее уңаеннан коллективыңа нәрсә әйтер идегез?

– Рәхмәт сүзләре. Сез – безнең сугышчыларыбыз, безнең таянычыбыз. Иң әүвәл, безнең белән инде күп еллар иңгә-иң хезмәт куючыларга һәм хәзер дә һәр иртә «Берёзка»га килүчеләргә рәхмәт белдерәм. Компаниядә 29 ел эшләгән кешеләр бар, 15 ел һәм аннан да озаграк эшләүчеләр дә дистәдән артык. Кайберләре тулы бер династия булып эшли. Мәсәлән, башта ир белән хатын урнаша, аннары балаларын да эшкә алып киләләр.

Тәҗрибәле хезмәткәрләребез – кыйммәтле муенсадагы күп еллар дәвамында бик саклык белән, кадерләп җыелган энҗе бөртекләрем кебек.

– Сез инде күп еллар кешеләр белән эшлисез. Сезне нәрсә һаман да гаҗәпләндерә?

– «Берёзка» кече шәһәрләрдә һәм бистәләрдә эшли. Аларның кайберендә нибары 5 меңләп кенә кеше яши. Тик биредә халык намуслылыгы, ихласлыгы, хезмәт сөючәнлеге белән аерылып тора. Мин бу хакта шуннан чыгып фикер йөртәм: андагы кибетләребездә товарларны кичектереп түләү юлы һәм кредитка алганда, түләми йөрүчеләр проценты бик түбән.

Без үзебез дә сатып алучылар белән аларны үз күреп, гаиләбезнең бер әгъзасы кебек якын итеп аралашырга; клиентлар безгә кабат киңәш-табыш сорап мөрәҗәгать итсеннәр өчен, игътибарлы һәм файдалы булырга тырышабыз. Игътибарга лаек бер вак-төяк: хезмәткәрләребез сатып алучыларга үз телефон номерларын бирәләр. Мондый мөнәсәбәт хәзер бик югары бәяләнә, кече шәһәрләрдә эшләүнең бер үзенчәлеге булып тора.

Минем өчен «Берёзка» кибетләре челтәрен үстерү – сез, кадерле сатып алучылар һәм хезмәткәрләрем белән бергәләп 30 еллык сәяхәт ул, һәм әлеге сәяхәт шатлык-куанычлар һәм ачышлар белән тулы. «Берёзка» сезнең өчен эшли, сезнең өчен үзгәрә, алда аны зур юллар көтә. Безнең белән булыгыз!

САРСАК-ОМГА: УДМУРТ ДӨНЬЯСЫНА КАПКА

САРСАК-ОМГА

Фото: Александр Гайнетдинов

«Татарстан» үзенең йөз дә өч еллык тарихында байтак авыл күрде, әмма Сарсак-Омга кебек үзенчәлекле, шул ук вакытта заманча эшлекле дә, актив та авыл белән беренче тапкыр очрашабыз. Быел июнь аенда республиканың 11 районыннан тәҗрибә уртаклашу максатыннан «Авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру» семинарының нәкъ менә монда үткәрелүе дә очраклы түгел.

Татьяна Вафина

КҮЗ КАМАШТЫРГЫЧ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР

Сарсак-Омганың күз камаштырырлык үзенчәлеге юлдан кергәндә үк күренә – сырлап-бизәкләп ясалган җете сары капкалар христиан удмуртлар белән мәҗүси удмуртларның традицияләрен берләштергән дөньяга дәшә. Элек мондый авыл капкасы, тик читәннән үрелгәне, һәр удмурт авылына керә торган юлга куелган, дип сөйлиләр. Чит кеше кермәсен дип, аны төнгә ябып куя торган булганнар.

Борылыштан соң тагын бер истәлекле объект көтә – зәңгәр түбәле, алтын гөмбәзле чиркәү…

– Чынлыкта бездә чиркәү бик борынгы, 1903 елда төзелгән, – ди авыл җирлеге башлыгы Тамара Николаева. – XX гасыр башында төзелгән бу храмны да башка күп кенә гыйбадәтханәләр кебек ябып куйганнар. Анда озак кына вакытлар әле фельдшерлык пункты, әле китапханә, әле клуб була. Ләкин авыл халкы чиркәүне торгызырга уйлый. Өмәләр оештырып, якшәмбе көннәрендә, әкренләп, бу изге эшкә керешәләр.

БУРАНОВО ӘБИЛӘРЕ БЕР ЯКТА ТОРСЫН!

– Безнең «Зарни сизьыл» дип аталган ансамблебез бар, удмурт теленнән тәрҗемә иткәндә «Алтын көз» дигәнне аңлата. Авылыбызның яшь әбиләре аны 2000 елда үз көчләре белән оештыра. Пенсиягә чыгып, эшсез уты-

1

Борылыштан соң тагын бер истәлекле объект – зәңгәр түбәле, алтын гөмбәзле чиркәү...

2

Музейда меңгә якын ядкәр саклана.

рырга өйрәнмәгән алар, менә шулай оешып та китәләр. Әбиләребез бөтен Удмуртия буйлап чыгыш ясап йөрде, «Бураново әбиләре» кебек Мәскәүдә дә җырлап кайттылар. Ләкин шунысы хак: нәкъ менә безнең әбиләргә карап, Бурановоныкылар алга үсеп китте дә инде, – дип сөйли Тамара Сергеевна, һич шикләнмичә.

СӘЯХӘТЧЕ ЧИРКӘҮ

Хәзерге заманда һәр авылның диярлек үз музее бар. Сарсак-Омгада да бар ул. Нинди генә әле! Кайбер район үзәгендә дә андыйны очрата алмыйсың.

Борынгы йорт янына киләбез...

– Хәзер бу йортта музей, – ди Тамара Сергеевна. – Элек бу бина Сарсак-Әрәмә авылында Богоявление чиркәве иде. Аннары аны мәктәп, китапханә итеп үзгәртәләр... – башка күп авыллардагы кебек. Ә 90 нчы елларда авыл бетте, барысы да күченеп китте. Ә бина калды, һәм, аны безнең үзәк урнашкан хуҗалыкка күчереп, медпункт ясап куйдылар. Ә 2015 елда федераль программа буенча яңа медпункт төзелгәч, бина тагын ятим калды. Һәм без анда музей ясарга булдык.

– Музейга килүчеләр бармы соң?

– Ничек кенә әле! – ди Тамара Сергеевна һәм, ишекне ачып, иркен, чиста өйгә үтәргә дәшә. – Халык йөри, карый, укучылар да керә, районнан да киләләр. Монда кич утырулар оештырабыз, Әбиләрне җыябыз, фольклор ансамблен чакырабыз...

ТАРИХ САКЧЫСЫ

– Менә монда бездән Бөек Ватан сугышында катнашучылар. Алар 500 гә якын. Һәркайсына кечкенә альбом ясарга булдык... – дип сөйли Тамара Сергеевна азу ярган экскурсоводтай. – Ә бу колхозга, авыл советына багышланган почмак. Менә Мактау китабы. Бу – безнең беренче рәис – Молчанов. Менә монда авыл советы рәисе булып эшләгәннәрнең барысы турында мәгълүмат тупланган....

– Боларның барысын да кем язды, кем җыйды, кем шулай системага салды?

– Мин үзем җыям. Борынгы, тарихи әйберләрне бик яратам, шуңа күрә бу музейны оештырырга булдым да. 2013 елда, әти-әнием үлгәч, аларның йортында бик күп нәрсәләр калды. Нишләтергә боларны дип уйлап тордым да, музей ясарга кирәк, дигән фикергә килдем.

Менә күрәсезме, бу – бер колхоз рәисенең әтисе сөйләгәннәр. Ул Гражданнар сугышында булган, без бала чакта аның белән очрашу үткәргән идек, анда ул кылыч белән ничек сугышканы турында бик кызыклы итеп искә ал-

– Бу иске земство мәктәбе. Эчендә миче дә бар, күрәсезме? Монда мәктәпнең бөтен тарихы сакланган, – ди Тамара Сергеевна.

ган иде. Мин аның сөйләгәннәрен бик яхшы хәтерлим....

– Нинди матур, каллиграфик язу!

– Әйе, мөгаен, берәр махсус писарь язгандыр. Безгә авыл хуҗалыгы идарәсеннән килеп эләккән альбомда сакланган. Кызганыч, әлбәттә, альбомда фотосурәтләрнең барысы да безнең көннәргә килеп җитмәгән. Монда тагын КПСС әгъзасының исәп карточкасы да бар. Менә безнең авыл кешеләренең Мәскәүдә ВДНХда катнашулары турында бер дәлил. Монысында – чиркәү янында төшкән авыл кешеләре. Күргәнегезчә, ул чактә әле бина реставрацияләнмәгән була. Кучмә байрак... Мин боларның барысын да иске авыл советы бинасын сүткәндә таптым.

Ә монда – безнең җирлектәге мәҗүсилек тарихы. Болар – борынгы ыру билгеләре. Һәр ыруның үз билгесе булган. Ул нәсел вәкилләре хәзерге көндә дә безнең авылда яши, алар ыруга нигез салган Омга нәселенә карый.

ИХЛАС МАВЫККАН КЕШЕЛӘР

– Бу иске земство мәктәбе. Макетны безнең мәктәп укучысы Олег Филиппов ясады. Эчендә миче дә бар, күрәсезме? Монда мәктәпнең бөтен тарихы сакланган. Элек ничек булганын онытмасыннар өчен...

Тамара Сергеевна Сарсак-Омганың бөтен тарихын саклап калган, ахры. Мондый ихлас мавыгып эшләүче кешеләр – теләсә кайсы авыл өчен чын табыш.

– Менә бу әйберләрне үреп ясаган оста, кызганыч, үлде. Ярый әле, исән чагында мин аңардан кайбер нәрсәләрне сатып алырга өлгердем.

Бу курчаклар да кулдан ясалган. Аларны шушындагы бер оста ясый. Күрәсезме, кинодагы атаклы өч дусны ясаган: Вицин, Никулин һәм Моргунов самогон аппараты белән! Ә аннары ул Җиңү көненә музейга менә шушы солдатларны алып килде.

Кешеләр хәзер үзләре бөтен нәрсәне музейга ташый. Каска алып киләләрме, почта сумкасымы – барысын да алам.

Ә бу авылыбызның атаклы әдәбиятчысы, җырчы Леонид Лазарев. Ул балалайкада, гомумән барлык уен коралларында да уйный иде. Менә аның баяны, язу машинкасы, фотоаппаратлары. Җырлар, шигырьләр яза, фотога төшерә иде – авылдагы бәйрәмнәрен, кичәләрне истәлеккә калдырды. Аның гаиләсе барлык фотоаппаратларны музейга тапшырды.

Лазарев әйберләре белән янәшә радиолалар, магнитофоннар, Ленин бюсты урын тапкан...

– Бу әйберләрнең барысын да чыгарып ташлаганнар иде – мин җыеп алдым. Ленинны чыгарып ташларга ярыймы инде? Әлегрәк шулай иткән булсалармы... – дип көлә Тамара Сергеевна.

СӘҮДӘГӘРЛӘР БҮЛМӘСЕ ҺӘМ УДМУРТ ЙОРТЫ

Икенче бүлмәгә күчәбез – ул «Сәүдәгәрләр бүлмәсе» дип атала.

– Безнең авылда сәүдәгәр Таракановлар яшәгән, алар тимерчеләр булган. Бөтен нәрсәне үзләре ясаганнар. Аннары гына, үз эшләнмәләрен сату белән генә чикләнмәс өчен, кибет оештырганнар. Керосин лампасы, үлчәүләр, облигацияләр – нәрсә бар, барысын да җыйдык.

Сәүдәгәрләр бүлмәсеннән «Удмурт йорты»на күчәбез. Төрле техникада чигелгән сөлгеләр, кулдан тукылган келәм, бирнәле сандык... Алтын куллар тудырган матурлык!

– Удмурт кәләше бирнәсен гадәттә үзе чиккән һәм, өйгә кергән кешеләргә үзенең уңганлыгын күрсәтер өчен, чигүле әйберләрне шушы рәвешле элеп чыккан. Кызлар инде 12 яшьтән үк әнә шулай чигә белгәннәр.

Тамара Сергеевна, сандыкны ачып, аннан пөхтә итеп төреп куелган әйберләрне чыгара. Итәкне, алъяпкычын, башлыгын киеп, яулыгын бәйләп карый... Һәм менә каршыбызда – нур чәчеп торган чын удмурт кәләше.

3

Тамара Сергеевна, сандыкны ачып, аннан пөхтә итеп төреп куелган әйберләрне чыгара. Итәкне, алъяпкычын, башлыгын киеп, яулыгын бәйләп карый...

3

– Мондыйны бәйрәмнәрдә генә кигәннәр. Ә менә монысы – эшкә барганда, чөнки бизәксез, – дип аңлата ул. – Ә менә бу хәзерге күкрәк баласы рюкзагына охшаш җайланма белән кырда эшләгәндә баланы күтәреп йөргәннәр. Ә менә монда, түшәмдә, күрәсезме?

– Акча асылынып тора бит анда!

– Әйе. Армиягә китүчеләр түшәмгә чүкеч белән акча кадаклап куя – йоласы шундый. Соңыннан чүкечне ыргыта торган булганнар, ул килеп төшкәч кайсы тарафка күрсәтә, солдат шул якка хезмәт итәргә китә, янәсе.

Солдатларны армиягә иске рекрут җыры белән озаталар:

Китам хәрби хезмәткә, бер елга гына түгел,
Туган авылымда эзләрем генә калачак.
Минә малай чагымда ук йөгереп йөргән елга буе,
Менә әти-әнием белән печән чапкан кыр-басуы.
Онытма мине, туган төбәгем, күрешербезме икән тагын?..

Ә акча үз солдатын көтәргә тиеш. Кайткач исә, дуслары аны түшәмгә күтәрәләр, һәм егет бу акчаны тешләре белән тартып алырга тиеш.

Хәзер безнең авылдан өч егет махсус хәрби операциягә китте. Берсе кайтты инде. Менә аның үз акчасын алырга килгәнен көтәбез.

ЯРАТКАН ЛИЦЕЕМ

Музейдан мәктәпкә юл тотабыз. Уку йорты авыл җирлеге башлыгы тормышында аерым урын алып тора. Кайчандыр бу мәктәп агролицей була, ә Тамара Сергеевна анда директор вазыйфасын башкара. Ул укытып чыгарган кешеләр арасында кемнәр генә юк: Әгерҗе районының хәзерге башлыгы да – аның укучысы.

4
Армиягә китүчеләр түшәмгә чүкеч белән акча кадаклап куя – йоласы шундый.

5 Лицей стеналарына 11 нче сыйныфны тәмамлаучыларга теләкләр язылган плакатлар эленгән..

6
– Безнең мәктәптә барлыгы 92 укучы белем ала, тагын 19 бала мәктәпкәчә төркемнәргә йөри, – дип сөйли Ләйсән Шәйдуллина.



– Мин лицейны тәмамлаганда, безнең сыйныфта 30 укучы иде. Барысы да авыл хуҗалыгы институтына укырга керде! – дип горурланып сөйли район башлыгы Ленар Нургаянов.

– Директор эшен, мәктәпне сагынмыйсызмы? – дип сорыйбыз Тамара Сергеевнадан.

– Сагынам, – дип елмая ул. – Тик укучыларымның барысы да биредә, Сарсак-Омгада, районда, һәркайсын күреп торам, кирәк булса, барысы да ярдәм кулы суза. Иң мөһиме, сүземә колак салалар. Мин барысының да дуслары исемлегендә. Мин үзебезнең лицейны яратам, – ди җирлек башлыгы.

– Яртылаш барыбер биредә ул, – ди лицейның хәзерге директоры Ләйсән Шәйдуллина. – Тәне белән тегендә, җаны белән монда. Мәктәпне онытып буламыни?!

Лицей, әлбәттә, күзне сөендереп, балкып тора. Янәшәдә – республика программасы буенча төзелгән спорт мәйданчыгы. Сәхнә. Балалар бакчасының аерым керү урыны бар.

– Безнең мәктәптә барлыгы 92 укучы белем ала, тагын 19 бала мәктәпкәчә төркемнәргә йөри, – дип сөйли Ләйсән Малик кызы. – Штатта 40 хезмәткәр, 25 педагог һәм тәрбияче.

Лицей-мәктәп стеналарына 11 нче сыйныфны тәмамлаучыларга теләкләр язылган плакатлар эленгән. Бу – зур тормышка аяк басучы өлкән иптәшләренә унынчы сыйныф укучыларыннан үзенә күрә бер сюрприз. Быел Сарсак-Омга мәктәбендә унберенче сыйныфны – 7, тугызынчыны 14 укучы тәмамлаган.

Мәктәптә удмуртлар да (алар күпчелекне тәшкил итә, чөнки Сарсак-Омга – удмурт авылы), татарлар да, руслар да укый. Балалар туган телләре буларак удмурт телен дә, татар телен дә һәм, әлбәттә, рус телен өйрәнәләр. Инглиз һәм немец телләре 7-8 нче сыйныфларда икенче чит тел буларак укытыла.

– Монда барыгыз да полиглотлар, ахры?

– Нинди генә полиглотлар әле! – дип раслый Ләйсән ханым.

Бүген мәктәптә полиглотлар күренми – аларның законлы каникул вакыты. Ә укытучылар эш урынында. Әдәбият укытучысы Флёра Камил кызы Зарипова безне мәктәп музеена алып бара.

ТАГЫН БЕР МУЗЕЙ

Аның башка мәктәп музейларыннан аермасы – һәр чыгарылыш һәм династиягә багышланган альбомнар.

– Һәркем монда килеп, үз сыйныфының папкасын табып, фотосурәтләр карый, ниндидер мәктәп хатирәләрен, балачагын искә төшерә ала, – дип сөйли Флёра ханым. – Бирьдә 1954 елдан башлап һәр чыгарылыш сыйныф укучыларының альбомнары саклана.

Ә диварда – укытучылар династияләре. Мәсәлән, математика укытучысы, мәктәптә хезмәт стажы 44 елга җиткән Людмила Леонидовна Маркитонованың династиясе. Аның улы да (ул хәзер махсус хәрби операциядә) мәктәптә эшләгән, килене инглиз теле укыта…

– Ә менә монда безнең династия. Бу этием, сеңлем, кызым, – дип санап китә Флёра ханым. – Бездә династияләр бик күп.

Борынгы уку әсбаплары, тарихи мактау кәгазе – монда уникаль һәм оригиналь документлар бихисап. Счётлар, элек физика дәресләрендә кулланылган приборлар... Сарсак-Омгада ядкәрләргә бик сак карыйлар.

– Бу – кулдан ясалган көзгеле шар, ул 80 нче елларда мәктәп дискотекасында түшәмдә эленеп тора иде. Әлеге яктылык музыкасын физика укытучысы балалар белән бергәләп үзе ясаган, – ди укытучылар, яшь вакытларын искә төшергән әйберләргә үзгә бер җылылык белән карап.

Мәктәпнең махсус хәрби операциягә киткән укытучыларның һәм кайчандыр бу мәктәпне тәмамлаган, хәзер махсус хәрби операциягә киткән ир-егетләрнең портретлары өчен аерым урын бирелгән.

– Бу безнең укытучыбыз Сергей Юрьевич Маркитонов, шул математика укытучысының улы. Элек ул монда директор иде, аннары тормыш иминлеге нигезләрен һәм физкультура укытты. Бу подполковник Виктор Александрович. Ул да безнең мәктәп укытучысының улы. Монысы Александр Тихин – өлкән прапорщик, китапханәчебезнең улы. Барысы да безнең балалар.

Мәктәптә тә «удмурт өе» бар. Аны авыл музеендагы «удмурт өе»нең филиалы дип атарга була. Милли почмакны удмурт теле укытучысы кайгыртып тора. Анда төрле милли һөнәрләр буенча осталык дәресләре, «Лазарев укулары» үткәрелә. Без исемен инде берничә тапкыр ишеткән Леонид Лазарев лицейда тарих укыткан икән.

ГАЖАСА ПЫРЫНЫ КУРИСЬКОМ!*

Мәктәп ишегалдыннан чыгып барганда, гомер буе Сарсак-Омгада яшәгән һәм беркая да китәргә җыенмаган авыл җирлеге башлыгыннан, директор-җитәкче күзлегеннән караганда, умгалыларның башкалардан нәрсә белән аерылып торуын сорыйбыз.

– Без эшчән халык, – ди Тамара Сергеевна. – Бездә хуҗалыклар бик нык. Терлек асраучылар күп. Зур-зур бакчалар. Крестьян-фермер хуҗалыкларында эшлиләр. Менә «Авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру» семинарында мини-ферма ачтык. 400 кеше, төрле районнардан 11 авыл җирлеге башлыгы килде. Барысын да яхшы каршы алдык, бөтенесен күрсәттек, сөйләп бирдек. Безнең халык ачык йөзле, кунакчыл. Кешегә мөнәсәбәтең яхшы булганда, ул да сиңа шундый ук мөгамәлә күрсәтә.

Без һәркемне бик куанып каршы алабыз, барыгызны да һәрвакыт көтеп калабыз – рәхим итегез! Гажаса пырыны куриськом!

7

Людмила Леонидовна Маркитонованың мәктәптә хезмәт стажы 44 ел тәшкил итә.

8

– Бу – кулдан ясалган көзгеле шар, ул 80 нче елларда мәктәп дискотекасында түшәмдә эленеп тора иде.



9 – «Авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру» семинарында мини-ферма ачтык. 400 кеше, төрле районнардан 11 авыл җирлеге башлыгы килде...

НИЧЕК БАРЫРГА:

Әгерҗегә таба юл тотарга. Аңа 32 километр кала, үзегезгә кирәкле авылга килеп тә чыгасыз. Казаннан Сарсак-Омгага кадәр – 293 км.

НӘРСӘ КАРАРГА:

Музей һәм чиркәүдән тыш, Сарсак-Омгада тагын бер истәлекле урын бар – Алабуга–Сарапул почта трактындагы Әби патша күпере. Риваятьтә әйтелгәнчә, аның астында Емельян Пугачев үз кылычын кайраган. Әлбәттә, үзе кайрамаган, авылның бер иратына кушкан һәм яхшы хезмәте өчен аны бик мактаган, диләр. Ләкин кылычның нәкъ менә Пугачевныкы булганлыгы – тарихи факт. Күперне бу якларга килергә җыенган Екатерина патшабикә өчен салганнар, тик нияте үзгәргән, килмәскә булган, диләр... Тарихи күпер өстеннән заманча бетон күпер уза: төзүчеләр иске күперне җимермәгән. Шул рәвешле күпер ике катлы булып калган.

НӘРСӘЛӘРНЕ ФОТОГА ТӨШЕРЕРГӘ:

Сарсак-Омгага кергән җирдәге капка фотода аеруча шәп чыгачак. Аның фонында төшкән селфилар бөтен дөнья буйлап тарала. Фото гынамы! Җирле пленэрларда бу капка – төп натура. Мәсәлән, күрше Иж-Бубый авылында урнашкан Мөхәммәтҗан Әхмәтҗанов исемендәге музейда әлеге капка сурәтләнгән картина экспозициядә үзәк урыннарның берсен алып тора.

Гомумән, бу якларда капкалар – чын сәнгать әсәре: Казаннан Әгерҗегә барасыңмы, кире кайтасыңмы, як-ягыңа карарга гына өлгер! Татарстанда капкаларның ниндие генә юк.

* *Гажаса пырыны куриськом! – Хуш киласез! (Удмурт теленнән. тәрҗемә)*

ай кәефе: блогерларча

БАРЫСЫ ДА БИК ШӘП

Моннан соң Татарстан блогерларының иң яраткан бәйрәме блогерлар Сабан туе булыр, мөгаен.

Беренче шундый Сабан туе 27 июльдә Теләче районының Баландыш авылында узды.

Авыл халкы, әлбәттә, бәйрәмгә нык-лап әзерләнгән иде. Бу көнне алар Казаннан, Яр Чаллыдан, Түбән Кама-дан, Азнакайдан һәм Татарстанның башка шәһәрләреннән социаль челтәрләрен татар телендә алып баручы популяр блогерларны кабул итте.

Ике як та – кабул итүче дә, чакырылган-нар да – йөзгә кызыллык китермәде. Бәйрәм гөрләп торды: җырладылар да, биеделәр дә, милли уеннарда да катнаштылар, тәмләп сыйландылар да! Һәм, әлбәттә инде, нәтиҗә буларак, «барып җитәрлек», «кереп китәр-лек» «контент» тупланды.

Ә «нетипичный татарин» Илнариус Та-тариус, барысын да шаккатырып, ул көнне өйләнеп куйды! Әйе-әйе, Сабан туенда! Ак күлмәкле кәләш тә, никах балдаклары да, Теләче районы башлыгы Нәҗип Хаҗиповның котлавы да – барысы да чын булды.

Блогерларның көндәлек эшләре дә шул бит: иң мөһиме – шаккатыру! Татариус ул көнне моңа ирешә кебек.

Фото: Александр Ефремов

АЙДАР
ДИКИЙ

Сабан туенда
өйләнешү – текә!
Ягъни бик шәп!